Рәис САФИН

Җан авазы



SHAMS
КАЗАН
2017

УДК 82–1.145:821.512.145
ББК -5*84Тат
С 21


Сафин Р.
С 21 Җан авазы. – Казан: «Школа» редакция-нәшрият үзәге, 2017. – 472 б.

Каләм иясе Рәис Сафин исеме әдәбият сөючеләргә һәм милләтпәрвәр затларга яхшы таныш булыр. Ул – повесть-хикәяләр, поэма-шигырьләр, көндәлек матбугатта чыккан күпсанлы публицистик мәкаләләр авторы.

Рәис Сафин халыкыбызның алтын баганадай дәүләтчелеген югалтуы, кылычтан үткәрелүе, чукындыру һәм урыслаштыру шаукымы, толерантлык чире, катнаш никахларның һәлакәтле гариплеге, манкорт балаларның наданлыгы турында ачынып вә ачыттырып яза.

© Р.Сафин, 2017
© РИЦ «Школа», 2017





Тугра: Сафин Рәис
Габдулла улы (С.Р.Г.)
Нәҗип Нәҗкаш эше.

Сентябрь – 2016.

Татар өчен җан аткан әдип...

Миллионлы башкалабыз Казан шәһәрендә кемнәр генә яшәп ятмый – ашап-эчеп кенә көн үткәрүчеләр дә, гап-гади эшчеләрдән алып министрлар, әдәбият-сәнгать әһелләре, тагын-тагын бик күп һөнәр ияләренә кадәр! Мин моның белән: һәрбер кеше үз тәҗрибәсеннән чыгып, тормыш-яшәеш күренешләренә үз каланчасыннан торып бәя бирә, максат-ниятләренең рухи маягын билгели, гражданлык бурычын үти, милләте һәм язмышы каршында исәп-хисап бирә, дип әйтергә телим.

Менә шулар арасында Рәис Сафин дигән танышым, фикердәшем, каләмдәшем дә бар бит әле, дип уйлап куям кайчак. Кем соң ул, ил-көнгә һәм татар дөньясына нинди файда китерә, дип әйтүчеләр булыр. Менә шул сорауга җавап йөзеннән аның турында сөйлисем, язасым килде дә инде.

Каләм иясе Рәис Сафин иселе әдәбият сөючеләргә һәм милләтпәрвәр кешеләргә яхшы таныш дип уйлыйм. Ул – повесть, хикәяләр, шигырьләр, көндәлек матбугатта чыккан күпсанлы публицистик мәкаләләр авторы. Иң элек тәрҗемәи хәле турында берничә кәлимә сүз. Ул 1935 елның 6 гыйнварында (Ураза гаете көне!) Арча районының Субаш-Аты авылында туган. Аның тормыш һәм хезмәт биографиясе – үзе бер китаплык...

Китап димәктән, ул – ун китап авторы. Бераңгә дә ялынмый, бер кемнән дә ярдәм сорамый. Китапларын үз пенсия акчасына 300-500 данә итеп, фән һәм мәгариф министрлыгының «Школа» нәшриятында бастырып, китапханәләргә һәм җәмәгать оешмаларына тараткан

Рәис ага турында дөресен сөйләү тыйнаксызлык булмастыр. Бу урында тагын шунысын да әйтү кирәктер: ул 64 яшеннән соң гына кулына каләм алып, иҗатын бүген дә нәтиҗәле һәм бәрәкәтле дәвам итүче язучы булып саналырга хаклы түгел микән әле? Китапларын үзе бастырып, үзе бушлай таратып йөрүенең «сере» бик гади: җан авазы белән сугарылган язмаларының, әйтер сүзенең киң катлам укучыларга тизрәк барып ирешүен ихластан тели ул!

Безнең татар матбугаты аның чын милли рух белән сугарылган, милләтебезнең тарихта һәм бүгенге көннәрдәге фаҗигаи язмышы турында ачынып язылган ватанпәрвәр шигырьләрен басарга бик ашкынып торлый. Чөнки автор тел яшереп маташмый, татар хәятының 1552 елдан бирле чит кавем кысымы астында изелеп, хокуксыз илдә яшәве... Барлык шушы мәсхәрәле золымнарга өстәп, шовинизм рухлы «Яровая пакеты»н да төбәкләргә чәпәп куюлар һәм халкыбызның алтын баганадай дәүләтчелеген югалтуы, кылычтан үткәрелүе, чукындыру һәм урыслаштыру шаукымы, толерантлык чире, катнаш никахларның һәлакәтле гариплеге, манкорт балаларның наданлыгы турында ачынып вә ачыттырып яза ул. Боларны рәсми матбугатта бастырсаң, башың «себер китәргә» мөмкин! Ә кайсы гына баш мөхәррирнең кәнәфиен ташлап китәсе килсен икән!..

Иҗатыннан мисаллар китерү белән мавыгасым килми, ә шулай да түбәндәге юлларга игътибар итик әле:

Милләтемнең изге мирасына
Хуҗа булды комсыз бер кавем.

«Безнең җирләр», – диеп өскә япты
Шовинизм дигән бөркәвен...

Һәм, ниһаять:

Керфекләремдә күз яше,
Күңелемдә горурлык:
Болгарыбызның һәр ташы –
Баш бәһасе торырлык!

Болгар темасына безнең шигърияттә байтак шигырьләр иҗат ителгән. Шулардан иң яхшы үрнәкләрне сайлап, беренче Президентыбыз Шәймиев җитәкчелегендә Болгарны яңарту, реставрация ясау эшчәнлеге барышында әлеге тыюлык туфрагында шигърият стелласы да торгызылса, әлеге дүртъюллык, һичшиксез, үзенең лаеклы урынын алыр иде, минемчә.

Авторның «Без – кылычлы халык» дигән шигыре дә гыйбрәтле һәм истә калырдай образлы юллар белән тәмамлана:

Сынган кылыч – шагыйрьнең дәһшәте ул,
Шул дәһшәткә тотынгандыр безнең кул!

Бу шигырьдәге кинаягә аңлатма бирү һәм шәрехләүнең хаҗәте юктыр. Авторның бу китабы белән якыннан танышу хәерлерәк булыр.

Мәңге хәтеребездә: узган гасырның 90 нчы елларында Татарстанда милли азатлык хәрәкәте кузгалды, халыкның үзаңы уянды. Икенче сортлы республика булып тагын күпме яшәргә мөмкин, дигән сорау мәйдан уртасына чәчрәп чыкты. Меңләгән ватандашлары кебек, ул көннәрдә Рәис Сафин да мәйдан уртасында кайный. «Азатлыкка олтыру көрәше эзсез генә узмады, – ди ул. – Митинглар остасы буллмасам да, шигырьләрем

белән әлеге изге һәм сәваплы көрәш кырына дөрләткеч ут өстисем килде!»

Йөрәктән сәвылып, әрнү катыш горурлык белән үрелеп, дәүләтчелекне торгызу турында чаң кагып, әнә шулай яңадан-яңа шигырьләр туа тора...

Минем: «Татарстан Язучылар союзына керү турында бер дә уйламагансың, ахры», – дигән соравыма ул болай дип җавап бирде:

– Тыйнаклык сакладым... Өметләнергә дә урын аз иде бугай. Идарә утырышында, җитмешкә җиткән агайларны союзга алмаска, дигән катгый таләп куелганын да ишетеп белә идем. Үземә дә, кешеләргә дә мәшәкать тудырасым килмәде...

Мин аның бу сүзләре белән килештем.

Ә йөрәгендә шигырь уты дәвам итә...

Тормыш-яшәештәге күркәм яки ямьсез күренешләр, гыйшык-мәхәббәт лабиринтлары, күңел багындагы серләр, яхшылыкны зурлау, дин вә әхлакка чакыру, табигатьтәге төсләр-күренешләр... Комсыз-комагай, акча һәм байлык колы булма, кешелек сыйфатларыңны югалтма, кыйблаң дөрес булсын... Уян, татар, дөньяда ирек-азатлыктан да кадерле нәрсә юк, уянырга һәм көрәшергә вакыт безгә... Җыеп кына әйткәндә, Рәис Сафин әнә шундый әһәмиятле темаларны үзенең каләм очына «эләктерә», менә шундый хакыйкатьләрне әйтеп бирергә олтыла, укучысын яхшылыкка, сафлыкка, әдәп бакчасына өнди.

Социаль темаларга кереп, Дума депутатларының баш очында усал «чыбыркы»сын да уйнатып ала ул:

Уен бара парламентта –
Милли үй-хисләр ташый.
Депутатлар тавыш сатып,
Ил сатып акча ясый.

Р.Сафин иҗатында милли шигырьләр күпчелек урынны алып тора дисәк, ялгышмабыз. Ватанпәрвәр һәм граждан рухлы авторның милли темага еш мөрәҗәгать итүен аңлап та, аңлатып та була, чөнки ул татар өчен, аның үткәне һәм киләчәге өчен җан атып, борчылып, патриотик гамь белән яши. Аның болай дип әйтә алган фикри юлларын ничек инде хупламыйсың да, ничек инде йөрәгеңә якын аллмыйсың ди:

Урыс теле – тур башында,
Башка теллэр чүплектә, –
Төбәк компоненты дигән
Шовинистик читлектә.

Дәүләтчелекне кайтару мәсьәләсенә килсәк, автор иҗатында хыялый романтизм чалымнары да юк түгел. Шулкадәрсе ихласый ышанып ул үзен: «Газиз халкым яшәр бәйсез чорларда!» кебек ышаныч белән юатырга да тырышып карый. Миңа калса, хәзергә – миф, әкият бу. Тот капчыгыңны! Татарстан үзенең хәзерге биләмәләре белән Россиянең кыл уртасына, образлы итеп әйтсәк – «ашказаны»на урнашкан. (Биредән юлбары «туры эчәк»кә). Регионнар өстеннән тоталь контроль шулкадәр каты һәм оста оештырылган ки, «азатлык» дип кыл да кыймылдата аллмыйсың. Авызыңны ачтың икән, сиңа «милләтче» яки «экстремист» дигән ярлык тагып, төрмәгә утыртып куюлары да бик ихтимал. (Рафис Кашапов язмышын хәтерлик). Россия империя

буларак сүтелгәндә яки чын федерализм булганда гына безгә чын Азатлык еллаерга мөмкин.

«Толерантлык» дигән шигырендә әдип чәнечкеле уклары кыйбласыз буынга һәм чиновникларга юллый:

Кечкенәдән урыслашкан бала
Түгел инде милләт сагында.
Татарның да манкорт тырәләре
Толерантлык саклау ягында.

Толерантлык – ирек, миллилектән
Ваз кичәргә өндәп котырту.
Толерантлык – илсез вак халыкны
Төп башына алдап утырту.

Минем өчен Рәис ага «офык»та ничегрәк пәйда булды соң әле?.. Ачык хәтерлим: моннан ун-унбиш еллар элек – «Идел» яшьләр журналында эшләгән чагымда танышытык без аның белән. Тора-бара сабырлыгы, кызыклы әңгәмәдәш, тәмле телле һәм уйлы-гамьле кеше булуы белән җәлеп итте ул мине үзенә. Ул да мине туры сүзле, ихлас әңгәмәдәш буларак якын кабул итте булса кирәк. Кыскасы, «җеннәребез» килеште безнең.

Аның сөйләгәннәреннән, язганнарыннан мин шуны ачык аңладым: тормышта һәм дөньяда аны иң нык борчыганы – халкыбызның тарихларда уелып калган ачы язмышы, милләтемнең бүгенге халәте рухиясе. Катнаш никахлар, сибелгән татар катламының күп җирләрдә урыслаша баруы. Менә шушы хәлләргә карата күпчелек кавемнәребезнең битарафлыгы җанын сызлата аның. Китапка «ЖАҢ АВАЗЫ» дигән исем юкка бирелмәгәндер.

Рәис Сафин бер шигырендә үзе турында болай дип белдерә:

Мин шагыйрь дә, язучы да түгел,
Бу шөгыльдә тыйнак һәвәскәр...

Әлеге сүзләрдә күпмедер хаклык булса да, моның белән һич килешмәс идем. Авторның көмеш челтәр белән үрелгән иң яхшы шигырьләре, күңел җимешләре халкыбыз мәнфәгатьләренә хезмәт итә, хакыйкать һәм гуманизмга өнди. Хәер, Рәис ага әлеге куплетның соңгы ике юлы белән үз-үзенә җавап та бирә:

Тик үйларәм тынгы бирми миңа,
Күңелемдә алар – зур гаскәр.

Китапның соңгы өлеше (V бүлек) «Дини мотивлар» дип атала. Дин юлына һәм намазга баскан ил агасының дөртьюллыклары белән танышу, минемчә, өлкәннәр өчен дә, яшь буын өчен дә кызыклы булачактыр.

Форсаттан файдаланып, Рәис Сафин атлы каләм иясенә кайбер киңәш-тәкъдимнәрне дә җиткерәсе килә. Ул татар теле бай булган парлы-парлы сүзләр белән шактый еш мавыгып китә. Әйтик: аң-акыл, боерык-фәрман, җир-туфрак, калеб-күңел кебек сүз «чылбыр»лары – асылда бер үк мәгънәдәге синоним сүзләр ләбаса! Аларны катлы-катлы итеп әйтү шигырь юлларын бизәми, авырайта гына. Әлбәттә, бер куплетка 4-5 парлы сүз «дыңгычлап» тутырылган икән, шигырь һәм тел хасиятенә бары зыян килә, гармония бозыла. Икенчедән, тиңдәш кисәкләр өч тапкыр рәттән саналып китсә, шигырьнең тәме китә, энергиясе югала. Өченчедән, кайбер шигырь үрнәкләрендә «һич килешмә – белешмә дә» ке-

бек кытыршы рифмалар да очрап куя. Автор киләчәктә мондый кимчелекләргә игътибар итсен иде.

Алда әйтелгәнчә, шигърият дигәндә аның күңел капусы бик соңарып, 60 яшьләрдән соң ачылган. Әмма... иҗатка беркайчан соң түгел икән! Ул моны яшәү рәвеше, күңел тирбәлеше һәм иҗаты белән раслап бирде.

Рашат НИЗАМИ,
Ғади Такташ исемендәге
әдәби премия лауреаты.
29 август, 2016ел.

I бүлек



Жир-су, һава, ут-ялкында
Кешелекнең яшәеше.
Изге кыйбласын җуймасын
Уй-фикерең сөреше!

Болгар җыенында

I

Мин изге Болгар җирендә
Гыйбрәтле язмыш күрдем.
Бабамнарның ядкәрләрен
Сыкранып карап йөрдем.

Ун-унбиш гасырлар элек
Төзелгән таш биналар...
Нигез ташлары таралган,
Я тим калып тораlар.

Чиркәү нигезендә ята
Бабамның кабер ташы.
Әйтерсең, чиркәү чатына
Кысылган бабам башы.

Таланганнан, урланганнан
Тиңсез истәлек калган.
Алар безнең күзгә карап,
Я рдәм сорыйлар сыман.

Ишелгән, ауган диварлар
Тик харәбә хәлендә.
Ак пулат, кара пулатлар
Г орур тора әле дә.

Меңьеллык корылмаларны
Тарих тузаны баскан.

Манараларның башлары
Зәңгәр күкләргә ашкан.

Башларындагы айлары
Иман нурлары сирпи.
Әйтерсең, болгар бабамнар
Сәламләп кулын селки.

Керфекләремдә күз яше,
Күңелемдә горурлык:
Болгарыбызның һәр ташы, -
Баш бәһасе торырлык.

Изге Болгар җирен ап-ак
Кыр чәчкәләре сарган.
Әйтерсең, басу-кырлары
Ябынган атлас юрган.

Әйтерсең, бабамнар рухы
Чәчкә булып калыккан.
Шәһит киткәннәрнең җаны
Чәчкәләр булып кайткан.

Әйтерсең, алар җилфердәп
Сәламли оныкларын.
Әманәт итеп тапшыра
Меңьеллык орлыкларын.

Миллион чәчкәләрнең тажын
Талгын җил йөри тарап.

Өйлә намазына басты
Халык кыйблага карап.

Изге теләкләр багышлый
Ата-бабам иләндә.
Илле мең зат сәҗдә кыла
Изге Болгар җирендә.

Дөньяга сибелгән татар
Дәррәү Болгарга килде.
Ата-баба ядкәрләрен
Торгызырга сүз бирде.

Кәһарманнар каны тамган
Бу җирләр – изге җирләр.
Сугыш кырында меңләгән
Ятып калган чын ирләр.

Шәһит киткәннәрнең рухы
Шат һәм догалы булыр.
Халкыбыз Болгар җирендә
Иләһи һәйкәл корыр.

Без тарихта илләр белән
Рухи байлык алышкан.
Бабаларның гамәлләре
Җир-күк белән тоташкан.

Болгар, 18 июнь, 2011 ел.

Милли холык

Кыпчак, татар Иртеш-Дунай арасында
Алтын Урда, Идел-Йорт дәүләтен корды.
Татар булып гомер итү – җиңел түгел,
Ата-баба дошманнарга каршы торды.

Ил-дәүләтле, дан-шөһрәтле ата-баба,
Ут-ялкында, авырлыкта күп сыналды.
Чукындырып, ассалар да, киссәләр дә...
Татар Рухы иманына тугры калды.

Безнең халык җир-күкләрнең сыйфатында,
Табигате белән татар табигатьле.
Җирләр-күкләр һәм табигать мәңгелектер, -
Татарның да гомер чиге шулар хәтле!

Ят илендә татар булу җиңел түгел, -
Көрәшләрдә чыныгадыр милли әһел.
Татар булу – дәрәҗәле, затлы булу,
Горурлыкта, сабырлыкта булсын күңел.

Татар булу – иманыңа инанулык,
Ил-җиреңне, тел-динеңне бул тотарлык.
Иркен-азат Идел-Йортның күк йөзендә
Кояш булып балкып торсын милли холык!

Июль, 2011 ел.

Без – кылычлы милләт

... «Бетте көч, сынды кылыч – шул булды эш:»
Бөек Тукай сыкранып әйткән бу сүз.

Кылыч сына, кеше үлә сугышта, -
Тик халыкның рухы исән буллмышта.

Һәм яшәеш төрлечә дәвам итә,
Кемнең язы, ә кемнең көзе җитә.

Дөньяны әйтәләр күләсә диеп,
Бүген түбән – иртәгә була биек.

Кыйтгаларның ил-җирләрен иңләп без,
Шан дәүләтләр тоткан гаярь милләт без.

Ходай биргән язмышы һәр барлыкның,
Теләгеннән тора фәкать халыкның.

Бу тормышта киртәләр булып тора,
Ләкин халык хөрлектә тормыш кора.

Сынган кылыч – шагыйрьнең дәһшәте ул,
Шул дәһшәткә тотынгандыр безнең кул!

Апрель, 2016 ел.

Каравыл!

«Эттән күбәйде дошманым», – дигән Тукай,
«Ун урнына хәзер унбиш» эт – алабай.

Чит этләргә үз этләребез кушылды,
Әер-өер алар усал аваз салды.

Урыс телле татарыбыз астан тешли,
Газиз башны урыслашканнары ашый.

Тәре таккан ул-кызлары барсын узып,
Телебездән мәхрүм итә канун язып.

Өстебездә кара болыт, уйный давыл,
Котырган этләр улаша... Каравыл!

Уйлашыйк әле!

«Булды юлда киртәләр»... Бүген ул койма,
Татар юлын япмакчы мәскәүле тырма.

Шул тырмага алар безне бастырмакчы,
Татарны булдыксыз итеп калдырмакчы.

Милли хак-хокукларыбызны нык кыса,
Курыкканнар ярыкларга кереп поса.

Әй, татарым, күзеңне ач, башың күтәр!
Изелеп яшәдең озак, инде җитәр!

Котылыйк без бу коллыктан берләшеп,
Ирекне алып була фәкать көрәшеп.

Бар татарның исенә төшерик тарихын,
Алтын Урда, Идел-Йорт дәүләте барлыгын.

Дан-шөһрәтле дәүләтләр тоткан халык без,
Койрык кысып яшәр милләт һич түгелбез!

Чәр-чәр килеп өргән баудагы көчек тә,
Ирек даулый, булса да ул көрчектә.

Ә без – халык. Авыз ачып тик торыйкмы?
Әллә һаман шул көчектәй бәйдә булыйкмы?

Әй, туганнар, канкардәшләр, уйлыйк әле,
Киңәшергә, берләшергә вакыт мәле!

Апрель, 2016 ел.

Вакыт!

Милли җыен, сабантуйлар
Мең еллар белән яшьтәш.
Халкыбызның яшәеше –
Гәрчакта булган көрәш.

Көрәш һаман дәвам итә,
Тик заманалар үзгә.
Ата-бабалар дәүләтен
Торгызу фарыз безгә.

Хөрлек безгә үзе килмәс, –
Көрәштә калсак ятып.
Милли рухыбызны барлап,
Мәйдан тотарга вакыт.

Азатлык өчен көрәштә
Милләтеңә бул терәк!
Сабантуйларда сайрашып,
Берләшү безгә кирәк!

Июнь, 2009 ел.

Үкенечле үтенеч

Әй, татарым, үз кадереңне белеп,
Сөеп кара әле үзеңне.
Нигә һаман күрше тавыклары,
Күркә булып күрнә күзеңә.

Чит-ятларның гореф-гадәтләрен
Үзеңнеке сыман итәсең.
«Горько» сүзен инде «Әче» диеп,
Халкың үзәгенә үтәсең.

Кызларыбыз ярымшәрә калып,
Әверелә мода колына.
Үз гәүдәсен күргәзмәгә куеп,
Охшап кала базар малына.

Оят-намус, күркәм әдәп-әхлак –
Халкыбызның сыйфат билгесе.

Гасырлардан мирас булып кичкән –
Әби-бабай күңел көзгесе.

Мең-мең еллар бөртек-бөртек җыйган
Әманәте алар милләтнең.
Без-татарны затлы халык иткән,
Кыйммәтлесе булыйк өммәтнең.

Үз телебез, үз динебез саклап,
Тик үзебез булып калыйкчы.
Ходай биргән асыл сыйфатларны
Киләчәккә алып барыйкчы.

Июнь, 2013 ел.

Метаморфоза

«Балта биреп шөшле алдым», -
Дип әйткән ди бер юләр.
Юләр дә мөгезле түгел,
Татар шикелле, диләр.

Татар дигән ир-егетнең
Хатыны кяфер-маржа.
Татар исемле кызга да
Тәреле урыс хуҗа.

Маржаның ире – басурман,
Урыс хатыны – «чапый»*.
Татар кияү, татар килен –
Аталалар поганый.

Шул «поганый» килен, кияү
Урыска хезмәт итә.
Дөньяга урыс үрчетеп,
Бар гомерләре үтә.

Кайда татар горурлыгы,
Рухи иман ныклыгы?
Кайда дини әхлагыбыз,
Милләтебез аклыгы?

Юкса, кяфер бу халыкның
Элгәре бабалары, –
Ата-баба башын кискән,
Бүген кисә уллары.

Халкыбызның канын түккән
Бу кавем безгә хәрәм.
Урыс кармагына капкан
Балаларыбыз әрәм .

---

* *Чапый – чаплашка сүзен мыскыллап әйтү.*

Май, 2013 ел.

Үзең хуҗа бул!

Үй-фикерең, гамең бармы синең,
Әйт әле син, газиз татарым?
Телсез, динсез, илсез каласың ич,
Кайда синең гаярь улларың?

Утиләрме ата-бабаларның
Коръән тотып әйткән васыятен?
Дәште – кыпчак, Идел-Йорт җирләре
Берләшсеннәр булып бербөтен.

Алар скиф, һуннар, хазарларның
Әманәтле туган җирләре.
Шул җирләрдә әби-бабай торган, -
Төрки булган ана телләре.

Милләтемнең изге мирасына
Хуҗа булды комсыз бер кавем.
Безнең җирләр, диеп өскә япты
Шовинизм дигән бөркәвен.

Әй син, татар! Даула үз хакыңны,
Орыш-бүлеш барган дөнья бу.
Вакыт җитте газиз ватаныңа:
Син – татарым, үзең хуҗа бул!

Татар халәте?..

Батырларның үлеме марҗадан дип,
Әйткән безнең әби-бабалар.
Татарның да язмышына хуҗа -
Ире татар булган марҗалар.

Үзләренә ирне өйләндереп,
Килен итеп татар кызларын,
Милләтемнең бәгыренә керә,
Әсир итә хаин улларын.

Ата-бабаларның башын кискән,
Канын койган шушы халыкка
Татарымның денсез улы, кызы
Сәждә кыла, калып хурлыкка.

Нәсел каны, ата-баба каны
Чит-ят каны белән бутала.
Катнаш гаиләләрдә туган бала -
Татар өлешеннән буш кала.

Балта биреп шөшле алдым, дигән
Агайларга охшап калабыз.
Үзебезнең балта белән безнең,
Башны чаба манкорт балабыз.

Хак динебез, сихри моңы, көе...
Мәшһүр дастан кебек телебез...
Толерантлык хәйләсенә батып,
Миллилекне жуя йөзебез.

Тәкъдиреңә сылтап, гашыйк булсаң,
Чит милләтнең егет, кызына –
Халкыбызның бәддогасы орыр,
Чыгалмассың гомрең язына.

Октябрь, 2012 ел.

Татарлык билгесе

Динебез кайта читләрнең
Гореф-гадәтен алып.
Асыл затларыбыз йөри
Милли киемсез калып.

Джинсы чалбары өстеннән
Итәксез күлмәк кия.
Башына яулык урый да, –
Мөселман булдым, – дия.

Кайда соң асыл күлмәкләр -
Хатын-кыз хозурлыгы.
Чигүле ап-ак яулыклар -
Татарның горурлыгы.

Юктыр баш түбәләрендә
Татарыбыз калфагы.
Калфак – милләтебез тажы,
Дәрәҗәбезнең багы.

Асыл затларыбыз йөргән
Сәхтиян читек киеп.
Сокланып караган халык
Затлылыкка баш иеп.

Безнең әбиләр яшәгән
Мөселман әби булып.
Җаннарында Иман нуры,
Милли рух торган тулып.

Инде юк чиккән күлмәкләр, -
Күз яуларын алырлык.
Алъяпкычлар аклыгына
Аккошлар таң калыклык.

Әнкәемнең ак яулыгы
Җырларда гына калды.
Каш ясыйк дип, күз чыгардык, -
Милләт йөзе югалды.

...Энҗе-мәрҗәнле калфаклар, -
Милләтебез өлгесе.
Тарих кичкән ак яулыклар, -
Татарлыкның билгесе.

Кан акты*

Тәүлек буе тоташ яңгыр ява,
Күкләр елый, күкләр тишелгән.
Бер мең биш йөз илле икенче ел...
Казан диварлары ишелгән.

Ул чакта да татар илен иңләп,
Карлы яңгыр яуган туктаусыз.
Җирләр-күкләр явыз илбасарны
Итмәк булган элә-танаксыз.

Иңләп-буйлап гөрләвекләр ага,
Ә ул елны ташып кан акты.
Шәһитләрнең изге рухын өреп,
Аллаһ милли татар яралтты.

Яңгыр түгел, күктән таш яуса да
Татар ирек даулар мәйданда.
Таш кыялар эреп юкка чыгар,
Татар каны ташка тамганда.

Яңгыр ява... Гамьле-динле татар
Шәһидләрен ала исенә.
Рәт-рәт баскан халкым җир-күкләрдән
Куәт ала рухи көченә.

---

* 2012 елның 15 октябрендә тәүлек буе корлы-бозлы яңгыр яуды. Котырынып җил дулады. Ләкин халыкыбызның милләтпәрвәр затлары матәм көнен искә алырга Ирек мәйданына җыелды

Уен бара...

Мең биш йөз илле икедә
Татарлар аерылган.
Бер төркемдә – кырымлылар,
Берсе рус яклы булган.

Үзара талаша татар
Калып хур-мәсхәрәгә.
Камай морза кебекләре
Сатыла мәскәүләргә.

Бүген дә төркем-төркемнәр...
Татарның башын ашый.
Телсез, илсез калган татар
Мунчаклы башын кашый.

Башын кашый,
Кыен ашый.
Күз чыгарып, каш ясый.
Мөстәкыйльлек биргән булып,
Мәскәүләр уен ясый.

Уен бара парламентта –
Милли үй-хисләр ташый.
Депутатлар тавыш сатып,
Ил сатып акча ясый.

Дөньяны күләсә, диләр,
Әйләнә ул – чарлана.
Чарланган газиз халкым да
Яшәр бәйсез чорларда!
Иншалла.

Июнь, 2015 ел.

Толерантлык турында

Толерантлык дип җан ата
Татарның бер түрәсе.
Бу тормышта толерантсыз
Яшәп булмый, янәсе.

Коръән чишә алмаганны
Чишмәкче теге түрә.
Милли асылын югалткан
Халкыбыз зыян күрә.

Берьяклы толерантлыктан
Мәстәкыйльлек беткәне.
Халкыбызны мәгърифәтсез...
Ана телсез иткәне.

Толерантлык – миллилектән
Ваз кичәргә котырту.
Толерантлык – вак халыкны
Төп башына утырту.

Толерантлык – шовинистның
Мәкерле яу хәйләсе.
Басып алган ил-милләтне
Итмәк корбан тәкәсе!

Этләр белән мәчеләр дә
Яшәми бер ояда.
Аллаһ һәр кавемне үзгә
Бар иткән бу дөньяда.

Июль, 2011 ел.

Риваять

Хаин татар толерантлыкка сыенып,
Үз нәфесе комсызлыгын өскә куяр.
Халкын сатып, телен-динен, үзен сатып,
Хәрамләшер, сабыйларның яшен кояр.

Телсез калган, динсез калган татарларның
Урыс телле оныклары тәре үбәр.
Милләтенә хыянәтче – бәдбәхеткә
Кыямәттә җавап тотар вакыт җитәр.

Җавап бирер сатлык җаны, фәхеш тәне.
Хак Тәгалә, ата-бабасы каршында.
Юксынудан нәсел-нәсәпләре елар
Табалмагач аны оҗмах бакчасында.

Август, 2013 ел.

Милли корт

Коръән тотып ант итсә дә
«Хак татармын мин» диеп...
Ғаласының исеменнән
Кемлеген була белеп.

Кайсы халык исмен таккан
Кызына һәм улына.
Ул сатылып, шул халыкның
Әверелгән колына.

Заманга җайлашып яши,
Нәкъ хамелеон төсле.
Ул – татарның милли корты,
Ул мөртәт – икейөзле.

Гыйнвар, 2013 ел.

Кем гаепле?

Җитмеш биш яшьлек дин әһеле Мисбах үзен дәвалаучы теш врачының: «Кәләпүшеңне сал», – дип әйткән сүзләренә үч итеп, биш ел буе үзе ясаган мылтыктан атып үтерә.

Утырттылар аны, шәп иттеләр,
Кеше үтерүдә гаеплән.

Изге Коръән кеше үтергәнгә
Ут җәзасы куяр әзерләп.

Җан кыючы Мисбах барсын белеп,
Кануннарның бозган һәммәсен.
Төрмәгә ул үзен хөкем иткән,
Гөм тәмугка белгән керәсен.

Ләкин Мисбах ұң корбаны булып,
Кылган гөнаһ – канлы хур эшне.
«Кәләпүшең сал», – дип әйткән өчен
Үтергән ул атып кешене.

Катгый кануннарның һәркайсында
Үтерүгә җәза уелган.
Үзең чәчеп,үзең үстермәгән
Чәчәкне дә өзү тыелган.

Тик курсәтте Мисбах бу тормышта
Гореф-гадәтләр дә барлыгын.
Милли хиснең, милли горурлыкның
Кануннардан өстен торганын.

Июнь, 2016 ел.

Җаным сыкрануы

Ник бу кадәр маңкортлаштык?
Ник бу кадәр тырыштык?
Телсез, өнсез хәлдә калдык,
Идел-Йортта адаштык.

Әби-баба мең-мең еллар,
Саф татарча сөйләшкән.
Скиф, һун кавемнәр белән,
Килен-кияү бүлешкән.

Төрки телле, ислам динле
Халыклар дөнья тоткан.
Ат тояклары авазы
Кыйтгаларга тоташкан.

Без шул шанлы халыкларның
Хак-шәрәфле варисы.
Әманәтне хыянәтсез
Үтәү – татар бурычы!

Маңкортны кадаклау кирәк
Хурлык баганасына.
Милләттәшләр, ягыллмагыз,
Маңкортлык карасына!

Июнь, 2016 ел.

Өмет баглау

Әнисе итәген тотып,
Аякка басты сабый.
Иңнәрен киереп әнә
Аллаһка өмет баглый.

Тәүге сүзен «әннә», диеп,
Туган телендә әйтте.
...Милли-дини тәрбиядә
Гаярь ир үсеп җитте.

Инша Аллаһ, татар җанлы
Булыр ул милләтпәрвәр.
Азатлык өчен көрәштә
Каһарман, кыю сәрдәр.

Шундый фидакарь затларны
Халык биш йөз ел көтә.
Ата-баба дәүләт тоткан
Чорларны өмет итә.

Җир-күкләр фатиха бирер,
Җанда иман нурланыр.
Алтын Урда, Идел-Йортлы
Татарны илләр таныр.

Август, 2016 ел.

Өмет

Илне-җирне кара болыт каплап китте,
Милләтебез актык чиккә килеп җитте.
Ай, Кояшсыз һәм яңгырсыз яшәүләрдән
Чүлдә үскән кылган сыман корып кипте.

Хак кыйбласын җуйган татар манкортлары
Толерантлык базарында үзен сата.
Илсез, җирсез, телсез калган денсез татар,
Хөр-иректсез һәм ваемсыз яшәп ята.

Телен тешләп толерантлык саклый татар,
Икенче сорт халык булып гомер итә.
Ислам динле, ана телле, милли моңлы
Ил-җиребез кануни хуҗасын көтә.

Әби-бабай меңь-меңь еллар кыр-далада
Кыйтгаларны иңләп-буйлап гомер иткән.
Ил-җирләргә белем һәм мәгърифәт илткән,
Дан-шөһрәте дөнья буйлап ерак киткән.

Без – борынгы скиф, хәзәр дәвамында,
Һун, пәчәнәк, сармат рухы безнең җанда.
Шан-дәһшәтле дәүләт-каганатлар тоткан,
Болгар, кыпчак өлеше бар безнең канда.

Әй, татарым, нәсел-нәсәбеңне барла,
Аллаһ язган мәңгелегең көтә алда.
Дәүләт тоткан, дәүләт тотар горур халкым –
Башын имәс дошманнарга һичкайчан да!

Май, 2013 ел.

И, мокатдәс туган телем!

Атлар кешни, этләр өрә, кошлар сайрый,
Барысы да үз телендә аралаша.
Сәер булыр – кошлар өрсә, эт кешнәсә,
Әгәр атлар кошлар кеүк сайрый башласа.

Тик татарда сәер хәлләр гаҗәп түгел,
Татар белән татар сөйли урысча гел.
Татар теле – дәүләт теле аталса да,
Татарның ул үги теле – бичара тел.

Меңнең-меңнең еллар ата-баба сөйләшкән тел
Кирәк түгел хәтта авыл баласына.
Әби-чәби, бабай-агай тел сындырып,
Русча дәшә нәсел булып каласына.

И мокатдәс ана телем, газиз телем,
Коръән сүзле, әлифбалы милли идең...
Державаның сәясәт корбаны булдың...
Пыскып янган учакларга охшап калдың.

Ләкин атлар-кошлар булып сайрамачак,
Кошлар өрмәс, кешнәмәсләр һич этләр дә.
Тел – Аллаһның мәңгелек акыл бирәге,
Ул калачак милләтпәрвәр иңсәләрдә!

Кыямәттә Аллаһ безләргә эндәшер
Мөэмин-мөселман кавемнәре телендә.
Телен хурлап, үзен зурлап йөргән адәм
Курчак сыман телсез калыр суд көнендә.

Август, 2013 ел.

Җитәр вакыт...

И татарым, байтак ялгышлыклар кылдың,
Милләтеңә чөнки син битараф булдың.
Варисларың бисмилласын әйтә белми,
Чукынырлар урыс телле оныкларың.

Синең инде нәсел-нәсәбең дә бетәр,
Оныкларың чиркәүләрдә тәре цәр.
Үлермен дә котылырмын дип уйлама,
Аллаһыга җавап бирер вакыт җитәр.

Июль, 2013 ел.

Исеңдә тот!

Өзгәләнмә паспортыңда
Язылмаса милләтең.
Асылың кәгазьдә түгел,
Өлмәтеңдә кыйммәтең.

Сандугачның милләте юк,
Тик белә һәммә кеше.
Аның моңлы сайравыннан
Гүшсыз кала бер ише.

Дуңгыз да милләтсез калган,
Ул да исемсез-сансыз.
Дуңгыз дуңгыз булып калыр...
Чөнки дуңгыз имансыз.

Мәсьәлә иселмдә түгел,
Иң мөһиме – җиселмдә.
Милләтең татар икәнен
Һәрвакыт тот исеңдә!

Июль, 2013 ел.

Нигә шулай?

Горур дибез, мактый, мактанабыз,
Милләт җанлы дибез татарны.
Кем дип атыйк, катнаш гаилә корып,
Милләт мәнфәгатен сатканны?

Ир-егетләр марҗа кочагында,
Хыянәткә кереп, җан сата.
Кызларыбыз егетләрне узып,
Тәре такканнарны ярата.

Татар кызы, татар егетләре
Ник үзара никах корышмый?
Егет кызны, кызлар егетләрне
Ник эзләми, нигә табышмый?

Ат кешнәшеп, ә этләр иснәшеп
Табышалар, кирәк булганда.
Эт бүрене, атлар да ишәкне
Пары итми нәсел корганда.

Хайваннар да, кошлар, балыклар да,
Үз каныннан нәсел калдыра.

Кош-корт – оя, бүреләр өн кора,
Гәр тереклек тормыш булдыра.

Катнаш гаилә – сыныкка сылтау ул,
Үзләштерү башка халыкны.
Тик берәү дә яулап ала аллмас,
Күңелдәге милли холыкны.

Июнь, 2013 ел.

Татар аты

Атлар чаба! Кешнәү авазлары
Кайтарылып төшә болынга.
Тояк тавышлары сөйли кебек
Шанлы тарихыбыз турында.

Атлар чаба. Гәм тузгыта алар
Борынгыдан калган чорларны
Атлар белә һәм аңлыйлар бугай
Бабайлардан калган моңнарны.

Атлар чаба туган туфрак буйлап,
Елга-күлләр, урман буена.
Ил атлары йөргән урыннарда
Чит ил ишәкләре туена.

Тышау салып, ятлар үз дигәнчә
Тотмак була атлар чирүен.
Атлар көтә илдә таң атуын,
Гаярь ирләр килеп җитүен.

Ата-баба яккан учакларның
Гаман әле балкый утлары!
Очкыннардан күтәрелеп чыга
Бик борынгы татар тулпары.

Атлар чаба – киләчәккә таба,
Олы юлның куба тузаны.
Мәйдан тотар ярсу атлар кирәк -
Утны-суны кичә торганы...

Апрель, 2009 ел.

Иреккә сусау

Заставада ярсу бер кырыкмыш,
Озак торган бикле аранда.
Табыллмаган аны иярләргә
Тәвәккәл ир-солдат арада.

Кыбырсынып, биеп торган уйнак
Үз җайдагын көткән зарыгып.
Мине дә ул, ярын көткән заттай,
Көтеп ала иде сагынып.

Ияренә менеп утыруга
Тотына ул ярсып чабарга.
Туктатуның берәр чик-әмәлен
Кирәк иде миңа табарга.

Авызлыклыйм. Тезгенемне тартам,
Өзәнгегә терәп аякны.
Кырыкмышым томырылып чаба,
Чак тотынып калам шул чакны!

Чик буйларын урап чаба торгач,
Чара таптым мин дә чаяга:
Кушаяклап чапкан айгырымның
Терәп куям башын кыяга.

Тик айгырым минем бу тозакның
Тиз арада тапты ачкычын.
Сыртыннан ул мине ыргытты да,
Очып үтте кыя баскычын.

Ул юк булды. Тауларга качты,
Әллә инде күкләргә ашты?..

Декабрь, 2013 ел.

Безнең татар

Каргыйбыз без, Иван явыз дибез,
Рәнҗүебез аңа ихластан.
Ә чынында – гаепләрне эзлик, –
Тирәләре сатлык ханлыктан.

Петрга да каһәр бәддоганы,
Ләгънәтләрне мулдан юллыйбыз.
Ә нигә соң кардәш төркиләрдән
Аерылган безнең юлыбыз.

Сораулар күп, ләкин җавапларны
Әйтә аллмас беркем тәгаен.
Татар иле азат яшәр иде...
Таный белсә әгәр гаебен.

Күрә белсә, әгәр сөйли белсә,
Күңелендә ниләр барлыгын...
Татар өчен Рәсәй кануннары,
Милли сәясәттә тарлыгын.

Нигә татар һаман кими бара?
Кая китте безнең милли хис?
Милләтләрнең рухи җанын йолкып,
Шовинизм сакта тора ич.

Мәктәпләрдә дин сабагы диеп,
Кяфер динен алар укыта.
Ә татарның динсез хәзрәтләрен
Дини берләшмәләр куркыта.

Авылларда татар мәктәбенең
Ишегенә йозак салына.
Ана телен өйрәнмәгән бала,
Чит ояда канат кагына.

Кечкенәдән урыслашкан бала
Түгел инде милләт сагында.
Татарның да манкорт түрәләре
Толерантлык саклау ягында.

Борынгыдан килгән бу гадәтне,
Тарихны без яхшы беләбез.
Үткәннәрне татар түрәләре
Гамәлендә ачык күрәбез.

Әйтерсең лә биш йөз еллык гомер
Эз саллаган татар холкына.
Түрәләре шул ук куркак җаннар,
Арты белән баскан халкына.

Табан ялый татар түрәләре,
Алар шул ук оста ялагай.
Берсен-берсе узып байлык җыя, –
Алар саран, алар комагай.

Милләт гаме, милләт мәнфәгате
Борынгыдан булса гамәлдә, –
Үз иленә, үз җиренә үзе
Хуҗа булыр иде һәр мәлдә!

Иван явыз, Петр кансыз, дибез,
Чукындырган дибез татарны.
Сатлык түрә болардан да яман,
Нишләтергә икән аларны?

Май, 2011 ел.

Булма гафил!

Һәр кавемдә гыйбадәтле урыннар бар,
Халык барып Коръән укый мәрхүмнәргә.
Искә ала ата-баба үткәннәрен,
Әманәтли бу мирасны бүтәннәргә.

Мәселманның зәм-зәм сулы Кәгъбәсе бар,
Иң мөкатдәс кадерле Мәккә җирендә.
Дөньядагы мөэминнәрне берләштереп,
Саф иманлы өммәт итә һәр төрен дә.

И кардәшем, дөньялыкта яшәгәндә,
Исламның биш фаразын кыл. Булма гафил!
Корбан чалган, ихластан хаҗ кылганнарга
Аллаһының җәннәтенә булыр хак юл.

Май, 2014 ел.

Табигыйлек

Тышта давыл котырына, буран дулый,
Өереп кар бөртекләрен җиргә сылый.
Киерелеп баскан шайтан таягында,
Февраль җиле үги бала сыман елый.

Чүп үләннең кырауларга исе китми,
Курыкмый шайтан таягы да бураннан.
Һәселләрнең җирдә яшәү озынлыгы, -
Туган җирдә тамырлары нык булганнан.

Сентябрь, 2011 ел.

Орлыксыз башак...

Җәйләр үтте, көзләр җитте,
Бозлы яңгырлар яуды.
Төп кануныбыз да – кысыр
Болытка охшап калды.

Җил-давыллар куып йөрткән, -
Ул гүя сәяхәт болыт.
Кояш нурларын үткәрми,
Күкләрдә пәрдә булып.

Исеме бар, җисеме юк, –
Тел җуйган татар сыман.
Маддәләр кыйбла югалткан,
Манкортлар кебек калган.

Канундагы: мөстәкыйльлек,
Суверен дәүләт сүзен...
Монафикълар ят иткәннәр,
Ил-җирнең милли йөзен.

Хак-хокуксыз, кан һәм җансыз
Булаллмый канун терек.
Ул хәзер – орлыксыз башак,
Җелексез сөяк кебек.

Ноябрь, 2012 ел.

Кардәшкә эндәшү

Күкне – ата, Җирне – ана диләр,
Шөкер, бар үз ата-анабыз.
Җирдән-күктән, эти һәм әнидән
Бу дөньяда яшәү алабыз.

Әби-бабам, мең-мең еллар буе,
Милли рухын чарлап яңарткан.
Татар булып мәңге яшәешен
Ислам дине белән ныгыткан.

Аллаһ сүзе безнең телгә күчкән,
Болгар халкы дингә бирелгән.
Изге диннең асыл сыйфатлары
Тормышыбыз белән үрелгән.

Акыл ала халкым үткәненнән,
Коръән төпкелленнән – хикмәтне.
Ата-баба, эти-әниләргә,
Динебезгә булыйк рәхмәтле.

Әсин, кардәш, күзең карасыдай
Саклыйсыңмы халкың мирасын?
Җир-күкләрнең, эти-әниләрнең
Әманәтле изге догасын?!

Сентябрь, 2013 ел.

Уяна!

Юк инде!.. Кылыч сынды дип,
Туктап калу – җинаять.
Татарның чын татарлыгы
Уяна бит, ниһаять!

Кылычы сынган затларның
Акылы җаен таба.
«Көчле берне еккан чакта,
Белемле меңне ега».

Бүген урыс дәүләтендә
Татар – акыл иясе.
Татар тормыш рәвешендә
Татулык идеясе.

Милләтем сабантуйлары
Дөньяны иңләп килә.
Татар толерантлыгына
Кыйтгалар башын ия.

Кемгәдер ул дәрес бирә,
Кемнедер көнләштерә.
Ә безгә рухи көч бирә,
Дәртләнеп көрәштерә.

Тик һаман шиңә барабыз
Тамырларыбыз корый.
Милләтем күзәнәкләре
«Тел» дигән кодрәт сорый.

Июнь, 2015 ел.

Соңгы чара

Көпчәкләр дә изеп китә аны,
Тояклар да басып имгәтә.
Баскынчылар һаман таптап тора,
Сабакларын өзеп тилмертә.

Ил-җирендә үскән татарникның*
Җәрәхәтле тәне талана.
Чәчәкләрен явыз йолкып ала,
Яфраклары аска салына.

Җир-Күкләрнең рәхим-шәфкатеннән
Сихәтләнеп китә кайчакта.
Җир катламын үтеп, тирән китеп,
Тамырларын җәя туфракта.

Халкыбыз да шул татарник сыман
Афәтләргә дучар ителгән.
Гәләкәттән исән калу өчен
Чит илләргә күплән сибелгән.

Бик тырышып, хәләл эшләсәк тә,
Рейстагларга әләм элсәк тә...
Илсез-җирсез ятим хәлендә без –
Язмышыбыз хәтәр элмәктә.

Ятимнәрне сөймәс үги ана,
Үги ата кагар уң-сулга.
Әнә ватан, үксез балаларын
Чит-ятларга асрамага бирә,
Тел-лөгатьсез ата-анага.

Без дә илдә артык кашык булып,
Хак-хокуксыз була барабыз.
Татарниктай мәхрүм калмыйк дисәк,
Инкыйразга дучар булмыйк дисәк, –
Мәйдан тоту – соңгы чарабыз.
Тик шул чакта исән калабыз.

---

* *Татарник – шайтан таягы дигән үсемлек.*

Июнь, 2015 ел.

Көрәш өлгесе

Әзелгән яфрак шикелле
Җирдә аунап ятмабыз.
Кылыч сынса да, көрәштә
Егылып сынатмабыз.

Хурлык булса да,
Чигендек.
Әмма да таркалмадык.
Чигенү –
Җиңелү түгелен
Мәйдан тотып аңладык.

Татарның билендә – билбау,
Кулларында – сөлгесе.
Мөстәкыйльлекне торгызу –
Булыр көрәш өлгесе!

Июнь, 2015 ел.

Тураеп бас!..

Халкым кебек, мин чарасыз калган,
Еллар кичкән гади бер картмын.
Гомерем буе бер уй тынгы бирми:
«Ник илемдә илсез калганмын?»

Әй татарым, юкка чыгабыз ич,
Язгы кардай эри барабыз.
Зур дәүләтләр тоткан халык идек...
Көлтә-көлтә нигә ауганбыз?

Баскынчылар берәм-берәм җыеп,
Орлыкларын җыя көлтәнең.
Сабагын да үзенеке итмәк,
Җелегенә үтмәк җилкәнең.

ЕГЭ дигән мәкер уйдырмасы
Милли канатларны каера.
Милләтемнең егет һәм кызларын
Ана телләреннән аера.

Указ биреп, милли компонент дип
Бугаз төбенә басалар.
Оптимизация дигәннәре белән
Хак-хокукны, телне кысалар.

Әй татарым, күтәр горур башың,
Тураеп бас, ныгыт билеңне!
Беркем сиңа бүләк итеп бирмәс
Идел-Йортлы изге җиреңне!

Июнь, 2015 ел.

Уйланыйк әле, кардәшләр!

Берлек дибез... Бердәмме без?
Бер фикердә, уйдамы?
Милләт гаме, күңел күге...
Тормышыбыз җайдамы?

Космополитизм чире
Халкыбызга йокмасмы?
Глобальлек аждаһасы
Безне кабып йотмасмы?

Милли хиссез татарымны
Никахсызлык аздыра.
Хаксыз брак, катнаш гаилә
Милли юлдан яздыра.

Бисмилласыз егет-кызлар –
Одноразовый товар.
Сафлыгын җуйган БУ*лар
Үзедәй ишләр табар.

Гыйффәтлеген югалтканның
Җан-тәне бушап кала.
Гомер буе кораксыган
Мичкәгә охшап кала.

Берәүләргә бик тә кирәк
Безне тунап таркату.

Асыл сыйфатларыбызга
Үтә дә мөһим кайту.

Ә яшьләр – безнең киләчәк,
Шуларда бөтен өмет.
Дини әхлак, гореф-гадәт,
Милли рух булсын берҗк.

Сафларыбызны ныгытыйк,
Берлектә бердәм булыйк!
Милләтебезгә язылган
Кыйбла юлыннан барыйк!

**БУ – бывшие в употреблении.*

Июль, 2015 ел.

Мин – татармын!

Бар иткәнсең мине, илаһи зат!
Башым иеп әйтәм рәхмәтне.
Яшәү дигән могҗизаны күрдем, -
Җир йөзендә булган җәннәтне.

Рәхәтен дә, михнәтен дә гиздем,
Тыелганга кайчак үрелдем.
Тормыш дигән диңгез дулкынында
Күбекләнеп ярга сөрелдем.

Ләкин Күкләр мәрхәмәтле булды,
Җир-әнкәбез сөйде иркәләп.
Инде дөнья белән хушлашырга
Үз вакытым килә «ирмәләп».

Язмышыма һич тә өлкәләмим,
Халкым белән өзлексез гомерем.
Үзем булып рухи сүзем кала,
Утлы күмер булып – шигырем.

Тик таңнарда бик еш моңсуланып,
Сагынамын гаярь чакларны.
Сагышларга ирләп сарыламын,
Юксынамын асыл затларны.

Колагымны куеп мин тыңлыймын,
Тирбәләмен татар моңында.
Халкым кебек, күркәм туган телем
Зеңләп тора күңлем кылында.

Горурланам татар булуыма,
Шул сыйфатта китәм дөньядан.
Аллаһ кушса, фәкать татар булып
Туар идем җирдә яңадан.

Декабрь, 2013 ел.

Ерактан килгән аваз

Колагымда мең төрле шау,
Мең төрле моң яңгырый.
Ғаләмнәрдән аваз килә,
Ғасырлар күзгә карый.

Ата-бабам эндәшә күк
Алтай далаларыннан.
Урман булып шаулый аваз
Енисей буйларыннан.

Хәлне сорап аваз сала
Изге Болгар җирләре.
Аваз сала дәүләт тоткан
Алтын Урда ирләре.

Ғәммәсенең соравы бер:
«Мирасны саклыйсызмы?
Татар дигән дан исемне
Тормышта аклыйсызмы?

Халкыбыз исән-имин ме,
Ил-җиребез ни хәлдә?
Дәүләт канатларын җәя
Телле һәм динле мәлдә!»

Чи дияргә дә белмәдем,
Дөресен әйтү – оят:
Хатын-кызлар кәфер коча,
Маржа куйнында ир-ат.

Июнь, 2015 ел.

Җан авазы

Син дә татар, мин дә татармын,
«Ләкин башкаеңны сугып ватармын», -
Әгәр дә син оныткансың икән
Туган телне һәм дә Ватаның.

I

Әй татарым! Тыңла әле җан авазым,
Сине сөйгән милләтпәрвәр мин бер улың.
Өзгәләнәм – кайгы-хәсрәт килсә мәгәр,
Чәчәк атам, шатлыкларың булса әгәр.

Тик кояшлы, аяз көннәрең аз синең.
Биш йөз елга сирәк килде якты язлар.
Гаваларда карчыгалар оча һаман,
Исән кала козгыннардан тик бик азлар.

Капкастыннан шуышып йөргән этләр дә,
Койрыкларын кысты боты арасына.
Бәйдә торган усаллары койрык болгый
Эттән явыз хуҗасына ярасынга.

Төн эчендә кеше тәнен тишеп үткән
Бамбук сыман сатлык җаннар калкып чыкты.
Камай кебек, Шаһгалидәй мәртәт бәкләр
Дошманнарга шәһри Казан серен ачты.

Золым белән, хәйлә белән илбасарлар
Ханлыкларны бер-берсенә каршы куйды.

Бөрәңләрне сатып алды, ә күпләрне
Кан елгалары агызып дәррәү суйды.

Татарларның бер-береннән көнләшүен,
Хөсетлеген дошман оста файдаланды.
Үзара талашып яшәгән кавемне
Аркан белән кол итеп бә йләп куйды.

Бәйләп куйды! Аяк-кулга богау салды,
Бөрәңләрне кол итеп базарда сатты.
Кайберләрен хак диненнән яздырды ул,
Бөрәңләрне тере килеш утта якты.

II

Әй кардәшем, кайгыларны берләштергән
Ил-дәүләтле, каганатлы халык идең...
Дастаннарны таң калдырган ак бүреле,
Иңле-буйлы далаларның шаһы идең.

Кем уйлаган мәсхәрәгә калырсың дип,
Илең-җирең – бабаңнарның уч төбе бит.
Илбасарлар хәзер хәтта үз җиреңдә
Мәчет салыр урын бирми: "диаспор", дип.

Син шуларга ил-дәүләтләр төзеп бирдең,
"Үзара тату гына яшәгез", – дидең.
Дәүләтләрен торгызырга, ныгытырга
Иң булдыклы морзаларыңны күндердең.

Тырыштылар алар татар сыйфатында,
Башкардылар үз эшләрен кылып файда.
Бүләкнең дә дәүләтиләрен алдылар...
Тик исемсез һәм җисемсез дә калдылар.

Илен сатып, үзен сатып, динен сатып,
Татар-морза әверелде монафикъка.
Муенына тәре тагып, үз татарын
Кылыч аша үткәрүче опричникка.

Казан, Кырым, Касыйм, Себер ханлыгына,
Нугай Урдасына алар яуга чыкты.
Иң явыз башкисәрләрне дә уздырып,
Кардәш-ыруларының башларын чапты.

Биш йөз татар тирә булып, корал тотып,
Данга күмде, күккә чөйде ятлар илен.
Язучы-шагыйрьләр, галим голәмәләр...
Туган теле итте илбасарлар телен.

Яу кырында дан казанды денсез татар,
Генералиссимус булды хәтта берсе.
Рәсәй илен баскыннардан саклап калды
Минин дигән татарның гаярь кешесе.

Илең сатып, үзең сатып, динең сатып,
Хыянәтче татар, әйтче! Син ни оттың?
Җир-күкләрнең хак мөэмине-мөселманны
Тәре таккан кяфер-мөшриккә алыштың.

Каннар коеп, башлар кыеп, мөртәт булып,
Ғаскынчыга мал табыштың, дан табыштың.
Син Аллаһтан, халкың, ил-җиреңнән киттең –
Айбалтаңны кәкре шөшлегә алыштың.

Даның да юк синең, нәсел-нәсебең дә,
Исемең дә мәсхәрә-хурлык тамгасы.
Ғулсаң да син чит илнең хәтта патшасы –
Шәҗәрәңдә калды хаин атамасы!

Хәтерләүне юктыр сине Кеше итеп,
Ғагышлаучы изге дога истә тотып.
Кардәшләрең ләкин исләрендә саклый,
Телгә ала бәддогалап, ләгънәт укып.

Сатлык җанга каргыш юллый фәрештәләр,
Ата-баба каһәре дә берчак сугар.
Монафикъка Хак Тәгалә җәза бирер –
Тәмугъларның дәһшәтлесе аны йотар.

Йә әйт, Хаин! Шуллмы цтәц бурычыңны?
Кайтарумы ил-халыкка әҗәтеңне?
Аллаһыны, җир-әнкәне саттың икән –
Ғичберәц дә кирәксенми хаҗәтеңне!

III

Илдә чыпчык цлми, дигән борынгылар.
Исән-имин яши безнең тырыш халык.

Җан ярабыз каны һаман саркыса да...
Чын татарны саклап тора милли холык.

Тик, кызганыч, язгы боздай ул да эри,
Милли мәгарифсез татар телсез кала.
Гәлакәтнең чоңгылына чума бара.
Кирәк кыю, тәвәккәлле кискен чара.

Ил-дәүләтнең шовинистик әнчекләре
Мәкер белән зәһәрләнгән хәйлә кора.
Аждаһадай бөекдержавачыл чоңгыл
Берәм-берәм халыкларны йота тора.

Хак юклыктан, шул хәлиткеч чараларны
Газиз халкым кыла аллый газап чигә.
Иректән ул ваемсыз, ул битараф,
Чигә болай без хокуксыз туган илдә?!

Без һаман да ялганнарга ышанабыз,
Явызларның кармагына ник кабабыз:
Авызыбыз һаман саен пешеп тора,
Пешкән саен цҗәтләнеп ник кабабыз?!

Ә балыкчы кармагына "җим" не элә!
Хәйләнең дә мәкерлесен җайлап кора.
Ил канунын цзе өчен корбан иткән –
Ул цзе дә корбанлыкта чират тора.

Бу дөньяда бернәрсә дә бакый түгел,
Яшәеш тә, фасыллар кук, цзгәреш тә.

Оясында ни күрсә ул – очканында
Тормышын да дәвам итәр шул рәвештә.

Тиктомалдан гаепләмик без язмышны,
Төрле хәлләр булып тора бу тормышта.
"Үзе егылган – еламас", – дия халык,
Без үзебез булып калыйк һәр буллмышта.

Үзебезнең кем һәм нинди икәнлекне...
Дөреслекне белсен бала дәреслектә.
Халкы белән, үзе белән горурлансын,
Горур кеше, кол булса да – бәйсезлектә.

Азатлыкка тик горурлар дәгъва кыла –
Горурлыгы булган халык азат була.
Толерантлыкта алданып яшәүчеләр –
Ил-җирендә мескен була, нәүмиз була.

Бу дөньяда бернәрсә дә эзсез үтми,
Тарихтагы хаталардан гыйбрәт алыйк.
Дөньялыкта әгәр яшәп калыйк дисәк –
Балаларны туган телдә тәрбиялик.

Үз халкының кем икәнен күрсен, белсен,
Шул халыкның шанлы гүзәл тарихы бар.
Чит җирләрне басып алган бу ватанда
Дәште-Кыпчак, Идел-Йортлы дәүләте бар.

Ялган тарих уйлап табу кирәк түгел,
Дөреслекне әйтү кирәк татарларга.

Халкыбызның күркәм асыл сыйфатлары
Балкып торсын буыннардан-буыннарга!

Татарларым! Тыңлагыз сез хак сүземне,
Үзебезне ил хуҗасы итеп таныйк.
Гүн Атила изге васыятьләрен үтик:
Тату яшик, бергә булыйк, бердәм булыйк!

IV

Әй татарым! Язганнарым чын күңелдән,
Сөйләгәнем – өзгәләнгән җан авазым.
Кардәш-ыру таркау чакта оялаттык
Җиребездә бу дөньяның иң явызын.

Бу тормышта мәкер дә бар, хәйлә дә бар –
Гәммәсен дә файдалана залим затлар.
Хамелеон ялганнарына ышана
Ихлас җанлы, пакъ күңелле безнең татар.

Ялтыраган һәрнәрсә дә алтын буллмас,
Гәр әйтелгән сүз дә хак-хакыйкать түгел.
Акыл белән, зиһен белән, хикмәт белән
Хакыйкатькә ирешә тик зирәк күңел.

Гәр гамәлне бисмиллалы башласаң тик
Китерер эш хуҗасына табыш-файда.
Бу дөньяда гамәлсез дә яшәп буллмый,
Булсын эшең бер тәртиптә, бер уңайда.

Тик, кардәшем, булма ләкин син беркатлы,
Тормыш цзе бик катлаулы, катлы-катлы.
Булсаң да син мең мәртәбә дөрес, хаклы –
Көчлеләрнең мал-мөлкәте булыр хаклы.

Җиде тапкыр цлчәп, тик бер тапкыр киссәк,
Арабыздан җил дә цтмәс, булсак бердәм.
Чит кавемнең яман, хәрам гадәтләре
Таркатадыр безне, мотлак, эчебездән.

Алар йогып һәлакәтле сырхау кебек,
Сау-сәламәт рухыбызга зыян сала.
Күңеленә, сафҗанына бозык кертеп,
Татарымның татарлыгын басып ала.

Ләкин өзмә өметеңне, чын татар бул!
Үз дәүләтең, цз җирең бар, чикмә нужа.
Яһуд халкы ике мең ел җәфаланды,
Бүген, әнә, ил-җиренә цзе хуҗа.

Милли холык, гореф-гадәт һәм йолалар...
Хак динебез безне мәшһүр халык иткән.
Ата-бала ихлас гыйбадәтле булып,
Аллаһының рәхмәтендә гомер чиккән.

Скиф, һуннар, хәзәр, кыпчак, болгар безгә
Мирас иткән тел дигән тиңсез байлыкны.
Әманәтле хәзинәне саклар өчен
Вәкаләтле вәкил иткән татарлыкны.

Безнең телдә – төрки кавемнәрнең теле,
Безнең төстә – төрки теллеләрнең төсе.
Өстебездә борынгылар әманәте –
Хыянәтсез үтәү безнең намус эше.

Әй татарым! Хаталардан гыйбрәт алып,
Басыйк тыгыз сафларга без рәт-рәт булып.
Динебезне, моңыбызны, үзебезне...
Саклыйк яман гадәтләрдән арындырып!

V

Бу дөньяның яхшысы бар, яманы бар,
Иманлысы, имансызы – җан иясе.
Ахирәттә гамәл дәфтәрләрен тотып,
Аллаһының алдына булыр киләсе.

1-10 гыйнвар, 2016 ел.

Бер кыйтга

Бу кадәрле гамьсез битарафлык
Каян килде сиңа, татарым?
Тараканнар кебек посып калдың,
Шуллмы синең татар булуың?

Юкса скиф, хазар, һун бабалар
Безнең кебек денсез буллмаган.

Кыйтгаларны кушып яшәгәннәр,
Ил-җирләрне иңләп буйлаган.

Без аларның кардәш варислары -
Дәвамчысы кандаш токымның.
Синнән, миннән – һәр татардан тора
Яшәеше чорлар халкының.

Сентябрь, 2013 ел.

Албасты

Бисмилла әйтмәгән булган
Йоклар алдыннан татар.
Дин-догасыз бу бәндәне,
Явыз албасты басар.

Борын куышының берсен,
Йә икенчесен каплый.
Тончыга татар – һич кенә
Сулыш алыр җай таплый.

Авызын томалап куя –
Өне чыкмасын, диеп.
Албасты шат, бу адәмнең
Тынсыз калганын күреп.

Ул терсәктән канлы кулын
Татарга саллмак булды.

Алланың кәһәре сукты –
Үзе җан тәслим кылды.

Уянды татар, явызны
Өстеннән алып атты.
Офыкларда нур балкытып,
Татарның таңы атты.

Май, 2014 ел.

Давыл хәбәрчесе

Өзгәләнеп сүзең әйттең,
Ачтың милли яраны.
Уяттың син гамь-ваемсыз
Биш йоклаган ил-йортны.*

Ирек мәйданында калып,
Ирек өчен ач тордың.
Идел-Йортны торгызуда
Байрактан алда булдың.

Шуңа карагуһчылар
Болыт булып ябырылды.
Ярты-йорты ирекнең дә
Шәүләсе генә калды.

Җил-давыллы көннәр алда,
Вакыт куар болытларны.
Халкыбыз зарыгып көтә, -

Фәүзиядәй каһарманны,
Бәйрәмовадай татарны!

**Казан, Кырым, Себер, Касыйм ханлыклары һәм Ногай Урдасы дәүләтләрен күзаллап.*

Июнь, 2015 ел.

Җавап

«Аерылганны – аю, бүленгәнне – бүре
Ашар», – дигән борынгылар нык кисәтеп.
Гүя бабабыз: «Бердәм булыгыз!» дип әйткән,
Бердәмлекне тал чыбыгында күрсәтеп.

Бөек Кубрат балалары юл чыкканда,
Истә тоткан Аксакаллар әйткән сүзне.
Әермәдәй ябырылган дошманнардан
Зарур булган саклап калу милли йөзне.

Без – Татар, Болгар, Балкар бүгенге көндә,
Өч туганның нәселләре яши җирдә.
Туганлыкның чыбыкларын бәйлик бергә,
Үтә аллмас арабыздан хәтта җил дә!

Февраль, 2013 ел.

Тартыш бара...

Бер очында бауның – ерткыч нәфес,
Оятсызлык, золым, явызлык.
Бер очында – Галиҗәнап намус,
Патшалар да таҗын салырлык.

Тартыш бара катгый! Гәр ике як
Бауны тарта барлык көченә.
Алла ярдәм бирсен – хакыйкатьне
Өлге иткән гаярь кешегә.

Яхшы – яман, ялган белән хаклык
Тормыш мәйданында көрәшә.
Ә залимнәр купшы сарайларда
Мал-мөлкәтен илнең бүлешә.

Җаннар кыеп, каннар коеп алар
Тарткалаша эттәй котырып.
Мал-мөлкәтне булдыручы гавам
Төп башына кала утырып.

Гәлакәтле булган бу тартышны
Читтә торып Иблис күзәтә.
Вәсвәсәгә баткан адәмнәрнең,
Ялгышларын тормыш төзәтә.

Бу тартышта беркем читтә түгел,
Шул тартышка карап уй корам:
Кай очында бауның син торасың?
Хак очында аның мин торам!

Февраль, 2007 ел.

Татар язмышы

(Атлар елына)

Дүрт яшемдә битемә ат типкән,
Кырык көнгә миннән аң киткән.
Гәм кырык көн авыл зиратында,
Казып куйган кабер-йорт көткән.

Ғәлакәткә мине дучар иткән -
Яратмаска, бәлки, атларны?
Тик сокланып, ихлас күңелемнән
Сөеп гомер итәм аларны.

Балачактан инде җәйге төндә
Болын-тугайларда ат көттем.
Тугры атым белән чик сакладым,
Ташлы суклакларны мин кичтем.

Әлмисактан бирле төрек телле
Кабиләләр атны – зат иткән.
Атлы кеше – затлы кеше булган,
Ир-ат булып илдә җитлеккән.

Далаларда скиф, һуннар булган,
Кемнәр килеп, кемнәр китмәгән.
Атлар калган офык эргәсендә,
Нәселләре корып бетмәгән.

Атлар белән без дә исән калдык,
Аерылгысыз булып дуслаштык.

Татар – атсыз, ат – татарсыз калып,
Үзебезне әллә югалттык?!

Ә бит җәйрәп яткан далаларда
Ата-баба – хайван, мал тоткан.
Баскынчылар, ач шакаллар кебек,
Калҗа чәлдерергә яу чапкан.

Көтү-көтү утлап йөргән атлар
Каршы алган дошман яуларын.
Әй син, татар! Изге көрәшләрдә
Иярең дә кала алмадың?!.

...Һәр татарның холык-фигылендә
Дала рухы, атлар хәяты.
Без – барыбер атлар нәселеннән,
Җан-рухымда атлар аяте.

Декабрь, 2013 ел.

Татарник

Лев Толстойдан

Галәмнәрнең Җир исемле җисемендә,
Меңъ-миллион цсемлек цсә тцрендә.
Тамырларын тирәнгә, як-якка җәеп,
Татар дигән цсемлек тә бар җирендә.

Шул Татарның бинић ая ботаклары
Дөньяларны иңгә-буйга алган урап.
Галәмнәрнең хуҗасы цз рәхмәтеннән,
Ташламыйча цсемлекне тора карап.

Гәрчак аның игелекле орлыклары
Алгарышта, яңарышта, хәрәкәттә.
Тереклеккә кылган изге гамәлләре,
Инша Аллаћ, мәңге булыр бәрәкәттә.

Май, 2011 ел.

Кем һәм нинди?

Кем булсаң да, нинди булсаң да син,
Мохтаҗлыкта һәрчак каласың.
Башкаларның милли-рухи, матди
Байлыкларын көчләп аласың.

Шулай булган, шулай гомер иткән
Ата-бабаң элек-электән.

Корал тотып, чит кавемнең малын
Талауларга халкың күнеккән.

Тишек-ярык өйнең мич башында
Сез булдыгыз яткан калтырап.
Хыялланып ашъяулык турында,
Мичнең йөрмәвенә аптырап.

Иген-игү, хайван, кош-корт асрау
Булаллмаган илнең кәсебе.
Борынгыдан зар-интизар булып,
Яшәүләрнең – шулдыр сәбәбе.

Ачның ачу яман була ди,
Гаепсездән чөнки ул ала.
Хәмер эчеп, иләсләнгән нәләт
Күршеләрен суеп сау кала.

Кече яшьтән үк ул үзләштерә
Канлы-яшьле сугыш һөнәрен.
Сылтау итеп ватанпәрвәрлекне
Кол итәләр алар үзләрен.

Миллионнар яу кырында үлә,
Кол гомере керми исәпкә.
Шөһрәт өчен үзен корбан итү –
Әверелгән котсыз гадәткә.

Тынычта да халкың тынгы белми,
Яши кебек сугыш кырында.

Башкаларга ирек бирми яшәү –
Шовинистның азгын канында.

...Бүтән халыклардан аермалы
Булуларың бары тик шунда.

Сентябрь, 2015 ел.

Муенчакларны атып!

Мөселманнар шәһит китә
Азатлык, хаклык өчен.
Ирләр сугыш мәйданында,
Халкы бирә бар көчен.

Көрәш бара җирдә, күктә,
Бара ул һәр төбәктә.
Көрәш бара диндә, фәндә...
Бара ул һәр йөрәктә.

Гәркем үзен хаклы саный,
Булса да эше яман.
Баскынчылар гарәпләрнең
Иреген даулый һаман.

«Мөселманнар-террорчылар,
Экстремист-вәһһабчылар».
Шулай дип ялган тарата
Исламны хурлаучылар.

«Кызым, сиңа әйтәм, мәгәр,
Ә киленем син тыңла!»
Кинаялы бу сүзләрне,
Татарым, үзең аңла!

Яла ягу, сугыш тагу –
Нәсараларның эше.
Илләрне канга батыра
Мәкерле алар ише.

Акны кара дип сөйлиләр,
Юк дошманны бар итеп.
Биш йөз ел алар кан коя
Татар башына җитеп.

Теш үтмәс татарның башын
Биш йөз ел кимерәләр.
Чуер ташы сыман башны
Кимереп тилмерәләр.

Гәрнәрсәнең бер чиге бар –
Сабырлыкның да чиге.
Татарның да болытлардан
Арына бара күге!

Мәселманнарның иламы
Куәтен татыр вакыт.
Баш бирмәс гаярь башлардан
Муенчакларны атып!

Июль, 2015 ел.

Мин әйтәмен

Күке халкы йомыркасын
Чит ояга саладыр.
Кошлар күке киллмешәген
Балласыдай багадыр.

Без дә бит чит «баскыннар»ын
Тур башында тотабыз.
Әйтерсең лә мәгыйшәттә
Алар – ишек тоткабыз.

Гәркайда күке авазы,
Кычкыралар шом салып.
Язмышларны юрый алар
Гавәмнең котын алып.

И туганнар, мин әйтәмен:
Уйланыр вакыт чынлап.
Туган телсез калабыз ич
Ятлар фәрманын тыңлап.

Октябрь, 2013 ел.

Ләкин!..

Берәүләрне илдән куды,
Берәүләргә яла якты.
Берәүләрне гаепсездән
Төрмәләргә кертеп япты.

Мәйданнарда яулап алган
Мөстәкыйльлек нәүмиз калды.
Албастылар ябырылып,
Хак-хокукка богау салды.

Тик татарның горурлыгы
Хәр дәүләтендә калды.
Тау башындагы бөркет тә
Канатын җилпеп алды.

Сентябрь, 2014 ел.

Бергә булыйк, бердәм булыйк!

Бергә булыйк, бердәм булыйк, кардәшләрем,
«Бердәмлектә – көч» дип әйткән ата-баба.
Җир-күкләрне тоташтырып яңгыр ява,
Дөньяларны иңләп – буйлап сулар ага.

Иксез-чиксез далаларда, ил-җирләрдә
Ат уйнатып гомер иткән төрки-татар.
Яшәгәннәр кыйтгаларны берләштереп, -
Тик берләшкән халык бәйсез дәүләт тотар.

Бергә булыйк, бердәм булыйк, татарларым!
Бердәмлектә халкыбызның милли багы.
Җанны-тәнне, күңелләрне берләштерик,
Татар иле үз дәүләтен барлар чагы.

Август, 2013 ел.

Учак

Мин учакны соңга калып яктым,
Тоеп өлгермәдем җылысын.
Җаным өргән йөрәк ялкынымда
Газиз халкым инде җылынсын.

Соңга калдым. Язым, җәем үтте,
Ишегемне көзләр шакыды.
Үй-хисләрем күңлем күгендә
Таң йолдызы сыман балкыды.

Ут-ялкынсыз җирдә яшәеш юк,
Дөнья үзе утлы-ялкынлы.
Кояш та бит Илаһи бер учак,
Нурлар булып килә ялкыны.

Соң булса да, хәерлегә булсын,
Сүндермичә рухи учакны,
Кочак җәеп, җаным каршы алыр
Учагыма баккан кунакны.

Сентябрь, 2015 ел.

Сорауларга җаваплар

Хушлашыр да вакыт якынлаша,
Исәп тотам үзем алдында.
Бу дөньяда ни гамәллəр кылдым,
Җир җимертеп йөргән чагымда.

Кайберәүләр кебек, юлдан язып,
Йөрмәдемме динсез адашып?
Ялган сөйләп, гайбәт, яла ягып,
Гомер итмәдемме алдашып...

Байлык җыеп, кеше канын коеп
Басмадыммы золым юлына.
Кеше хакын урлап, алдап-йолдап,
Төшмәдемме нәфес колына?

Аллаһының кушканнарын үтәп,
Яшәдемме фани дөньяда?
Тәкъва булып, гыйбадәтлəр кылып,
Кешеләргә биреп җай-файда.

Намусымны, газиз иманымны
Сатмадыммы черер милеккә?
Хиссез, төссез булып калмадыммы
Әверелеп үзем череккә?

Күз алдымнан үтә тормыш юлым,
Төрле чагы булган гомернең.
Авыр чагы, җиңел чагы булган,
Сынау чагы булган күңелнең.

Тик вөҗданым ак-пакъ килеш калды,
Асыл сыйфатларын җуймады.
Гомер буе изгелекләр кылдым,
Күңелемә яман сыймады.

Берәүне дә юкка рәнҗетмәдем,
Җәбер-золым кылып йөрмәдем.
Кешеләргә зыян салган булсам –
Күтәралмас иде йөрәгем.

Тирем түгеп, хәләл көчем белән
Эшләп таптым ашар икмәгем.
Аллаһ ризыклары тәгам булды,
Хәрам малга зекер итмәдем.

Амбар-келәт байлык тупламадым,
Ялангач та, ач та булмадым.
Башкаларның өлешенә кереп,
Катлы-катлы коттедж салмадым.

Тик бәхетле саныйм мин үземне,
Рухи байлыгыма куанам .
Үземнән соң оят һәм намуслы
Саф-инсафлы дәвам калдырам.

Бәхилләшер вакыт якынлаша,
Күңелемдә юктыр һич курку.
Үлем бит ул – фани дөнья киче,
Теге дөнья исә – таң ату.

Август, 2013 ел.

Бигайбә

Гомеремнең ахырына килеп җиттем,
Халкыбыз берләшер диеп, өмет иттем.
Кыйтгаларны әүвәлгечә тоташтырган
Хөр-мөстәкыйль дәүләт булуын мин көттем.

Күрә аллам тантаналы ул көннәрне,
Халкыбызны рухландырсын шигъри көчем.
Милләтенә хыянәт иткән татарны
Яшен ташы булып суксын милли үчем!

Июль, 2011 ел.

Тәвәккәллек

Акыллы тауга менмәс ди,
Тәвәккәл тауга менәр.
Яшьлегемдә мин дә мендем
Булмасам да һич юләр.

Өч ел буе хезмәт иттем
Саклап илебез чиген.
Үзәк өзгеч салкыннары
Тәнемдә дулый бүген.

Тауда яшәү җиңел түгел,
Табигате бик кырыс.
Яшәү кадерен белергә
Өйрәтә хәтәр тормыш.

Һава җитми, берни үсми,
Тау-таш ишелеп тора.
Тик гайрәтле затлар гына
Тауларда тормыш кора.

Тәвәккәлдә тау көче бар
Көчләләр яши тауда.
Мин һаман тауларда яшим
Сиксәндә булганда да.

Сентябрь, 2015 ел.

Тансыклаган төш

Мин төшемдә таулар гизеп йөрим,
Үзаҗәеп бер халәт кичерәм.
Шул төшемне инде ничәнче кат
Кабат-кабат искә төшерәм.

Һавасы саф, рәхәтләнеп сула,
Һәммә тараф серле тынлыкта.
Кояш та юк кебек, ләкин дөнья
Сөт шикелле ап-ак чынлыкта.

Җан-тәнемне тылсымлы наз коча,
Ләззәт алам хискә уралып.
Урманнарда сихри кошлар моңы, -
Тыңлап торам шулай таң калып.

Үзәннәрне билдән үлән баскан
Чәчәкләре ала күз явын.
Рәт-рәт басып алар каршылыйлар
Табигатьнең кырыс сынавын.

Тау бөркете сыман, ташка басып,
Күзәтәмен таулар тормышын.
Кәүсәр чишмәседәй көмеш сулы
Шаулы елгаларның агышын.

Кышын яңгыр, җәен карлар ява, –
Түгелдер бу сәер тамаша.
Таулар урап ак болытлар ага -
Җир белән күк бергә тоташа.

...Мин төшемдә таулар гизеп йөрим...

Октябрь, 2013 ел.

Сагыш

Солдат хезмәтеннән хәтирә

Таулар холкы – кырыс, үзгәрүчән
Әле кояш сөеп иркәли.
Әле дулап искән «әфган» җиле
Капшап йөри тәнне үтәли.

Үзәкләргә үтә салкыннары,
Барган атлар кала туктalып.

Хәтта толып кебек калын туннар
Әйтерсең лә китә юкарып.

Мин төшемдә һаман таулар кичәм,
Кыяларга менәм ирмәләп.
Күккә ашам, йә упкынга очам,
Таулар белән яшим бергәләп!

Памир-тауда ак болытлар кочтым,
Тау башыннан күрдем дөньяны.
Биш мең ике йөз метр биектә
Сакладым мин ватан-ананы.

Хезмәттәшләр күптән-күптән инде,
Китеп барды якты дөньядан.
Чик сакчысы – ил сакчысы булдык,
Сырхау алып кайттык Памирдан.

Тик берәү дә сыкрап-сыктамады,
Үзен егет итеп санады.
Тормыш безне, кыя-ташка баскан,
Бөркетләргә тиңләп сынады.

«Акылы бар тауга менмәс», – диеп,
Куркак әйтер, аклап үз-үзен.
Ә мин һаман таулар эргәсендә -
Тауларыма гашыйк егет мин!

Октябрь, 2013 ел.

Аяныч

Шагыйрьлеккә дәгъва кылмыйм,
Каләмнән сүзем тамсын.
Мөкатдәс эш-гамәлләрем
Әманәт булып калсын.

Ниятем: үй-фикеремне,
Теләкләремне әйтү.
Газиздән-газиз халкымның
Офыкларын киңәйтү.

Хак-хакыйкатьне җиткерү,
Чынбарлыкны белдерү.
Үз дәүләтен торгызырга
Милләтемне күндерү.

Ләкин шунысы аяныч:
Урыслашкан кардәшләрне
Күндераллмый тилмерү...

Август, 2015 ел.

Йөрәккәем

Син типкәндә уй-хисләрем хәрәкәттә,
Ғәмәлләрем игелекле бәрәкәттә.
Булсаң да син, башым кебек, чир-инфарктлы,
Син һаман да күңелем күк сәяхәттә.

Яшь чагыңда Памир тубәсендә йөрдең,
Кар-буранлы «әфган җиле»нә уралдың.
Тының кысып, ачы әҗәл кочканда да,
Кыя-таудай син куәтле булып калдың.

Сабыр булдың, чыдам булдың, гаярь булдың,
Юкса үзең йодрык кадәр ит кисәге.
Йөрәккәем, син илаһи, мәшһүр даһи,
Җир-күкләрнең куллар кысышкан үзәге.

Йөрәккәем, кан агышым, юл барышым,
Син бердәнбер, юк тиңдәшең, юк алмашың.
Акыл барда – уй-фикерләр булыр җайда,
Күңелем һәм син бит минем иҗатташым.

Октябрь, 2014 ел.

Йөрәк җыры

Күпме кайгы-хәсрәт кичерәсең,
Күпме газап-михнәт чигәсең.
Югалтканда туган-тумачаны
Өзгәләнер хәлгә җитәсең.

Юа сине ачы күз яшьләре,
Телгәлидер усал сырхаулар.
Сабыр гына, Аллаһ рәхмәтендә
Үтәсең син авыр сынаулар.

Ихтыярың синең, күз тимәсен,
Чыдамлыкта – юктыр тиңдәшең.
Абынсаң да, сыкрап авырсаң да,
Җан-тәнемә яшәү илтәсең.

Яхшысын да, яманын да күрдең,
Чиксез сиңа әйтер рәхмәтем.
Ә син һаман унсигездә сыман,
Дәрт-кодрәтле гаярь йөрәгем!

Май, 2016 ел.

Иҗат газабы

Бәргәләнәм, җаным ирсәләнә,
Күңелемне борчу кимерә.
Әсәрләрем, гүя, тәмен җуйган
Майсыз ботка сыман күренә.

Сызам, бозам. Юкса, язган булам, -
Хыялымны чынга ашырмак.
Әй тырышам. Килер буыннарга
Рухи мирас булам калдырмак.

Язганнарым өчен оялсам да,
Уй-хисләрем ихлас күңелдән.
Җан авазым булган фикерләрем, –
Изге ният белән җелгән.

Ләкин алар чиле-пешле кебек,
(Бәлкем, миңа шулай тоела).
Китапларым укып карыймын да,
Күңелемә шикләр уела.

Тик никадәр инде пошынсам да
Әманәтем чорлар чатында.
Булыр алар газиз милләтемнең
Исән-имин лег е сагында.

Сезне сөеп язган әсәрләрем, -
Нәселемнең бәгырь җимеше.
Татарыма булган мәхәббәтнең
Җир-күкләрдә гомер сөреше.

Декабрь, 2011 ел.

Хисап тоту

Берәүгә дә яман кылып яшәмәдем,
Беркемгә дә зыян-зарар мин салмадым.
Язмышыма нәрсә язган – шуны күрдем,
Яшәү – намус билгесе диеп санадым.

Дошманнарым, көндәшләрем юктыр минем,
Башкалардан мыскал артык юктыр җирем.
Барлыгым да артык түгел, ким дә түгел,
Ходай биргән ризыкларга җитә керем.

Тормышымнан канәгатьмен, бик тә шөкер,
Ятсам-торсам – җаным тыныч, күңел актыр.
Хәрәм эштән ерак торам – чөнки безгә
Тынычлыктан кадерлерәк нәрсә юктыр.

Карт көнемдә күңелем пакъ, уйларым ак,
Аллаһ биргән ризык белән туктыр тамак.
Чәфес колы, корсак колы булганнарга
Тормыш һәрчак биреп тора ачы сабак.

Декабрь, 2013 ел.

Кемгә нинди бәхет?

Бу дөньяда һәр җан иясенә
Яшәр өчен кирәк өч нәрсә:
Ашау-эчү, торак, кием-салым, -
Башкасы да мөһим – кирәктә.

Ризыкны мин инде тугыз яшьтән,
Көтү көтеп таптым үземә.
Калганнары – яши-яши килде,
Кызыл китермәдем йөземә.

Кирәклесен хәләл көчем куеп,
Эшләп таптым, малга ирештем.
Өч мөһимнең – һәммәсе дә булды,
Һәфес белән чикләр бүлештем.

Мин бәхетле – бар булганым белән,
Булдырганым белән шатланам.
Тыйнак кына фатирымда яшәп,
Хәләл ризык белән тукланам.

Ә берәүләр яши хансарайда, -
Эче-тышы тора ялтырап.
Талап җыйган хәрәм малын кочкан,
Җәза көнен көтә калтырап...

Декабрь, 2013 ел.

Халәтемнең шундый чагы

Күңелләрем сизгерләнде, һай нечкәрде, -
Моңсу җырлар ишетсәм дә тибрәнәдер.
Ил-җирләрнең һәлакәтле хәбәрләре
Сыкрандыра. Җаным-тәнем тетрәнәдер.

Афәтле бер шомлы хәбәр ишетсәммә,
Бәгырьләрем телем-телем теленәдер.
Бугазыма төер килеп утыра да, –
Җаным сыктый, үзәкләрем өзеләдер.

Үксеп-үксеп, күз яшьләрсез, эчтән елыйм,
Хак Тәгаләм, рәхмәтеңнән ташлама, дим.
Күңел күгем кайгы-хәсрәт капламасын,
И син дөнья, һәрвакыт та булчы илмин!

Декабрь, 2013 ел.

Кайтаваз

Кыя-тауларның кайтавазы көчле,
Яңгырый ул күкләр күкрәгән төсле.
Кыя-тау башларыннан тиз йөгереп,
Кайта үзән-уйсулыклардан йөреп.

Як-якта дулкыннар булып тибрәнә,
Шул аваздан кар-бозлар бәргәләнә.

Тын һавада тора озак зырылдап,
Скрипка кылларыдай зыңгылдап.

Шул кайтаваз кебек бүген минем дә
Сырхау-сызланулар дулый тәнемдә.
Буыннарым майламаган тупса күк,
Шыгырдыйлар аяк асты кары күк.

Бернәрсә дә эзсез генә узмый шул,
Памир тавында өшеде аяк-кул.
Чик буен саклап өч ел гомер үтте,
Үзәккә үткән салкыны куып җитте.

Сырхау алды буыннарымны, билне,
Сыкранып газапта үткәрәм көнне.
Әфган җилләре саулыгымны сауды,
Җаным-тәнем ярдәмгә мохтаж калды.

Илле елдан яңгырады кайтавазы,
Тик хөкүмәтнең юк һичбер авазы.

Февраль, 2013 ел.

Уразада булган чагың...

Тәрәз төбем каймаланган гөлләр белән,
Таң аттымы, чәчкәләрен көнгә бора.
Яфраклары тәрәзәдән аллый күзен,
Кояшкача үрелеп ул ача йөзен.

Су сипмәсәң, күзгә карап, алар шиңә,
Сабаклары нәүмизләнеп башын ия.
Яфракларга буй-буй булып сырлар куна,
Туфрак кибә, тамыр корый, гөлләр сына.

Табигатьтә һәркемнең дә үз көе бар,
Җан иясе бер-береннән кадер көтә.
Гөлләр үссен, гөрләп чәчәк атсын дисәң,
Уразада булган чагың торсын истә.

Декабрь, 2013 ел.

Барлыгым

Сәхрәләргә чыгам, сәфәр кылам,
Урманнарны кайтам әйләнеп.
Аллаһыга шөкерана кылам,
Яшәвемә җирдә сөенеп.

Юк, кирәкми миңа алтын-көмеш, –
Вәсвәсәле дөнья байлыгы.
Кадерледән кадерлерәк барлык, –
Җан-тәнемнең таза-саулыгы.

Апрель, 2012 ел.

Дәрья кичтем

Меналмадым тауның башларына,
Басалмадым текә кыяга.
Тау астында ыгы-зыгы килеп,
Үтеп китте гомер зыяга.

Тау бөркете сыман канат җәеп,
Болытларны кисеп үтмәдем.
Йөзсәм дә мин хыял дәрьясында,
Ярларына барып җитмәдем.

Мәхәббәт тә мине ташлап китте,
Әллә инде кадрен белмәдем.
Хәрәм юлда йөргән иптәшемнән
Хатын нигъмәтләре күрмәдем.

Юк, зарланмыйм. Рәхәте дә булды,
Михнәтләре булды мулырак.
Төптәнрәк уйлап яши белсәм,
Булыр иде тормыш тулырак.

Син боларны юкка язасың, дип,
Кырыкканны кабат кырыкма.
Хаталардан торган бу тормышта
Хаинлеккә икән юлыкма.

Декабрь, 2013 ел.

Соңгы теләк

Мин шагыйрь дә, язучы да түгел,
Бу шөгыльдә тыйнак һәвәскәр.
Тик уйларым тынгы бирми миңа,
Күңелемдә алар – зур гаскәр.

Уй-хисләрем ургып ташыганда,
Хак-каләмгә кулым үрелә.
Яшьлегемдә шыткан хыялларым -
Чәчкә булып чынга әврелә.

Аллаһ миңа мәрхәмәтле булды,
Күңелемә илһам, рух өрде.
Көзләремнең тансык җимешләре,
Соң булса да, пешеп өлгерде.

Бөекләр дә мәшһүр әсәрләрен
Акыл җыйгач язып танылган.
Алтмыш дүрттә – Күктән вәхи иңде,
Гәм олайгач... тудым яңадан.

Кеше китә, җыры кала, диләр,
Язганнарым – сезгә бүләгем.
Күңелемнең изге уй-хисләре
Юлдаш булсын – соңгы теләгем.

Декабрь, 2013 ел.

Мин – табигать баласы

Кырык биш ел йөрәк сырхавыннан
Газап чигеп гомер кичерәм...
Йөрәккәем – көйсез көз шикелле,
Төрле халәтләргә мин керәм.

Әле кояш чыккан кебек була,
Кайчакларны яңгыр, кар ява.
Табигать күк, мин дә үзгәрештә -
Кәефемнең шаһы – җир-һава.

Кышын елгыр чаңгыларда шуам,
Саф һавасын сулыйм урманның.
Наратларны кочып сихәт алам,
Мәрхәмәтен сизәм аларның.

Аккош күле, тылсымлы Тирән күл –
Казанымның энҗе-мәрҗәне.
Суларында рәхәт – сихәт алып,
Хозур кылам ямьле җәйләрне.

«Яткан ташны мүк сарыр», – ди халык,
Бетмик әле мүккә уралып.
Ташны ертып чыккан үләннәрдән
Яшик әле рухи көч алып.

Февраль, 2014 ел.

Ғаләмәт

Хыялларым, кыр казлары кебек,
Илләр гизә зәңгәр күкләрдә.
Очмак булам. Ләкин канатларым
Йорт казларын тоткан бикләрдә.

Кыр ұрдәге булып дәрья кичәм,
Җир сулардан, гүя, көч алам.
Үй-хисләрем Ғаләмнәрне айкый, –
Йорт ұрдәге ләкин мин һаман.

Дөньяларны кочар вакыт үтте, –
Хыялларым калды соңгарак.
Чынга ашмас үй-хисләрем белән
Ата каздай йөрим каңгырап.

Май, 2014 ел.

Алданма!

Уянам да... Төннәр буе
Кайгы-хәсрәттә булам.
Бәгыремне телгәләгән
Шомлы уйга уралам.

«Нигә дип милли рухыңны
Җуясың, татар?» – диям.

Җаным сыкранып әрнидән
Сырхау хәленә киләм.

Нигә татар урыслаша?
Үз асылыннан кача?
Милләтебез тишек кораб
Ник түгел лә югыйсә.

Нигә ул татар булудан,
Үз-үзеннән ояла?
Үз илендә, үз телендә
Сөйләшүдән тыела?

Нигә без әллә кемнәргә
Яларга тырышабыз?
Нәүмиз җан иясе кебек
Яткларга сырышабыз?

Тик татар сырышкан халык
Дөньяда яманатлы.
Балта биреп шөшле алган
Ник була аллый хаклы.

Нигә аңыбызны җуеп,
Бу хәлгә килеп җиттек?
Без үзебезне үзебез
Илбасарга кол иттек.

Кайда татар горурлыгы?
Ата-баба берлеге?

Телебез дә иң борынгы
Шөһрәтле дөнья теле.

И татарым, син бит шанлы
Төрки затлар варисы!
Скиф, һун, болгар, кыпчаклар...
Ил-җирләре хуҗасы.

Октябрь, 2015 ел.

Борчылу

Мин киткәч тә тормыш дәвам итәр,
Иртән балкып нурлы таң атар.
Йолдызлар сүнеп йокыга талыр,
Кояш чыгар, төндә ай калкыр.

Мин киткәч тә тормыш дәвам итәр,
Халык иртән эшенә китәр.
Бетмәс борчу-мәшәкатьләр белән
Көн артыннан серле төн үтәр.

Мин киткәч тә тормыш дәвам итәр,
Бу турыда һичбер шигем юк.
Илләр-җирләр үз урнында калыр,
Тик халыклар тулы булмас күк.

Глобальләштерү дигән аждаһа
Йотып тора кече халыкны.
Илен-җирен үзенеке итә,
Тартып ала бөтен барлыкны.

Исән калыр микән туган телем –
Мең гасырлар буе чарланган.
Тәрҗемәләрдә камиллеге белән
Дөнья күләмендә дан алган.

Исән калыр микән илаһи моң -
Башка халыкларда булмаган.
Дөньяларны үтә таң калдырып,
Сихри аһәңнәргә ураган.

Исән калыр микән Идел-Йортым,
Акча суккан, чуен эреткән.
Шанлы Алтын Урдам... Гүн бабамнар
Каганатлар данын терелткән!

Газиз халкым, исән калырбызмы?
Хәвефләнеп көн-төн уйланам.
Ике татар русча сөйләшкәндә,
Җаным-тәнем белән сыкранам.

Кая безнең татар горурлыгы,
Кая китте мәгърур милли хис?
Югыйсә бит, барын ата-баба
Әманәткә безгә биргән иҗ.

Авыз ачып, гамьсез-аңсыз торсак,
Аждаһага азык булырбыз.
Үз кадерен белмәгән кавемдәй
Тарих чүплегендә калырбыз.
Аллаһ сакласын!

Июнь, 2015 ел.

Гомеркәем!..

Гомеркәем, ярсу аттай чабып,
Син һаман да алга ыргылдың.
Ачысын да, татлысын да тойдым,
Төрле ягың белән борылдың.

Мәхәббәт тә сөеп иркәләде,
Хәтирәсе калды йөрәктә.
Аларсыз да яшәү булмас иде,
Булмас идем җирдә йөрмәктә.

Язмышыма һич тә үпкәләмим,
Ни булса да – булды минеке.
Үзеңнеке – гел үзәктә була,
Хикмәтлесе – була илнеке.

Гомеркәем, бик яраттым сине,
Тормышымның син бит кояшы.
Изгелектә кылган гамәлләрем
Милләтемнең булсын юлдашы.

Июнь, 2015 ел.

Картлыгым-шатлыгым

Йорт салдым, бакча үстердем,
Нәсел җебен сапладым.
Бәрәкәтле хезмәтемнең
Җимешләрен татыдым.

Әй син, тәхетле картлыгым,
Яшә яшьлектә калып.
Картаймас йөрәгем кебек –
Унсигез яшьтә булып.

Өч көнлек кунак гомернең
Булсын тәмен татырлык.
Картлыкта сәламәт яшәү –
Үзе күркәм батырлык!

И бәхетле син, картлыгым,
И тәхетле шатлыгым.
Балаларым, оныкларым –
Сез минем – йөз аклыгым.

Мин бәхетле

Мин байлыкның колы булмадым һич,
Аны ызгыш корты санадым.
Хәрам малга – әдәп-әхлаксызлык
Сазламыгы итеп карадым.

Көнчелексез үткән гомеремә,
Язмышыма ихлас ризамын.
Тыйнак кына фатирымда яшәп,
Тәкъдиремә башым орамын.

Ач та, ялангач та булмадым мин,
Маңгай тирем түгеп эшләдем.
Аллаһының нигъмәтләре белән
Тормышымны бизәп яшәдем.

Орынмадым читләр күңеленә,
Кагылмадым кеше хакына.
Гаиләләрем һич тә манчылмаган
Күз яшенә, кеше канына.

Гаепсезгә нахак бәла тагып,
Ялган сөйләүләрдән сакландым.
Яла ягу, гайбәт сатуларны
Баш казыгы итеп санадым.

Ата-бабам гадәт-йолаларын
Алышмадым дөнья малына.
Намусымны, калеб-күңелемне
Керләмәдем нәфес сазына.

Мин бәхетле. Меңнән-мең рәхмәт әйтеп,
Шөкерана кылам барына.

Октябрь, 2015 ел.

Баш иямен

Исән-имин торасыңмы, туган җирем?
Ата-бабам гомер иткән синдә минем.

Сукалаган, чөчкән, урган алар синдә,
Туфрагыңны учларына алып көн дә.

Синең басу-кырларыңда иген иккән,
Син аларны хәлле иткән, маллы иткән.

Көмеш сулы чишмәләрдән суың эчкән,
Тирен тыгеп, билен бөгеп гомер кичкән.

Болыннарда каерылып печән чапкан,
Тау башында җир җиләге алып капкан.

Синең туфрагыңда үсеп таңы аткан,
Сине сөеп, үз анасыдай яраткан.

Ашлык булып кайтасың син, келәт тулып,
Табыннарга куңәсең син, аш-су булып.

Җир-ана дип, атый сине шуңа халык,
Тапкан ана, баккан ана – ике барлык.

Баш иямен һәрчак сиңа сәждә китеп,
Сиңа кайтам, сине бакый йортым итеп.

И туган җир! Рәхим – рәхмәт, мәхәббәттән, –
Мәхрүм итмә тереклекне мәрхәмәттән.

Апрель, 2011 ел.

Минем язмыш

Дүрт яшемдә, әйе дүрт яшемдә,
Мин үләргә тиеш булганмын.
Дүрт яшемдә чакта һәлакәтле
Ат тоягы көчен тойганмын.

Дагаланган атның койрыгына
Чана тагып куймак булганмын.
Гафу итмәс гамәл кылганмын –
Җәзасын да шундук алганмын.
Күкнең исән затлар исәбеннән
Алтмыш елга «төшеп калганмын».

Ләкин әти, аңа мең-мең рәхмәт,
Яшәү өргән минем тәнемә.
Ике тапкыр гомер бүләк иткән,
Шөкер итәм Аллаһ-Тәңремә.

Кырык көннән аң-һушыма килеп,
Ачканмын мин сыңар күземне.
Юкса, авыл зиратында мәгәр,
Әзер кабер көткән үземне.

Алтмыш дүрттә Күкләр искә алып,
Аптырашта булып калганнар.
Минем әле яшәвемне белгәч,
Тере диеп «язып» куйганнар.

Шулай итеп, мин алтмыш ел буе
Җир-Күк арасында торганмын.

Ләкин ипле тормыш корганмын.
Күңелемнең татлы хыялына
Ургыр өчен ерым ерганмын.

Алтмыш дүрттә кулга каләм алып,
Шигырь, хикәяләр сырганмын.
Инде менә сиксәнгә дә җиттем,
Мин һаман да әле яшәүдә.
Теләк булса, кеше язмышлары
Була аллый икән үлчәүдә!

Июль, 2015 ел.

Пошыну мәлендә

Буш мичкәгә охшап калдым –
Үй-фикердән бушандым.
Әллә арыплар киттемме,
Әллә инде картайдым?

Кулларыма каләм алып,
Берни язасым килми.
Китапларым өнсез ята,
«Сәяхәт» кылып йөрми.

Үзгәрдем. Гаҗәп үзгәрдем,
Битарафка әйләндем.
Күңелемә йозак элдем,
Үз-үземә бикләндем.

Ни белән бетәр бу халәт,
Ачылырмы тел чаты?
Ғалкырмы күңел кояшым, –
Биреп җаныма якты?..

Апрель, 2014 ел.

Авылдашларга нәсыйхәтем

Авылдашлар, канкардәшләр,
Сүзем ихлас күңелдән:
Китмәгез сез – җан яралган,
Ғазиз кендек каны тамган,
Изгедән-изге җирдән.

Сак-соклар кебек булмасын
Җан белән кендек каны.
Икәве дә – бертуганнар
Аермыйкчы аларны.

Үзмасын шушы тәңгәллек
Сагынулы моң-зарда.
Сагыштан газап чикмәсен
Туган җирләре барда.

Авылдашлар, аркадашлар,
Китмик туган туфрактан:
Йортларда учак сүнмәсен,
Өзелмик милли аштан!

Әзермен бу хакыйкатьне
Әйтергә яңабаштан.

Сентябрь, 2013 ел.

Сөйлим ихластан...

Авылымның гүзәллеге белән,
Көтү көткән чакта таныштым.
Болыннарда койрык чәнчәп чапкан
Яшь бозаулар белән ярыштым.

Тугайларны, су буйларын иңләп,
Казлар белән җәйләр кичердем.
Какы өзеп каптым, борчак салып,
Кузгалаклы ашлар пешердем.

Ун яшемнән дүрт ел көтү көттем,
Чишмәләрдән ятып су эчтем.
Җир-әнкәнең сыйлы хөрмәтенә
Бисмилламны әйтеп ирештем.

Субаш-Атым! Кендек каным тамган,
Ата-бабам торган туган җир.
Мәңге сиңа гашыйк улың итеп,
Куеныңнан миңа урын бир.

Июнь, 2014 ел.

Гомер

Субаш-Атым, тәүге тапкыр
Синдә тамды кендек каным.
Бер тән булып без берләштек,
Синдә яши минем җаным.

Җирләрең күзәнәгендә,
Төлләрнең мин тажында.
Кышын тирән тамырлардан
Шытып чыгам язында.

Болыннарда чәчәк атам
Иген кырларын яулыйм.
Җәен-кышын, язын-көзен,
Урманың булып шаулыйм.

Авылдашлар, мин асылда
Гәрчак сезнең тарафта.
Сагыш тулы җәсәдем дә
Калыр туган туфракта.

Июнь, 2015 ел.

Язмышымда – тояк эзләре...
(Тормыш сәхифәләрем)

Маңгаеңа тай типкәнме әллә?
(Халык әйтеме)

1

Узып барган атның койрыгына
Чана тагып куймак булганмын.
Әллә уйнап, әллә абайламый,
Селтәп куйган бахбай тоягын.

Җитә калган дүрт яшьлек балага
Дагаланган атның тоягы:
Сул ягымның бите умырылган -
Шәрә калган яңак сөяге.

Сәләмәләр – ертык кәгазь кебек,
Бит тирәли калган эленеп.
Үз рәвешен җуйган бит эченнән
Ак тешләрем торган күренеп.

Аңым киткән, сулар тыным беткән,
Үлде диеп мине белгәннәр.
Чын хәлемне белеп раслар өчен
Ат духтырын алып килгәннәр.

Сулышымны сизергә дип духтыр
Пыялага мине иснәткән.

Әле исән икәнемне белгәч,
Үз белгәнчә ярдәм күрсәткән.

Бит-авызны каннан арындырып,
Яңагыма япкан тиресен.
Битне төреп бака яфрагына,
Майлап куйган яра тирәсен.

«Дуңгызның бу эчке маен эртеп,
Стрептоцид белән кушылган.
Яраларны дәвалауда бу май
Иң сихәтле булып танылган».

Шулай дигән дохтыр әтиемә,
Маен сузып цзе ясаган.
Ике ирнең изге җан җылысы
Минем җаным белән кушылган.

Әткәй бәгърем могҗиза май белән
Дәвалаган сырхау битемне.
Юкса көн дә авыл зиратында
Әзер кабер көткән цземне...

Кайберәцләр риясыз күңелдән
Үлемемне хаклы күргәннәр:
«Калмаса да бәлкем тома тинтәк,
Гарип булып калыр», – дигәннәр.

Үпкәләмим. Аларның бу сүзе
Теләк булган бары яхшыга.

Үртәмәсен кай «акыллы башлар»
«Ат типкән дип аның башына».

Дөрестән дә, зиһен белән аңым
Төшеп калган тояк астына.
Теш үтмәде төгәл фәннәр дигән
Фән-гыйлемнең өске катына.

Гомер буе башым сызлаулары
Очар канатларны каерды.
Вакыт-вакыт аңсыз калуларым
Асылымнан мине аерды.

Командирым дөрес әйткән икән:
«Өлгермәгән сәер җимеш син».
Шуңадыр да, көзен чәчәк аттым,
Алтмыш дүрттә генә җитлектем!

Уйлап торам. Әгәр ат типмәсә,
Башкаемны ярык итмәсә,
Манараның* мәшһүр баскычыннан
Менгән булыр идем югыйсә.

Тик шулай да рәхмәтеннән Аллаһ
Ташламады зәгыйфь мәхлукны.
Булмасам да түрә – җитәкләдем
Меңәр оешмалы халыкны.

Язмышыма һич тә үпкәләмим
Намус белән үттем гомерне.

Яхшы нәсел илгә калдырамын,
Кызартмаслар, шәттер, йөземне.

Үй-фикерем, ихлас язмаларым
Рухи мирас булсын чорларга.
Бабаларның изге васыятьләре
Байрак булсын милли улларга!

2

«Балам кемгә охшап туар икән?» -
Дигән сорау ата-анада.
«Җиде әби-бабаң кыяфәте
Булыр – диләр, картлар, – баланда».
Җиде буын әби-бабаң төсен
Кемнәр әйтә алыр билгеләп?
Әтиемнең үз кыяфәтен дә
Анык кына булмый хәтерләп.

Безнең кебек, җае чыккан саен,
Төшмәгәннәр алар фотога.
Хәтта юктыр паспорт сурәте дә –
Бирмәгәннәр паспорт аңарга.

Авыл халкы хак-хокуксыз булып,
Гомер чиккән туган җирлектә.
Изге дине, гореф-гадәтләре,
Татарлыгы белән берлектә.

Әмма хәзер кая гына бакма,
Кеше йөзе торыр каршыңда.

Ауный алар бәдрәф идәнендә,
Саргаялар кабер ташында.

Эти-әни, истәлеккә диеп,
Төшкән булса әгәр бергәләп.
Сурәтләрен күңлем диварында
Саклар идем сөеп-кадерләп.

Тик юк алар. Әни бер ялгызы
Нәүмиз булып төшкән сурәткә.
Аның моңлы-зарлы карашлары
Хәсрәт уты сала йөрәккә.

Әнкәй мәрхүм, ирем өчен диеп,
Үң ягында урын калдырган.
Үзең дә юк, эти, сурәтең дә,
Аллаһ сине күккә алдырган.

Әткәй, бәгърем, истәлегең булып,
Фронт хатларың да каллмаган.
Сталинград өчен сугышларда
Син хәбәрсез, имеш, югалган.

Ватан өчен һәлак булганнарга
Шундый котсыз тамга тактылар.
Илдә совет уты сүнгәч кенә
Яктылыкны эзләп таптылар.

Ләкин кеше кысыр болыт түгел, -
Җилгә каршы канат кагына.

Болыт та бит актык тамчы суын
Җиргә сипкән тулы чагында...

Ядкарь булып җиде буыннарга
Фигыль-холкың калыр нәселдә.
Буең-төсең, күңел табигатең... -
Югалмаслар, әти, берсе дә!

3

Биш балаңның кайсы сиңа охшаш?
Хәтерләтә сине сурәттә.
Башкаларны белмим (алар вафат),
Ә син минем һаман йөрәктә.

Әткәй бәгърем, ялгыш сораганмын
Кайсыбызда диеп сурәтең?
Миндәгесе, сул як битемдәге
Яра эзе – синең хикмәтең.

Көзгеләргә күзем баккан саен
Әти, сине искә аламын.
Айлар буе мине дәвалаган
Җан-рухыңа дога кылямын.

Айлар буе ябык авызымны
Кашык тыгып көчкә ачкансың.
Эретмәсен миңа эчертергә
Умартаның балын тапкансың.

Чын үлемнең корыч тырнагыннан
Йолып калдың төннәр йокламый.
Ике тапкыр миңа гомер бирдең,
Дәва кылып миңа, сыктамый.

«Ул гомерлек, бәлкем, гарип калыр,
Тик яшәсен улым», – дигәнсең.
Күңелеңнең мәхәббәтен биреп,
Җан җылыңны миңа өргәнсең.

Дуңгыз маен көн-төн сылый торгач,
Ит үстергән битем ярасы.
Алмаштырып юкса куяр идең,
Юк шул аның запас яңасы.

Еллар үткән, җөйле яраларым
Үз сыйфатын алган тартылып.
Тик битемдә корыч дага эзе,
Гомерлеккә калды яд булып.

Әткәй бәгърем, гомер буе сиңа
Рәхмәт әйтәм, иеп башымны.
Аллаһыдан бакый җәннәт сорыйм,
Насыйп итсен сиңа яхшыны.

Ишетепләр беләм, кечкенәдән
Газапларны бик күп күргәнсең.
Урам эте сыман өйалдының
Асларында йоклап йөргәнсең.

Әни белән кара бер мунчада
Җибәргәнсез башлап тормышны.
Рәхмәт инде авылдашларыма -
Бүлешкәннәр өчен язмышны.

Инде яшәп кенә киткән чакта
Фашист явы сугыш башлаган.
Язмыш сине дөнья тамугына -
Суслонгерга илтеп ташлаган.

Бер киргә китсә китә бит ул -
Ватан өчен вафат булгансың.
Дөньялыкта инде кыямәтнең
Мәхшәр газапларын кылгансың.

Мин – ат типкән синең кече улың -
Дөнья белән һаман тартышам.
Синең өчен, туганнарым өчен
Туксан ягын сүтеп маташам.

Абыйларым ашка ашыккандай,
Иртә китте фани дөньядан.
Иң яраткан кызың – сеңлем Рәисә,
Алдын булып чыкты башкадан.

Туганнарым, газиз әнием дә
Фани дөнья белән хушлашты.
Ә мин исән. Синең хәер-догаң,
Яшәештә сине алышты.

Чирләремне өф-өф итеп кенә,
Сакка куеп яшим түземне.
Дүрт мәртәбә үлем тырнагыннан
Йолып алды Аллаһ үземне.

«Бурычыңны әүвәл түләмичә
Киллмә, – диде – ахры катыма».
Алтмыш дүрт яшь тулгач, бабай булгач,
Мин, ниһаять килдем «аңыма».

Аллаһ бирде хәер-фатыйхасын,
Я зар каләм бирде кулыма.
Ә син, әти, рухи көч бирәсең
Яшәр өчен төпчек улыңа.

Дәртле рухың, синнән калган геннар
Яшьни булыр яшәп үземдә.
«Егет кеше җитмеш һөнәр белсен», -
Диеп яшәгәнсең үзең дә.

«Мактаулы зат иде әтиең», – дип,
Искә алды сине әнием.
Гармунчысы, балта остасы да,
Булгансың син якын-тирәнең.

Мең тугыз йөз тугызынчы елгы
Гармуныңны саклыйм кадерләп.
Битемдәге яра эзе... Гармун...
Минем белән яши бергәләп.

Алар синең төсең-кыяфәтең
Синнән калган асыл истәлек.
Кеше китә, җыры кала, диеп,
Әйтеп киткән мәшһүр бер әдип.

4

Бернәрсә дә эзсез генә үтми, -
Ат аунаса җирдә төк кала.
Җаның аша үткән вакыйгалар
Кайтавазлар булып төс ала.

Төшләремә кереп йөдәтәләр,
Тетрәнәмен кайчак саташып.
Билгесез чит дөньяларны урап,
Көндез йөрдем өндә «адашып».
Шулай булды. Башым әйләнде дә
«Йөзеп китем» үзем каядыр.
Күзем йомык. Ләкин күз алдымнан
Чит-ят дөнья узып барадыр.

Таныш түгел йөзләр. Ләкин алар,
Әйтерсәң лә, якын туганнар.
Бәлкем алар минем әби-бабам,
Элгәредә кардәш булганнар?

Алар төрле-төрле. Ә үзләре
Охшамаганнар бик тә безләргә.
Үзды алар сүзсез, мыштым гына,
Үткен багып минем күзләргә.

Чырайлары ачык, йөзләре пакъ,
Үзләре чат татар төсендә.
Ак яулыклы, тұбәтәйле затлар
Узып китте мизгел эчендә.

Манзаралар берсе арты берсе
Алмашынып торды өзлексез.
Төркем-төркем булып үткән затлар
Кемнәр алар? Миңа билгесез.

Таныш түгел йөзләр, чит-ят мохит...
Хәйран калып торам аптырап.
Чик мин монда? Чинди дөнья соң бу?
Тел әйләнми, буллмый һич сорап.

Бик тә сәер яшәештә булдым,
Башым тотып ишек төбендә.
Сәфәр кылдым теге дөньяга мин
Басып торган хәлдә өемдә.

Аңлы килеш, акылымда булып,
Кинәт кенә җуйдым үземне.
Чит дөньяның чынбарлыгын күрдем,
Дер калтырап ачтым күземне.

Баш зыңылдый. Чигә тамырлары
Шартлар хәлгә килеп күбенгән.
Хастаханә раслаган кәгазьдә:
«Баш миендә инфаркт» диелгән.

Беренче кат сөйлим бу турыда,
Моңа кадәр тоттым сер итеп.
Яхшы беләм, усал теллэр әйтер:
«Акылыннан язган Рәис», – дип.

5

Бернәрсә дә үтми эзсез генә –
Ат аунаса, җирдә төк кала.
Чал тарихның кыя-тау башлары
Болытларга кереп югала.

Ә манежда старшина Яушев
Сыздыргалап каеш камчысын
Солдатлардан кавалерист «ясый»,
Ихтыярның сыгып тамчысын.

Старшина кулын татыган ат
Кинәт кенә куя ыргылып.
Тезгенен нык тотмаган «салага»
Киртәсенә тыңә сузылып.

Куркуыннан дер-дер калтыранып,
Ябышканнан атның ялына...
Каеш кебек сыек яшь егетлэр -
Әверелә камчы сабына.

Мин дә сыек камчы кебек чакта -
Өнсез калып кат-кат мәтәлдем.
Эт каешы кебек үҗәтләнеп,
Ат сыртында затка әйләндем.

Намус белән илгә хезмәт иттем,
Сакта тордым, йөрдем атларда.
Төкерекләр инде һавада ук
Бозга әверелгән чакларда.

Күз ачкысыз кышкы буранларда
Атым белән ердым көртләрне.
Тарлавыктан өргән «әфган җиле»
Өтеп алды бәсле битләрне.

Сыланып тау кыя куышына,
Яшеренеп тордым «секрет»та.
Төнге дозор суккакларын кичтем,
Кавалерист булып нарядта.

Адәм кадәр чыдам затлар юктыр,
Сабырларга Аллаһ юнь бирә.
Ат өстендә цирк артистыдай
Өйрәндек бит без дә йөрергә!

Мең-мең рәхмәт сиңа, старшина,
Гомер буе булдың якында.
Өйрәттең син ипләп иярләргә
Тормыш дигән чабыш атын да.

Бернәрсә дә үтми эзсез генә,
Юшкыннары кала йөрәктә.
«Хаклы гамәл кылып яшименме?»
Сорау торды уйлы үзәктә.

Хушлашыр да инде вакыт килер...-
Язмышларда Аллаһ кануны.
Кануннарның яхшы-яманы бар,
Аера бел актан караны!

---

* *Күккә күтәрелү баскычы.*

Декабрь 2014, гыйнвар 2015 ел.

Урман иле

(Эскизлар)

I

Күпме генә буран котырмасын,
Җилкенмәсен кышның салкыны...
Чыршылар инде бәллүр челтәр бәйли,
Карны ялый кояш ялкыны.

Умырзая зәңгәр керфек сирпи,
Яшел шәлен яба ак каен.
Яулык читен ачкан гүзәл кыздай
Гөл-чәчәкләр бизи май аен.

Аллы-гөлле урман чәчкәләре
Ай-кояшка таба ашкына.
Күңелләрне назлап, гашыйк итә,
Чүгәлисең барып каршына.

Хозурланып һәркем ләззәт ала,
Урман һавалары сулагач.
Үзенә хас күркәммлеге белән
Сокландыра монда һәр агач.

Язгы урман – купшы кызлар сыман,
Әйтерсең лә тәүге мәхәббәт.
Икесе дә – тылсым ияләре,
Икесе дә юмарт вә һиммәт.

II

Җәйге урман мулдан табын җәйгән,
Җиләк белән тулган аланы.
Татлы-затлы җимешләрен элгән
Алма, чия, миләш, баланы.

Табигатьнең сыйлы нигъмәтләрен
Авыз итеп һәркем шатлана.
Урманнарга рәхмәт әйтә-әйтә,
Адәм заты итә тантана.

Тудыра да, үстерә дә урман,
Җанны-тәнне сөя, иркәли.
Мәхәббәттән мәҗнүн кошлар моңы
Күңелләрнең кылын чирткәли.

Танышытыра, кавыштыра урман –
Тереклекнең изге йорты ул.
Урман белән гомер итә мәхлук,
Аның аша үтә барыр юл.

Табын җәеп, һәрчак каршы алыр,
Кунак итәр сые табылыр.
Урман фатихасын алган затка
Ғаләмнәрдә никах укылыр.

Җәйге урман – уңган килен сыман:
Икесе дә сыйлы, икмәкле.
Икесе дә яшәү бүләк итә,
Икесе дә серле хикмәтле.

III

Көзге урман – яшеллеген җуйган,
Каршылый ул кышны сагаеп.
Җилләр өзгән асыл яфраклары
Җиргә төшеп ята моңаеп.

Ғәр тарафта сафлык, моңсу тынлык,
Ғаскәридәй тора һәр агач.
Үз кадерен белеп гомер итә
Ғорур булып җирдә яралгач.

Яфрак яра, нәсел җимешләрен
Башкаларга биреп тарата.
Тамырларын еракларга җәеп,
Ғәр яз саен нәсел яңарта.

Ғәркем җирдә урман белән яши,
Игелеген күрә түләүсез.
Урман кылган изге гамәлләрнең
Исәбе юк, саны төгәлсез.

Көз урманны мең-мең төскә манган,
Искитәрлек сихри һәммәсе.
Әйтерсең лә, урман өстен япкан,
Табигатьнең төсләр җәймәсе.

Урман, урман! Син хатын-кыз сыман,
Хатын-кыздай рәхим-шәфкатьле.
Җир-анабыз кебек мәрхәмәтле,
Күкләр кебек көчле, куәтле.

IV

Кырпак шәлен бөркәп иңнәренә
Басып тора чыршы анасы.
Үзе сырып теккән яшел күлмәк -
Мәңгелекнең яшәү тамгасы.

Сөеп карый ана таҗ калфаклы
Зифа буйлы нарат кызына.
Тышта февраль. Салкын. Ләкин урман,
Сәфәр чыккан яшьлек язына.

Хатын-кыз да, урманнар да охшаш -
Икесе дә олпат, мәһабәт.
Икесе дә Аллаһ бүләкләре,
Бүләкләргә – кадер һәм хөрмәт.

Урманнарны күреп сокланабыз,
Хатын-кыздан яшәү алабыз.
Тик беренче юмарт вә иләһи –
Табигатьтер газиз анабыз.

Июнь, 2013 ел.

Сихәт алам

Күкнең йөзен болыт каплап, кар тузынса,
Күңелемдә хис буранналары тузгыса...
Урманнарга барам, тыныч ланып калам.
Һавасыннан мин үземә сихәт алам.

Урманда тын. Агачлары горур баскан,
Бар табигать кышкы йокысына талган.
Тукран гына агачларны «туклап» йөри.
Ул урманда каравылчы булып калган.

Җир өстенә табигать ак җәймә япкан,
Агачларга сыкыланып кырпак яткан.
Һәр тарафта энҗе карлар җем-җем итә,
Әйтерсең лә, урман кышын чәчәк аткан.

Җәен монда – ямьле яшеллек дөньясы,
Чәчәкләргә бизәнәдер купшы алан.
Көзен: «Безне җыеп алыгыз», дигәндәй,
Каршы алыр шомырт, чия, миләш, балан.

Мәҗнүн гашыйк-гыйшкы янына баргандай,
Мин ашкынып моңлы урманнарга киләм.
Кочак җәеп алар мине каршы ала,
Әнкәм кебек сый-хөрмәтле табын белән.

Гыйнвар, 2014 ел.

Татар аланәсе

Гүзәл язып карап торам бер туташка,
Әйтерсең лә, әверелдем тораташка.

Асыл затның гүзәл күрке әсир итте,
Аң-акылым, үй-зиһенем баштан китте.

Күк капусы ачылгандай итте шунда,
Үзебезнең татар кызы булды пәйда.

Затлы күлмәк кочып алган нечкә билен,
Иңнәрендә дулкын чәчләр – ике толым.

Асылташлы муенсасы җем-җем килә,
Чаглышлары йөз-күзендә уйный, көлә.

Елтыр кара керфекләрен сирпеп тора,
Серле-сихри күз карашын безгә бора.

Карашлары елмаюлы, йөзе көләч,
Әйтерсең лә күңелендә балкый кояш.

Шомырт кара күз нурлары таш эретә,
Туң йөрәкне, әфсен укып, гашыйк итә.

Тамырларда куерган кан сихәт ала,
Хис-тойгылар йөрәкләргә ялкын сала.

Гүзәл әрәбәдәй ак тешләре ялт-йолт итә,
Энҗе-мәрҗән тезмәсенә исләр китә.

Мәҗнүн итә мәхәббәтле иреннәре,
Алсу кызыл шәфәкъ булыр тик тиңнәре.

Ике бите – ялтыравык көмеш диңгез,
Төпкеленнән ай калыккан кебек көндез.

Чәчкәләрнең гүзәллеге – йөзләрендә,
Йолдызларның җемелдәве – күзләрендә.

Ай, кояштан сихри нурлар сибеләдер,
Йөзләрендә тылсым булып чигеләдер.

Асыл йөзенә карасаң – күз камаша,
Әби-баба нуры күкән чорлар аша.

Әманәтне мирас итеп алган туташ,
Коръән нуры ямьгә төргән аны тоташ.

Аллаһыдан иңгән иман кәлимәсе,
Саф-инсафлык – ата-баба яд бирнәсе.

Күкләр биргән аңа хикмәти нәфислек,
Җирдән сеңгән нәзакәтле нәселлелек.

Ул Аллаһның бүләгедер, ул – чынбарлык,
Туташ безнең рухи байлык, милли барлык.

Тән-гәүдәсе – Галәмнәрнең камиллеге,
Төс-кыяфәт – табигатьнең төгәлләге.

Үрнәк түгел Рафаэльнең Мадоннасы,
Бар чагында татарымның Алиһәсе.

Бу могҗиза – тереклекнең йөзек кашы,
Хатын-кыз ул – кешелекнең асылташы.

Барыр җирем онытылды, тукталдым мин,
Сокланудан хәйран калып укталдым мин.

Бу туташтан күзен аллмый һәр егет-ир,
Йа Ходаем, гашыйкларга түземлек бир.

Гыйнвар, 2014 ел.

Мәхәббәт әлифбасы

Аш-су остасына әүвәл
Мамыктай кирәк оны.
Суы, тозы... Һәм, әлбәттә,
Мичнең кызу ялкыны.

Сөю-сөелү өчен дә
Гашыйк булуың зарур.
Мәхәббәтең яңа пешкән
Икмәктәй балкып торыр!

Июнь, 2014 ел.

Мәхәббәт турында

Мәхәббәт ул чәчкә, диләр,
Чәчәк тә беркөн шиңә.
Мәхәббәт ул – ялкын, диләр,
Ялкын да утсыз сүнә.

Мәхәббәт – якты нур, диләр,
Кояш нуры, ай нуры...
Кояш та офыкка бата,
Ай – кояшның сыңары.

Мәхәббәтнең рәвеше юк –
Гүзәлгә охшамаган.
Ул ирекле тойгы булып
Дөньяны яулап алган.

Мәхәббәт ул – илаһи хис,
Күзгә күренми торган.
Аллаһ аны, үзе кебек,
Мәңгелек итеп кылган.

Мәхәббәт – акыл, уй-фикер,
Юк нәрсәне бар итә.
Мәхәббәт булганда гына
Тереклек дәвам итә.

Мәхәббәт – күңел кояшы,
Гомернең дүрт фасылы.

Мәхәббәт – тормыш күчәре,
Яшәешнең асылы.

Мәхәббәт – җил, чиксез дәрья,
Галәмнернең илчесе.
Мәхәббәттән кодрәт ала
Җир – күкләрнең кешесе.

Җир йөзендә мәхәббәтнең
Тиңдәше юк, пары юк.
Дөнья үзе – чын тамаша,
Мәхәббәтсез заты юк.

Июль, 2012 ел.

Татар хатыны

«Изге хатын кыз табар» дип, әйтә халык, -
Изге гамәл кешелеккә дәвам бирер.
Халкыбызга мирас булган бу затлылык,
Ана сөте белән канга-аңга керер.

Борынгыдан килгән шушы күркәм сыйфат,
Татарымны милләтпәрвәр Кеше итә.
Изге хатын – һәрчак милли гүзәллектә, -
Гүзәллекнең җиде күккә буе җитә.

Изге хатын кергән йортта кояш чыга,
Урамнарга сибелә назлы нурлары.
Изге хатын – ирле хатын, өйле хатын,
Илне данлый асыл затның ул-кызлары.

Милли хисе, горурлыгы булган татар, -
Халкы өчен утка керер, ул – җанатар.
Халкыбызның милли сыйфатында калып,
Телебезне, динебезне саклап тотар!

«Изге хатын кыз табар» ди, безнең халык,
Кыз балада безнең байлык, безнең барлык.
Изге хатын кыз тапканда, ул тапканда
Ахыр заманга ча яшәр безнең халык!

Сентябрь, 2011 ел.

Сәрхушлекне яңгыр юмакчы...

Күкнең йөзен болыт каплап алган,
Шыпырт кына ява вак яңгыр.
Гәр тарафта шомлы, серле тынлык,
Изрәп калган урман, басу-кыр.

Яңгыр ява, җиргә леп-леп тама,
Җирләр, күкләр гүя тоташтан.
Яңгыр ява, гөрләвекләр ага,
Ике дөнья бергә тоташкан.

Яңгыр ява, күз яшьләре ага,
Яфракларга тама тамчысы.
Күлдәвектә хатын аулап ята,
Җир, күкләрдә хәсрәт ачысы.

Аунап ята хатын... Бөрәҗләрнең
Кадерлесе, әни дигәне.
Мәхәббәтнең сихри Алиһәсе, -
Кешелекнең энҗе-мәрҗәне.

Яфракларга леп-леп итеп тама
Болытларның ачы күз яше.
Сәрхәш хатын җирдә аунап ята, -
Табигатьнең тере җимеше.

Сәрхәш хатын җирдә аунап ята,
Кузгаталмый хәлсез гәүдәсен.
Күзен ача. Күрә: башын иеп,
Китеп барган бер ир шәүләсен.

Дәһшәт белән ялт-йолт яшен яшни,
Җир тетрәнә, Күкләр сыкрана.
Фәрештәләр канатларын җәеп,
Сакка баскан хатын янына.

Яңгыр ява, ташны тамчы яра,
Язмышлар да таштай ярыла.
Болытлар да яңгырларын коеп,
Офыкларга таба агыла.

Дөньяларны кара болыт кебек,
Саранчадай басты сәрхәшләр.
Адәм заты сантыйлана бара, -
Сәрхәшләрдән тумый шәхесләр.

Июль, 2013 ел.

Кызганыч хәл

Син инде оят-намусны
Сакламадың, гүзәл зат.
Сын-гәүдәңне товар итеп,
Базарга куйдың кат-кат.

Гыйшык уйнашлары «суккан»
Акчалар җилгә очты.
«Җилдән туган» балаларны
Ятимлек җиле кочты.

Юл чатында фәхишәләр
Тәннәрен ваклап сата.
Ил җилкәсендә сыкранып,
Гарип балалар ята.

Җәза

Билне ачып, кендек чокырын күрсәтеп,
Кәттә буллмак кәпрәеп йөргән кызлар, –
Ана булып, балалар тапты бер заман
Хәмер эчеп, тәмәке тарткан «йолдыз»лар.

Дөньяларны басып китте гарип бала,
Ата-ана арлы-бирле инде чаба.
Бик азлары мескеннәрен дәваларга
Ил халкыннан хәер сорап акча таба...

Табигатьнең кануннары кырыс аның,
Үтәмәсәң – җәзасына тарыр җаның.

Август, 2012 ел.

Мәнсезлек

Язын табигать ямьләнә,
Яшеллеккә төренә.
Мәнсез милли кызларыбыз
Шүрәледәй күренә.

Ярфраклар да пышылдаша:
«Гаурәтен ачкан, диеп.
Инсафлы булыр кызларның
Ояты качкан» диеп.

Ялгышларның иң олысы:
«Мин-мин» диеп, масаю.
Төнге күбәләкләр сыман
Ялкын очында бию.

Ноябрь, 2013 ел.

Аналар күрке

Ат башында чуклы нукта,
Кызлар күзе шул чукта.
Чуклыга кызыга кызлар
Фикерләве сай чакта.

Чит ил кызларына охшап
Кәттә буллмакчы мәгәр:
Яшерен җирләрен ачып,
Үзен «миссис»ка тиңләр.

Мода диеп, яфрак койган
Агач шикелле кала.
Кендек күрсәтеп йөргәннән
Үзенә каза ала.

Хатын-кызны күркәм итә
Кулындагы баласы.
Ихтирамга лаек була
Тик балалар анасы.

Тулгак бәясе

Карлар эреп, язлар җиткәч,
Кошлар да оя кора.
Мәхәббәт җимеше булган –
Балалар туа тора.

Бәхетле шат мизгелләрне
Әниләр бүләк итә.
Ана сөтенең куәте
Гомер буена җитә.

Күпме изгелекләр кылып,
Рәхмәтләр юлласак та...
Бер тулгакка җитә аллмас
Сабыен тапкан чакта.

Июль , 2016 ел.

Терәк бул!

Күрер күзгә гап-гади кыз,
Ким дә түгел, артык та.
Сеңел, Апа, Әни, диеп,
Еш әйтәбез тормышта.

Шул сеңел, апа, әниләр
Нишләр идек булмаса?..
Безгә гомер бүләк итә
Шул әниләр ләбаса.

Әниләргә Хак Тәгалә
Яныннан урын биргән.
Илаһилык сыйфатлары
Тик сездә генә, дигән.

Кемнәр белән яшәвеңне
Яхшы белергә кирәк.
Сеңел, апа, әниеңә
Була бел алтын терәк!

Август, 2016 ел.

Тәкатьсезлек бәласе

Тыелган җиргә үрелсәң
Башлар-күзләр әйләнә.
Сөйгән ярың ятка кала,
Кәнтәй сиңа өйләнә.

Ләззәтле минутлар өчен
Гомер буе тулисең.
Этле-мәчеле тормыштан
Аңгы-миңге йөрисең.

Гадәткә керсә...

Шыр ялангач сөяркәсен
Берәү төшендә күрә.
Елан сыман сырпаланып,
Ирнең куйнына керә.

«Өздереп ярат әле, – ди, -
Мәхәббәткә мәгънә сал.
Күңелемне күрче әле,
Мине бер серкәләп ал».

Фәхешлек гадәткә керсә,
Азгынлык кыйла күңел.
Төштәме ул, өндәме ул,
Аныcы мөһим түгел.

Июнь, 2013 ел.

Тәүбәгә килү

Ашыгулар, һай, шул ашкынулар...
Буй җитмәстәй җиргә үрелү.
Өтәләнеп, инде авыз пешкәч,
Сабырсызлык өчен үкеню.

Буй үссә дә, төпле акыл җитмәү –
Адым саен йөзне кызарта.
Тиктомалдан килгән гамәлләрең
Янәшәңдә торып озата.

Булмаса да усал ният белән
Хурланасың кылган эшеңнән.
Җир ярылса, төшеп китәр идең,
Оятыңнан баскан төшеңнән.

Сабырлыгым җуеп, мин үзем дә,
Явызлыгын әйтәм кемсәгә.
Илне талап, безгә яла ягып,
Җәбер-золым эшләп йөргәнгә.

Таш атканга, аш белән ат, дигән
Хикмәт ияләре халкымның.
Йа Ходаем, күркәм сабырлык бир,
Вәкарьлеген мирас акылның.

Ноябрь, 2015 ел.

Капма каршылык

Корсаклы кеше ямьсезме?
Ямьсез – ир заты булса.
Иске бишмәт мамыгыдай
Эче бүселеп торса.

Корсаклы кеше ямьлеме?
Ямьле – хатын-кыз булса.
Туар баласы нурыннан
Йөзләре балкып торса!

Февраль, 2015 ел.

Заманның яман сурәтләре

Аккош, бүре, бурсык... Намус саклап,
Тугры булып кала парына.
Хыянәтче, җае чыккан саен,
Кабахәтлек кыла ярына.

Берәүләре үзен ваклап сата,
Берәүләре уптым сатыла.
Һәркайсы да тәнен кәсеп итеп,
Акча кочагына атыла.

Кулдан-кулга товар булып күнә,
Файдалана һәркем үзенчә.

Берәүләре аяк сөртеп китә,
Берәүгә ул – тере үләксә.

Галиҗәнап акча ияләре
Курчак уеннары уйната.
Наркоман һәм сәрхүш миңгерәүне
Фәхишәләр белән шаярта.

Тәүфыйксызлар, оятсызлар, диеп,
Булыр иде, юкса, гаепләп.
Тик берәүгә – хан сые да михнәт,
Ә дуңгызга сазлык – сәгадәт.

Август, 2013 ел.

Җир алмасы

Барның нигә кадере юк?
Нигә кадерсез кеше?
Юкса, Җирдәге һәр адәм, –
Айның, Кояшның ише.

Тик Кояш назында гына
Табигать чәчәк ата.
Кеше күңеле дә – Кояш,
Тормышның ае калка.

Ай-кояштан нурлар алып,
Ялтырап, көлеп тора.

Кешеләр дә кан алмашып,
Хәерле тормыш кора.

Йолдызлар да аяз күктә
Тылсымлы җемелдәшә.
Мәңгелек җан һәм мәхәббәт
Туганлашып серләшә.

Акыл иясе булсак та,
Без – табигать баласы.
Барның кадерләрен дә белсәк...
Булырбыз Җир алмасы!

Июль, 2011 ел.

Чорнап ала язмыш

Көзге сары яфракларны куып,
Җилләр уйный, ясап тұгәрәк.
Ботагыннан аерылган яфрак –
Илсез-җирсез калган күбәләк!

Кешене дә язмыш чорнап ала,
Чужа куа тормыш юлыннан.
Кемне җилләр, кемне михнәт куа –
Фани дөнья шулай корылган.

Ноябрь, 2011 ел.

«Аккош күле» урманында

«Аккош күле» урманынан,
Әйтерсең сугыш үткән.
Ауган агач өемнәре
Урманны басып киткән.

Җирләнмәгән мәетләрдәй
Яталар алар череп.
Күңелне шом урап ала,
Аяныч хәлне күреп.

Апрель, 2012 ел.

Икмәк каргышы

Бер юньсезе ипи ташлап киткән,
Аунап ята агы-карасы.
Чүплекләрдә ризык өемнәре –
Алар минем йөрәк ярасы.

Бисмилламны әйтеп, башым иеп,
Биштәремә җыям шуларны.
Җаным сыкрый, күңелләрем җылый,
Искә алам ачлык елларны.

Кырык өчнең кытлык июнь ае,
Валчык та юк чебен яларлык.

Юктыр өйдә черек бәрәңге дә –
Кәлҗемәсе итеп ашарлык.

Мин шешенеп, цләр хәлгә җитеп,
Өстерәлеп чыктым урамга.
Авыл тып-тын, гця җансыз калган,
Аңым җуйдым, чумып томанга.

Көч-хәл җыеп, берчак керфек кактым,
Яшь бәбкәләр цлән чемченә.
Мин дә татып, бераз сихәт алдым,
Хәйран калдым цлән көченә.

Цлән ашап кемдер исән калды,
Ә кемнеңдер өзде бәгырен.
Ач-яланғач цлем аша цтеп,
Икмәкнең без белдек кадерен.

Бер юньсезе ипи ташлап киткән,
Аунап ята агы-карасы.
Ипи ташлап йөргән шул юньсезнең
Бугазында икмәк каргышы.

Июнь, 2012 ел.

Бичара!..

«Кесәсеннән йодрык күрсәтеп йөри» дип,
Дөрес әйткән тәнкыйтьче зат кая китте?
Бүген татар шундый хәлгә килеп җитте -
Кесәдән дә йодрык күрсәтүче бетте.

Күкрәк суккан, төкрек чәчкән ир-егетләр,
Өнсез калды милләтпәрвәр аталганнар.
Бәндә буллыш гамьсез каләм әһелләре,
Дер калтырап, юрган астына посканнар.

Бәндә ул – кол, илсез-җирсез, хак-хокуксыз,
Юктыр аның дәрәҗәсе җәмгыятьтә.
Гамәленә күрә – әҗере дигәндәй,
Урыны да булыр аның әкияттә.

Бер сүз әйтсә, биш караныр як-ягына,
Ишетмәде микән диеп кеше-кара.
Милли рухы, милли төсе, иман көче...
Бетеп барган алар бүген бер бичара...

Август, 2012 ел.

Илле яшь ул...

Илле яшь ул – бәрәкәтле август ае:
Җиләк җимеш белән тулы бакча ягы.
Кешенең дә дәверләрне тоташтырып,
Ил алдына исәп-хисап тотар чагы.

Илле яшь ул – бәрәкәтле август ае:
Гомернең дә дәрәҗәле челлә мәле.
Дөньялыкта кылган изге гамәлләрнең
Игелеген күрер көннәр алда әле.

Илле яшь ул бәрәкәтле август ае:
Үткәннәргә каерылып бер карар чак.
Эш-гамәлең милли төсен югалтмасын,
Нәсел-нәсәп җебе булсын кулда һәрчак.

Гыйнвар, 2013 ел.

Дуска

Хөрмәтле дустым Әхмәт Гаделгә багышлап

Аның йөзе һәрчак елмаюлы,
Тартып торыр сине үзенә.
Ягымлылык белән әсир итәр,
Караттырып нурлы күзенә.

Мәхәббәтле, назлы карашлары,
Күңеленең дәрте җилкетер.
Тамырларга сихәт, илһам биреп,
Хыялларга канат беркетер.

Сөйләгәне ихлас, дөрес булыр,
Кыяфәте күркәм, сөйкемле.
Көләч йөзе кояш сыман балкыр,
Май аеның таңы шикелле.

Ул һичкайчан сине үпкәләтмәс,
Рәнҗетерлек әйтмәс сүзләрне.
Җан җылысы назлар күңелеңне,
Язлар итәр сүрән көзләрне.

Колач җәеп, сөеп каршылыйсың,
Гәрчак, дустым, үзең булып кал.
Синдәйгеләр – халкым хәзинәсе,
Йөзең якты, телең – татлы бал.

Октябрь, 2012 ел.

Яшибез

Егерме беренче декабрь...
Дөньялар бетә диеп,
Җир астына төшеп посты
Берәүләр, борын чөеп.

Егерме икенче декабрь,
Күктә кояш нур чәчә.
Бункерда әрләп авазы:
«Дөнья бетмәде кичә».

Декабрь, 2012 ел.

Очты мәгърип ягына

Бүген төнлә бер төш күрдем:
Шәүлә баскан да, имеш.
Намаз укыгандай итә,
Сурәт каршында килеш.

Әле генә шәүлә иде,
Әле генә ул – елан.
Кәлтә елан гына түгел,
Көйдереп чага торган.

Ул әле сәҗдәгә китә,
Шәүләгә охшап кайта.

Куллары тәсбих уйната,
Авызы гайбәт сата.

Йөрәгемә кадамакчы
Кылычтай очлы телен.
Зәһәренә агуламак
Тәнемнең ачык җирен.

Ул мине гәүдәсе белән
Уратып алмак була.
Яшькелтем кара койрыгын
Муйныма саллмак була.

Тыпырчынам, качмак булам,
Тик аягым абына.
Әй елан, аждаһа булып,
Очты мәгърип ягына.

Декабрь, 2012 ел.

Елан елына аяк басканда

Еланнарның бар төрлесе:
Бар эресе, бар вагы.
Кешеләр дә төрле-төрле, -
Бар карасы, бар агы.

Ак, кара төстәгеләрнең
Бар яхшысы, яманы.

Төстә түгел, эчендәдер
Гәркемнең үз еланы.

Бар күзлекле елан сыман
Ыжылдый торганнары;
Кеше чагып, бәла ягып,
Тормышын корганнары.

Бар әле кәлтә еланнар -
Алары гавам кебек.
Елан корбаны булырга
Язмасын Ходай берүк.

Декабрь, 2012 ел.

Ахырзаман

Дөнья беткән икән, имеш,
Җир өсте тулы мәет.
Ерткычтай әшнә-дусларын
Төшендә күрде Зәет.

Исрафил сур өрде, шулчак
Барча мәет терелде.
«Мөселман булабыз» диеп,
Аллаһ каршына килде.

Кеше канын койганнарны
Аллаһ гафу кылмады.

Җир-ана да мәртәтләрне
Куенына алмады.

... «Шушы хәшәрәт комсызлар
Аяусыз талый мине.
Балаларым, диеп ничек
Атыйм денсез кавемне?»

Сыкранып әйтте Җир-ана,
Күкләр яшен уйнатты.
Хәшәрәтләрне шайтаннар
Тәмуг утына атты.

Җәзадан качмак Зәетне
Сабыйлар хакы тотты.
Хәрам мал-мөлкәте белән
Нәфесе кабып йотты.

Декабрь, 2012 ел.

Дисәк тә...

Дөнья чуар, төрлесе бар,
Бар яхшысы, яманы.
Кайберәүләр гомер буе
Белми яши чаманы.

Дөнья һәрчак хәрәкәттә,
Хәлләр үзгәреп тора.

Яшәештә көрәш бара,
Тормышны сүтә-кора.

Дөнья ямьле, ул сөйкемле -
Тылсымы күзне буа.
Адәм заты үлә-бетә
Дөнья артыннан куа.

Ә ул – вәсвәсәле шайтан,
Кызыктыра, котырта.
Җиде үлчәп кисмәгәнне
Төп башына утырта.

Кеше хакы, хәрам ризык -
Тыелган аш дисәк тә...
Гөнаһны кыла торабыз
Язуклыгын белсәк тә.

Тик терсәкне тешләп буламый
Мең үлеп терелсәк тә.

Октябрь, 2013 ел.

Табып буллмый

Шагыйрь әйткән: «Елак коммунистны
Куяр идек, – диеп, музейга».
Истәлеккә елак коммунист та
Каллмаган шул торып музейда.

«Чиновниклар илне талый», – диеп
Әйтер идек коммун абзыйга.
Ришвәт аллмас чиновникны тапса...
Куяр иде халык музейга.

Июнь, 2011 ел.

Фәлсәфи яңгыр

Күк тутырып тансык яңгыр ява,
Күкләр тетри, яшен ук ата.
Чыңлап торган яңгыр тамчылары
Җирдә яшәү ямен яңарта.

Яңгыр ява, дөнья сихәт ала,
Басу-кырлар ямьгә төренә.
Чәнечкеле шайтан таягы да
Чәчәк аткан кебек күренә.

Ак болытның ачык «тәрәз»еннән
Йөгереп чыга кояш нурлары.
Яңгыр суын гөсел иткән гөлләр -
Җир-ананың җәннәт хурлары.

Аллы-гөлле салават күпере
Офыкларны кочкан дугалап.
Бер ягында кояш, ә бер якта
Болыт тора күкне тамгалап.

Шаулап килгән яңгырлары белән
Ачык дәрес бирә табигать.
...Хатын-кызның – болыт,
Гаярь ир-атларның яшен
Икәнлеген белдем, нинаять!

Табигать һәм кеше – тугандашлар,
Бер үк холык, бер үк шөгыльләр.
Табигатьне җан дустыдай күрсә -
Мәңге яшәр җирдә кешеләр...

Август, 2013 ел.

Вәт замана!

Эт туенда – эт ялаша һәм өрешә...
Ә туйларда егет белән кыз үбешә.
«Бер... Ике... Өч... Унау!» – диеп шаулый табын,
Туганнары үрле-кырлы сикерешә.

Этләр өчен бу табигый сайланышлар...
Йола булып акыл иясенә күчте.
Итәк-сатак өскә күтәрелгән саен,
Кеше заты этләрдән дә түбән төште.

Август, 2012 ел.

Икейөзле бәндәгә

Кешенең үзеннән түгел,
Сүзеннән сора, диләр.
Сүзләре аның кеммеген
Ап-ачык итеп сөйләр.

Әйткән-сүткән сүзләрендә
Чагылыр күңел кыры.
Нинди ул? Бармы кальбендә
Мөкатдәс иман нуры...

Ни чәчсәң, шуны урырсың,
Дип әйтә безнең халык.
Чир китсә дә, гадәт китмәс -
Үзгәрмәс яман холык.

Аңа бу яман гадәтләр
Яралганда салына.
Кем һәм ничек булачагы
Нәселеннән алына.

Зыялы бер адәм булып,
Кыланса да теленнән.
Тумыштан булган зәһәре
Ташып чыгар эченнән.

Ялган сөйләр, яла ягар
Башыңа бәла тагар.
Хәтта ай һәм кояштан да
Булмастай гаеп табар.

Әнкәем гел әйтә иде:
«Тизәккә басма, – диеп. -
Гомерлеккә табы калыр,
Бетераллмассың юып».

Ноябрь, 2009 ел.

Яши шундый...

Бу комагай ашар өчен яши,
Кап корсагы, ай-һай, иләмсез.
Балачактан булды ул талымсыз,
Комсызлыгы аның йөгәнсез.

Май катламы телем-телем булып,
Әгъзаларга көн дә сыланды.
Куас чиләгеннән ташып чыккан
Камыр сыман корсак салынды.

Ул һаман да, ашык-пошык килеп,
Чик-чаманы белми туена.
Бу комагай, баш-аягы белән,
Әверелгән нәфес колына.

Борын кадәр борынны да узып,
Корсак йөри сөзеп һаваны.
Тыны бетә, мыш-мыш килеп үтә,
Хәтта иң-иң якын араны.

Кибән хәтле корсак күтәрүдән,
Камыт булып аяк сыгыла.

Йөрәк сызлый, кан басымы дулый,
Тамырларга нидер тыгыла...

Күп ашаган – аз яшәгән диеп,
Белеп әйтә булыр ил-халык.
Бу дөньяда озак яшәү сере
Берәүгә дә түгел яңалык.

Ә бит кеше акыл, хис иясе,
Тереклекнең энҗе-җәүһәре.
Зат сыйфатлы, күркәм кыяфәтле –
Аллаһының мәшһүр әсәре.

Июль, 2013 ел.

Сайлау-сайлану

Берәү уйлый, берәү чиный, берәү мырлый, -
Кара урман аланында җыен шаулый.
Алдау-талау, хәйлә-мәкер остазлары -
Бер-берсеннән уздырышып тәхет даулый.

Хәйләкәрлек остасы – төлке сүз алды,
Купшы койрык шәрәфләрен сузып салды.
«Аю – безнең барыбызның уртак вожак,
Общак кануннарына да тугры калды.

Сүзен үти, вәгъдәләрен ул онытмый,
Безнең хокук, мәнфәгатьләрне дә саклый.

Алыш-биреш, өлеш бүлеш – безнең кулда,
Кода-кодагыйлык безне бик шәп яклый».

Алга чыгып ала карга каркылдады,
Чәпчи – оча чәүкә халкы чәрелдәде.
«Ботакка утырган өчен» салым түләү –
Кош-кортларны – диде алар – чәбәләде».

Арыслан да өстәл сугып сүзен әйтте:
«Мыштым аю безнең урман заты, диде -
– Биюдә дә ишәкләрдән һич калышмый,
Ил буенча мәтәлчек атылып йөрде».

Талкый торгач, ошбу җыен карар кылды –
Аю тагын ил-тәхеткә хуҗа булды.
Тамашалы шау-шулар да тынып калды, -
Гадәтенчә, аю да йокыга талды.

Урам эте – тик алабай һау-һау өрә,
Киселгән койрыгын болгап тавыш бирә.
Аю табанын суырып яткан чакта,
Ил-җирләрдә эт кануны хөкем сөрә.

Июль, 2011 ел.

Тере курчак

Өф-өф итеп кенә аны
Уч төбендә йөрттеләр.
Сөекле бердәнберләрен
Тере курчак иттеләр.

Иң затлысы, иң татлысы -
Гәммәсе дә балага.
Буйга җитте, ә ул һаман
Курчак – ата-анага.

Ир һәм хатын икәүләшеп,
Бишләр тирәсендә.
Картларның пенсияләре -
Малайның кесәсендә!

Гыйнвар, 2014 ел.

Кем ул?

Үзен кашка тәкәсенә
Тиңләп йөргән беришгер.
Дөньяның кендеген тоткан -
Батыргали, имештер.

Масаеп сөйләр сүзләрен,
Тубәнсетеп башканы.
Әйтерсең, ул иярләгән
Баш бирмәстәй кашканы!

Гавалану, тәкәбберлек -
Атландыра ишәккә.
«Мин-минлек»ләр сәбәп була
Ишәктән дә төшмәккә.

Декабрь, 2013 ел.

Бәгъзе каләм иясенә

Мәшһүрләрне үзенең тиңдәше санап,
Утыра ул канәфидә кукыраеп.
Эзли булыр көндезен чыра яндырып,
Әдиплеккә тиңдәшлекне хәлдән таеп.

Җисеменә исеме туры килмәүне,
Тик берәү дә әйтергә кыюлык тапмый..
Утырудан чәберчек йомырка басып,
Башыңны ташка орсаң да, чебеш чыкмый.

Гаҗәп түгел, хыялланса шигъри күңел,
Чиләр генә такылдамас сөяксез тел.
Тик агачка кунган карга – бөркет буламас,
Җем-җем иткән бәллүрләр дә энҗе буламас!

Декабрь, 2013 ел.

Гыйбрәтле җәза

Дәшмәү – иң зур җәза.
(Халык әйтеме)

Мактанчыкның теле орчык,
Зыр-зыр әйләнеп тора.
Бүленмәсне бүлеп куя,
Саламнан сарай кора.

Мин фәлән, мин төгән, диеп,
Чүпрәсез бал күпертә.
Сүз боткасы базарында
Вак балыклар үрчетә.

Дус-ишләре беравыздан
Шундый карар кылдылар:
Ләм-мим... Аңа эндәшмәскә,
Сүз әйтмәскә булдылар.

Ғәпләшер кешесе беткәч, –
Сынды аның түземе.
Үз-үзе белән сөйләшеп,
Йөри мескен берүзе.

Ғыйнвар, 2014 ел.

Фетнәче?

Мин Ғазазил булып баш күтәрдем, Ғафил булып калма. *Нури Арсланов.*

Татарның шагыйре әнә
Аллаһка баш күтәргән.
Үзен Ғазазилга тиңләп,*
Үзен-үзе «үртәгән».

Миллион кеше Аллаһының
Барлыгына ышана.

Миллион кеше аның ише
Алласыздан бушана.

Аллаһыны инкарь итү -
Яшәешне юк итү.
Дөньяда яшәеш буллмау -
Безнең чәнчелеп китү.

Ләкин тормыш дәвам итә.
Галәмнәрнең чиге юк.
Бер адашкан чебен дулап,
Тәрәз дә ватканы юк.

Аллаһ барлы, әллә юклы -
Бу акыл дәрәҗәсе.
Аллаһка тел тидермәгән
Гичбер хикмәт иясе.

**Газазил фәрештә – Иблис дип тә атала.*

Декабрь, 2013 ел.

Шулай булыр!

Кеше белән җәнлекләр дә яши,
Мең төрле кош оча һавада.
Ләкин алар, комсыз кешеләр күк,
Запас азык тотмый ояда.

Ашау өчен түгел, яшәү өчен
Көн күрәләр җирдә – юнь табып.

Табигатьнең кануннарын тоткан -
Яшәештә кала сакланып.

Ләкин кеше – акыл, хис иясе,
Үлә-бетә байлык бүлешә.
Гәрчә аның, башка мәхлуклардан
Юктыр артык хакы, югыйсә.

Байлык өчен, җир-су өчен кеше,
Үлем чәчә – атып як-якка.
Үзе кебек, миллионлаган затлар,
Башын сала канлы туфракка.

Җирнең астын өскә китерсә дә,
Явызлыгы булыр заядан.
Анасыннан шәрә туган бәндә –
Шәрә китеп барыр дөньядан.

Декабрь, 2013 ел.

Бәхет әлифбасы

Бәхетле, бәхетсез булу –
Әйтәләр: «Язмыш эше».
Тик язмышка өмет баглап,
Яшәмәс тырыш кеше.

Үз тормышын үзе корыр
Хәләл хезмәттән үреп.
Бәхетле гомер кичерер,
Тормыштан рәхәт күреп.

Эш-гамәлен башкарыр ул,
Тәүфыйк яменә төреп.
Бәрәкәтле итеп яшәр,
Барның кадерен белеп.

Дан-дәрәҗә, мал-мөлкәтләр
Бәхетле итми затны.
Хатын-кызга – коткы салма,
Кол итмә син, ир-атны.

Кеше хакы, хәрәм байлык
Албасты булып басар.
Чәфес корты кимергәннән
Татлы йокысы качар.

Шат-бәхетле булу өчен
Кирәкми титул, тәхет.
Игелек кыла белүең –
Үзе Илаһи бәхет!

Март, 2014 ел.

Дөньяви сагыш

Әби-баба, бертуган абый-апалар,
Канкардәшләр авыл зиратында ята.
Каберләре исәннәрнең кадерендә,
Исемнәре баш очларындагы ташта.

Язмыш безне чит җирләргә илтеп чәчә,
Берәүләрне шул туфракта горбәт итә.
Каберенә килеп дога кылучыны,
Һәүмиз җаннар өметләнеп һәрчак көтә.

Кендек каны таммаган бу чит җирләрдә,
Үзен мәхрүм итеп тоя мәрхүмнәр дә.
Шуңа кеше әрнеп туган якка бага,
Сансыз булып каллмас өчен хәтерләрдә.

Газизләрен гомер буе ана көтә,
Сагышлардан бәгырьләре өзгәләнә.
Намаз саен изге теләкләрен юллый,
Аллаһыга сәҗдә кылып ул тезләнә.

Бәхет эзләп киткән йөрәк парәләрен
Ата-ана хәер-догасы сакласын.
Дөньялыкта адашкан үз бәндәләрен.
Хак Тәгалә рәхмәтеннән ташламасын!

Адәм затын, акыл иясе, дисәк тә,
Гомер буе талкый аны тәкъдир-язмыш.
Ләүхелмәхфүз кушканнарын үтәп яшәү -
Дөньялыкта аталадыр, диеп тормыш!

Югалту

Хөкүмәт үзенчә яши,
Халык яши үзенчә:
Туган-туганын күрмичә,
Хәл-әхвәл белешмичә.

Халык хөкүмәтне җуйды,
Ә хөкүмәт – халыкны.
Олигарх-чиновниклар
«Патша» булып калыкты.

Үзе туйса, күзе туймас
Яңа байлар яу тота.
Имансыз Дәҗҗәл токымы
Илнең байлыгын йота.

Кайчак сүгенәсе килә:
Сатыйм, диеп, анасын.
Чичекләр итеп табарга
Дөреслек тантанасын?

Май, 2014 ел.

Саклап тора җәза

Кемдер затлы ризык ашап чәй эчәдер,
Тәм-томнардан ләззәт алып наз кичәдер.
Ә берәүләр ипи белән сөтле чәйгә,
Аллаһыга шөкер итеп көн күрәдер.

Табындагы ризыклары хуҗасының
Чынбарлыгын чагылдырып, тасвир итә:
Кеше талап мал җыючы башкисәрме,
Әллә гади гавам булып гомер көтә.

Бу икенең азыклары ни исемле?
Кайсы хәрам ризык булып, кан ислеме?
Иясенең эш-гамәле көн төслеме?
Әллә айсыз һәм йолдызсыз төн төслеме?

Әниләрнең, сабыйларның күз яшьләре...
Юкмы каргыш, ачы каһәр тәгамендә?
Тамагына таш булып утырыр мәгәр,
Я манатлы эшләр булса гамәлендә.

Бәхет-шатлык, исән-саулык юлдаш булыр,
Аш-сулары бисмиллалы хәләл булса.
Гаҗәп түгел: кеше хакы җәза булып,
Җан коючы киллер кебек саклап торса.

Июнь, 2014 ел.

Бәрәкәтле хәрәкәт

Күктә ай, кояш балкышы,
Йолдызлар елмаеша.
Җир-күкләр бергә тоташа
Илаһи нурлар аша.

Тоташа җаннар, җисемнәр –
Тормыш шулай ярашкан.
Яшәеш мәңгелек булып,
Дөньялардан оешкан.

Үй-хисләргә киртәләр юк,
Мәхәббәттә юк ара.
Дөньяларны берләштереп,
Җаннар йөри цзара.

Берсе килә, берсе китә –
Яшәеш дәвам итә.
Гыйбадәтле булганнарны
Игезәк тормыш көтә.

Август, 2014 ел.

Манзара

Йорт каршымда парлы каен цсә,
Иңгә-буйга чибәр, мәһабәт.
Хуш ис бөркеп яшел яфраклары,
Йөрәгемә биреп көч-сихәт.
Пар каеннар әйләнәсен бизәп,
Төлчәчәкләр балкый шатланып.
Бер аллагач башын күккә чөеп,
Каеннарга карый сокланып.

Яфракларга кояш төшеп кунган,
Җирләр-күкләр нурда коена.
Кошлар моңы тылсымлы ямь өсти
Мәңгелекнең тормыш җырына.

Табигатьнең сихри бизәкләре –
Искитәрлек гаҗәп манзара.
Җир-әнкәйнең изге гамәлләре
Күңелләрне бәйли цзара.

Октябрь, 2014 ел.

Көзге манзара

Үләннәрне көзге җилләр тарый,
Чәчәкләрне талкып тибрәтә.
Агачлардан очкан яфракларны
Урам себерттереп йөдәтә.

Йөзгә бәреп бозлы яңгыр ява,
Үзенекен итә елак көз.
Үзәк өзгеч салкыннары белән
Кыш бабай да килер инде тиз.

Гомернең дә дүрт фасылы бар шул:
Яшьлек балкып ата чәчәген.
Кояш белән торып кәсеп кылган
Сизми кала көзе килгәнен.

Октябрь, 2014 ел.

Чабата турында

«Татар тұрә булса әгәр,
Чабатасын тұргә эләр».
Шулай дигән элгәреләр,
Шулай дия хәзергеләр.

Тик замана тұрәләре
Чабата элеп маташмый.
Миллиардерлар булып яши,
Хәрам эчә, хәрам ашый.

Әйтерсең ул бу дөньяга
Мәңге яшәргә килгән.
Урлап, талап җыйган малдан
Әйтәләр: «Шайтан көлгән».

Чабаталар музейларда
Лаеклы урын алыр.
Хуҗалары җәһәннәмдә
Чабатасыз да калыр.

Июнь, 2015 ел.

Җыерчык

Җыерчыклар куна йөзгә
Яшьләтә дә.
Яшьлектәге җыерчыклар
Тик йөзләрдә.

Җыерчыклар сырлар уеп
Куна тәнгә.
Тәннән сихәт, көч-куәтләр
Киткәннәрдә.

Җыерчыклар өсти-өсти
Яши бәндә.
Тик буллмасын җыерчыклар
Күңелләрдә.

Июнь, 2015 ел.

Ак болытлар

Зәңгәр күктә ак болытлар йөзә,
Төрле сурәтләргә охшаган.
Атлар, кошлар... Кеше рәсемнәрен
Әйтерсең лә кемдер ясаган.

Гамьсез генә ак болытлар йөзә
Җилләр ирегенә бирелеп.
Кешеләр дә, ак болытлар сыман
Көн күрәләр илдән сөрелеп.

Ак болытлар...
Кысыр болытларның
Бушап калган эче-тышы да.
Болытлар күк, агым кочагында,
Уй-фикерсез, гамьсез кеше дә.

Уй-фикерсез, гамьсез кешеләр дә
Көн күрәләр гомер үтсенгә.
Ил дә, дин дә, тел дә – кысыр сүзләр,
Кысыр болыт кебек кешегә.

Июнь, 2015 ел.

Бер киңәш

Мәгънәсе бар һәр эшнең, дип,
Бик белеп әйтә халык.
Эшне җиренә җиткереп
Эшләүдә булыр хаклык.

Эленке-салынкы эшләү –
Тиңгелдер егет эше.
Эшсез тору – хөрәсәнлек
Оят, адәм көлкесе.

Күрше-күлән карап тора,
Холкыңны сынап тора.
Үзеңнең ким икәнеңне
Күрше кызыннан сора.

Июнь, 2015 ел.

Мандатлы кул

Мандатларны сайланып та,
Сатып та алып була.
Сатылган мандатлар белән
Кәттә урыннар тула.

Чиләктәгене иләккә,
Иләкнекен чиләккә.
Әвештереп утыралар
Мандатлылар «кетәк»тә.

Ашау – байдан, акча мулдан
Үрчеп тора дәцләттә.
Кануннарның заказлысы
Мөһер ала нәүбәттә.

Халык зары – җилгә оча,
Вәгъдәләр – онытыла.
Шәхси мәнфәгатьләр генә
Үй-хәтердә тотыла.

Мандатлы кул кулны юа,
Ике кул битне юа.
Чиновниклар, ябырылып,
Байлык артыннан куа.

Урлый, талый, ришвәт ала,
Ярсып хәрам мал җыя.
Мәнсез байлык хәерсезне
Яманга борып куя.
Үзе туйса, күзе туймый,
Нәфесен белми тыя.
Чөнки үзе өчен язган
Куштан канунга сыя.

Июль, 2015 ел.

Эх-ма!

Ут күрмәгән – уткурсә,
Көндез чыра яндыра.
Рәсәйнең яңа байлары
Илне өнсез калдыра.

Халыкны кычкыртып талый
Денсез улы-кызлары.
Чит дәүләтләр казнасында -
Нефть, газ долларлары.

Олигарх, чиновниклар
Җир-суны алды билән.
Көне-төне типтерәләр
Җиде кыйтганы иңләп.

Рәсәй малы – мал түгел,
Халыкныкы җәл түгел.
Эх-ма!

Сентябрь, 2013 ел.

Байлык белән сынау

Энҗе-мәрҗән диңгез төпләрендә ята,
Алтын-көмеш җир астында посып ята.
Энҗе-мәрҗән, алтын-көмеш хуҗалары -
Балчык сыйфатына кайтып – гүргә ята.

Энҗе-мәрҗән, алтын-көмеш кебек затлы
Байлык өчен кан коела, җан кыела.
Адәми зат җиргә килгән көннән алып,
Сугыш бара, үлем аша мал җыела.

Энҗе-мәрҗән, алтын-көмеш бинаһая,
Тик аларга акчалы бәндәләр ия.
Кан койган һәм җан кыйганның варислары:
«Бу байлыклар безнең шәхси милек», – дия.

Ялтыраган һәр нәмәстә алтын түгел,
Пыяланы энҗе дип алдану җиңел.
Тышкы ягы ялтыравык адәмнәрнең,
Дөньялыкта гамәлләре изге түгел.

Алтын-көмеш бер сынык икмәккә тормый,
Шулар өчен ил-жирләрдә талаш тынмый.
Чәфес колы булган комс ыз бәндәләрне
Хак Тәгалә ялтыравык белән сыный.

Энҗе-мәрҗән, алтын-көмешнең тылсымлы
Җемелдәвеннән берәүләр аңын җуя.
Чәфес колы, байлык колы булганнарны
Маймылдан да түбән дәрәҗәгә куя.

Көне-төне корал коя денсез илләр,
Үз-үзләрен юк итәргә җитә булыр.
Кан-яшь сеңгән барлык-барлык байлыклар да
Диңгез асты, җир астында булып калыр.

Гыйнвар, 2012 ел.

Кем син?

Һәркемнең бәхетле булып,
Рәхәт яшисе килә.
Рәхәт яшәү тыелмаган,
Бу хакта һәркем белә.

Тик берәүләр яшәү өчен
Җан тирен түгеп эшли.
Ә берәүләр тир түккәннең
Икмәген ашап яши.

Шул берәүләр урлый-талый,
Кеше хакына керә.
Хәрам ашый, хәрам эчә, –
Муллыкта көнен күрә.

Ә берәүләр берәүләрнең
Юк гаепләрен эзли.
Булдыксыз булуларында
Булдыклыны гаепли.

Имеш, аны аңламыйлар
Юкса ул – акыл заты.
Ялкаулыгын җиңә алса,
Булыр иде эш аты.

Бирәң нәфесен тыялмый,
Хисапсыз мөлкәт көри.
Вәсвәсенә ияреп,
Шайтан юлында йөри.

Син дә, ипташ, йөрмисеңме
Борының күккә чөеп?
Үзең мөгезсез булсаң да,
«Мин – кашка тәкә!» – диеп.

Сентябрь, 2015 ел.

Ә син беләсеңме?

Уйлан, Кешем!
Нәрсә өчен,
Килгәнсең син бу дөньяга?
Нәрсә кылдың,
Ни кыласың?
Бармы синнән берәр файда?

Бу дөньяда синнән башка
Бөҗәкләр бар,
Бар җанварлар,

Һәр кош-кортлар,
Һәр ерткычлар
Яшәүләндә бар хайваннар.

Һәр диңгез һәм океаннар –
Искиткеч зур,
Серле алар.
Һәркайсында яшәү җаннар -
Меңнәрчә төрле алар.

Һәркемнең бар үз дөньясы:
Кайсы оча,
Йөзә кайсы.
Кайсы җир өстендә йөри,
Һәр җәнлек җан иясе бар.

Һәр тереклек дөньясының
Һәр Ходаи вазифасы.
Һәрнәрсәнең
Һәркемнең дә
Бер-берсенә бар файдасы.

Әй син, Кешем,
Җир-әнкәдә,
Аллаһының Хак вәкиле.
Синең эш-гамәлләреңдә
Мәхлукларның тормыш хәле.

Сиңа Аллаһ акыл биргән,
Файдасын күр аның, дигән.

Акыл, фикер, уйлы затлар
Яшәеш канунын белгән.

Дөньядагы җан иясен
Бердәй күреп, хөрмәт иткән.
Табигатьнең байлыклары
Яшәр өчен мулдан җиткән.

Тиңе итеп кадерләгән
Җирдәге һәр җан иясен.
Күз карасыдай саклаган
Үсемлекләрнең дөньясын.

Ошбу байлыклар хуҗасы –
Аллаһыга сәҗдә кылган.
Чиксез рәхмәтләрен әйтеп,
Гәрчак гыйбадәтле булган.
...Гомер үтә искән җилдәй,
Җил белән бит син дә бердәй!

Июль, 2015 ел.

Әй, син кеше!..

Галәмнәрдә иң камил зат, иң гүзәл зат –
Тиңсез акыл ияседер, җирдә кеше.
Аллаһының сый-хөрмәте, нигъмәтенең
Кадерләрен белми, яши тик бер ише.

Ни кызганыч:оятсыз, комсыз адәмнәр
Хуҗа булып тора җиһан киңлегендә.
Вәхшиләрчә таламакта җил-әнкәне,
Ут уйнатып, туймас җаһил сурәтендә.

Шайтан колы, Иблис ише бу адәмнәр
Үлә-бетә байлык туплый, кан-яшь коя.
Миллиардлаган кеше хакы, хәрам малы
Нәселенә мәңгелекле каһәр җыя.

Әй син, кеше! Чал тарихка сәяхәт кыл,
Җир йөзендә яшәеш шулай көйләнгән:
Кавемнәрнең берсе килгән, берсе киткән...
Мал-мөлкәтләр, гәүдәләр ташка әйләнгән.

Вакыт үткән... Тормыш янә дәвам иткән.

Август, 2017 ел.

Тотка

Гап-гади ишек тоткасы,
Кайсы тимер, кайсы җиз.
Ачылганда, ябылганда
Ишек тоткага гаҗиз.

Такта ишектә дә тотка,
Зиннәтле ишектә дә.
Тоткалар һәрвакыт уяу –
Иртәдә дә, кичтә дә.

Кайсы ишек ялсыз эшли,
Кайсысы бикле тора.
Берәүнең күңеле актыр,
Ә берәүнеке – кара.

Кара күңел, ак күңел дә
Дөньяда тормыш кора.
Берәүнең гамәле хәләл,
Берәү хәрамгә керә.

Хәрам гамәлдәге йортның
Тоткалары җиз булыр.
Тәкәббер хуҗасы кебек
Тышитан масаеп торыр.

Ләкин куллар орынмаудан
Җиз тотка да тутыга
Эчендәге ямьсезлеге
Йөзенә калкып чыга.

Такта ишек тоткалары
Эш-хезмәттә шомара.
Әдәп белән каршы ала,
«Хәерле юл», дип кала.

Җәннәт ишекләренең дә
Шома булыр тоткасы.
Әһелләрен каршы алыр
Аллаһ хәер догасы.

Август, 2015 ел.

Уйландыра

Күптән түгел танылган шагыйрьнең
Укып чыктым шигырь китабын.
Лирик шагыйрь. Ләкин бер канатлы
Әдип икәнлеген аңладым.

Дөньялыкта чакта ялкынланып
Шигырь чисталыгын хаклады.
Поэзия дигән гүзәлкәйне
Пычрак сәясәттән саклады.

Әдәбият таҗы – шигырь, диеп,
Ихлас күңеленнән яратты.
Бар гомерен аңа багышлады,
Шигырьләрдә шау чәчәк атты.

Коеп куйган шагыйрь булды мәрхүм
Шигырьләре – остаз буллмакта.
Кояш кебек балкыр иде мәгәр,
Милләт гаме торса иң башта.

Ялкынлы сүз. Халык көткән сүзне
Кирәк иде әйтү тормышта.
Сәясәтсез көрәш киңлегендә
Очып буллмый сыңар канатта.

...Шигырь язды,
Җан-күңелен салды,
Яхшы шагыйрь булып танылды.
Төнге күктә
Якты эз калдырып,
Бер канатлы йолдыз атылды.

Август, 2015 ел.

Замана мактанчыгы

Сәрхүш бичара мактана:
«Без – дөнья асыллары.
Без – искиткеч, әйтерсең лә,
Табигать фасыллары.

Урманнар, басу-кырлар да
Диңгезләр, елга-күлләр...
«Россия» диеп йөртелә
Без яулап алган җирләр.

Илләрне, дала-чүлләрне
Дошманнардан әрчедек.
Мунча һәм аракыга да
«Русский» сүзен чәпедек.
Җир астына, җир өстенә -
Гәммәсенә без хуҗа.
Теләсәк... Тамга салырбыз
Ай-кояшка, йолдызга.

«Без-без» диеп, борын чөеп,
Сәрхүш китте абынып.
Сазламыкта аунап ята
Уткәннәрне сагынып.

Октябрь, 2013 ел.

Эт һәм песи мәрәкәсе

Ач үлемгә дучар булган бичара эт,
Күрше песи оясына керде бәреп.
«Почмагыңда вакытлыча яшәт, зинһар,
Күрше хакы – Аллаһ хакы» диләр, диеп.

Вакытлыча диеп кергән бичара эт,
Үткен, зәһәр тешләренә ирек бирде.
Песиләрне колга санап, малын талап,
Ә үзләрен кырып, һәлак итеп йөрде.

«Чир китәр, гадәт китмәс» ди аксакаллар,
Канкойгыч эт әле дә шул гадәтендә.
Толерантлык дигән мәкер, хәйлә кора,
Песи халкы юкка чыгу халәтендә.

«Якты чырай күрсәтсәң эт-хәерчегә
Яхшылык та сорар» – дигән безнең халык.
Яши аллый толерантсыз этләр белән
Бер ояда песиләр дә кардәш булып.

Июль, 2013 ел.

Ярый әле...

Бакчабызның ташландык бер почмагында
Комсыз билчән җәелеп үсеп утыра.
Тирә-юньне яфраклары белән каплап,
Үләннәрнең сут-җелекләрен суыра.

Балкып торган гүзәл чәчәкләрне күреп,
Көнчелектән хөсетләнеп көйсезләнә.
«Акыл белән аңлап булмас» бу баскынчы,
Тора-бара албастыга ук әйләнә.

Аршин белән үлчи алмаслык киңәя,
«Мин үзем дә серле, үзгә дөнья» – дия.
Җиргә-күккә, ай-кояшның нурларына
Чәнчеп-кадап, тик бер үзе булмак ия.

Җил-яңгырны, яктылыкны, һаваны да
Бу комагай башкаларга бирмәс иде.
...Ярый әле, көрәк тоткан берәү килде
Тамырларын берәм-берәм чабып өзде.

Июль, 2015 ел.

Менә шулай

Син уйлыйсың: "Дөнья көчленеке,
Ни кылса да, алар хаклы", - дип?
Бар дөньяны дер селкеткән илләр,
Ирләрнең дә ләкин хакы юк!

Бернәрсә дә мәңгелек түгел шул,
Вакыт үткәч, чери, таркала.
Хәтер булып, кылган гамәлләрдән,
Тик яхшы һәм яман эз кала.

Ә син – бәндә, туймас корсак колы,
Бертуктаусыз читтә сугыштың.
Ил-җирләрне яулап, кан-яшь койдың,
Бүселенгән саен корыштың.

Әнә илең – иясез йорт синең,
Тишек-тошык, нигез какшаган.
Баскынчылар башкаларны изеп,
Үзенең дә рухын таптаган.

Урлап, талап җыйган байлыкларың
Күрсәтмәдә сиңа игелек.
Кеше хакы булган хәрам малның
Бәддогасы сиңа мәңгелек!

Көннәрең дә инде санаулыдыр,
Хәер-дога сиңа кылмамын.
Акылыңа килсәң... Шатлыгымнан,
Каберемнән калкып чыгармын!

Август, 2017 ел.

Этлек

Эт симерсә, хуҗасын тешли, дип,
Дөрес әйтә зирәк халкыбыз.
Киллмешәк ач урам этләренең
Авызында милли хакыбыз.

Ил-җирләрне талап, басып алды
Котырынган этләр өере.
Кан-яшь коеп үтә халкыбызның
Биш йөз еллык хаксыз гомере.

Эт эт инде, тешен ыржайта да,
Тешләп ала кулың, ботыңнан.
Хак-хокуксыз халык телсез кала,
Газап чигә җәбер-золымнан.

Чинди гөнаһ шомлыклары өчен
Язмыш тага катгый җәзасын?
Әллә Аллаһ сынау итеп бирә,
Эт-мәчеле Иблис җәфасын?

Ат азгыны – тайга иярер, ди,
Эт азгыны – Иблис ялчысы.
Азгыннарны яшен булып сугар
Үт-ялкынлы Аллаһ калчысы.

Безнең мәгыйшәт

Сорау ала заман: Дөрес яшисеңме?..
Һәрнәрсәгә җавап бирәсе.
Эшләп тапкан хәләл мал-мөлкәтнең
Бәрәкәтен иде күрәсе.

Ни кылсаң да – шуның эзе кала:
Белеп-белми кылган хаталар...
Барысы да, бумеранг булып,
Үзеңә үк кире кайталар.

Бернәрсә дә эзсез генә узмый,
Кемнең яхшы, кемнең яманда.
Яман белән бил алышыр өчен
Яхшы кирәк һәрбер заманда.

Тәкъмид

Исә җилләр, күңә комнар... бетә эз...
Дердмәнд

Җилләр искән, комнар күкән, чорлар үткән,
Дөньялыкта мәшһүр затлар яшәп киткән.
Могҗизалы илаһи серле һәйкәлләр
Мирас булып, безнең чорга килеп җиткән.

Сызым булып, рәсем булып, язма булып,
Кавемнәрнең заман тарихы язылган.
Гасырларның уй-фикере тонып калган,
Җәмгыятьне бәхетле итә аллмаган.

Җилләр исәр, комнар күнәр, чорлар үтәр,
Пәйгамбәрдәй даһи затлар килер-китәр.
Аллаһының сәгадәтле иман нуры,
Коръән нуры җир-күкләрдә мәңге яшәр.

Июнь, 2017 ел.

Татарга эндәшү

Кем дип атыйм, нинди сүзләр әйтим,
Татарымны ничек уятыйм?
Бәгыремне парә-парә телгән
Җан сыкравын ничек аңлатыйм?

Чик бу кадәр васыйсызландың син?
Кемгә болай үлек итәсең?
Үзен үзе чаккан чаян сыман
Бетәсең ич, мордар китәсең.

Яр читенә килен җиттек ләса,
Алдыбызда үлем упкыны.
Кемнәр хәер-фатыйхасы белән
Ташлап китмәк булдык дөньяны?

Әллә адәм мәсхәрәсе булыр,
Телибезме котсыз язмышны?
Әллә Ана Телебезне барлап,
Гөрләтикме Җирдә тормышны?!

Ата-баба шан дәүләтләр т откан
Дунай-Иртыш Җир-су арада.
Скиф-һуннар, хәзәр-болгарларның
Каны ага безнең тамырда!

Барысы да үзебездән тора,
Гасырларның бездә мирасы.
Әманәтне, милли әләм итеп,
Без – татарга алып барасы!

Август, 2017 ел.

Әйтер сүзем

Язмышыма шөкерана кылып,
Гомер сукмакларын мин үттем.
Иң мөкатдәс үй-фикерләремнең
Аксакалы булып җитлектем.

Газиз халкым, изге ният белән,
Сиңа әйтер сүзем телемдә.
Сиңа булган хөрмәт, мәхәббәтем
Гәрвакытта күңел түремдә.

Көнчелек һәм бердәм була белмәү –
Халкыбызның явыз дошманы.
Яшик дисәк, бердәм милләт булып,
Хәрам итик әүвәл аларны!

Үз-үзеңне яраткандай итеп,
Сөю кирәк татар дөньясын.
Ата-баба әманәтен үтә –
Алыйм дисәң, хәер-догасын.

Борынгылар, кыйтгаларны кичеп,
Данлы-шанлы милләт булдырган.
Милли мәгърифәтле телле-моңлы
Ил-дәүләтләр төзеп калдырган.

Әй, татарым! Торгыз дәүләтеңне,
Хуҗа бул син мирас җиреңә!
Татар булып, телең, моңын сөеп,
Мәңге яшә ислам динендә!

Март, 2017 ел.

Мәңгелек сорау

Галәмнәрнең иге-чиге юктыр,
Әмәл дә юк буен үлчәргә.
Күләменә – фән колачы җитми,
Акыл җитми күкне иңләргә.

Гади генә яфрак, нәни бөҗәк, -
Уй-фикергә сыймас могҗиза.
Табигатьнең асыл серләренә,
Галәмнәргә Аллаһ тик хуҗа.

Тик бердәнбер Хак Тәгалә генә
Яшәешнең Әлхәм догасы.
Дөньяларны юктан бар кылучы –
Тик Үл гына Күкләр Раббысы.

Йолдызларны, Җирне, Ай-Кояшны
Элеп куйган Күккә беркетеп.
Ай-Кояшның нуры, Җир сулышы
Дөньяларны тота бар итеп.

Шифа нурлар, яңгыр тамчылары
Җир-Әнкәгә бирә бәрәкәт.
Тереклеккә тормыш бүләк итә
Тик Аллаһы. Аңа зур рәхмәт!

Көч-куәтле Аллаһ - илаһи зат,
Ул мәңгелек кодрәт иясе.
Чиркәүләрдә сурәт, җансыз потлар...
Аларны соң кемнәр диясе?

Март, 2012 ел.

Нәфес турында

Бу дөньяда барысы да
Парлы булып яралган.
Тискәре, уңай сыйфатлар
Я нәшә урын алган.

Яшәеш дәвам итсенгә
Алар булуы мөһим.
Я хшы-яман һәр сыйфатка
Булсын акылың хәким.

Һәр сыйфатның үз холкы бар
Үз горефе-гадәте.
Үзенә генә хас булган
Характер, табигате.
Нәфес – илаһи сыйфаттыр, –
Иҗатчысы тормышның.
Ләкин вәсвәсәле нәфес
Хәвефлесе язмышның.

Акыл, хикмәт хәлфә булсын,
Нәфесне шәкерт итик.
Изге гамәлләр кылуда
Нәфесне узып китик.

Июнь, 2017 ел.

Хисләрем дисбесе

Иртә торсаң – ит пешә, ди,
Соңга калсаң – бит пешә.
Яшьтән иҗтиһат иткәннәр
Дан-щөһрәткә ирешә.

Соңга калдым. Кабаландым –
Куып җитәргә теләп.
Уй-фикерем, сүз сөрешем
Җанымны алды билән.

Ашыккан – ашка пешкән, дип,
Дөрес әйтә шул халык.
Ашыкканда иң мөһиме,
Китә бит онытылып.

Аллә әмәлен тапмадым
Төшенмәдем серенә.
Әсәрләрем чиле-пешле
Язылды күк үземә.

Юкса инде бик тырыштым,
Бөтен җан-тәнем белән.
Хис-тойгыларым дисбесе
Хак Тәгаләдән иңгән.

Соң булса да, уң булсын, дим,
Бәрәкәтле юнь булсын.

Көзге җимеш татлы була, -
Тәме телләрдә калсын.

Ихластан әйткән сүзләрем
Яшәешкә ямь бирсен.
Ай-кояштай нурлар бөркеп,
Күңелне назга төрсен.

Әметле теләкләр белән
Сөеп яратам сезне.
Ничек булсам, шул сыйфатта
Кабул итегез мине.

Май, 2017 ел.

Татар язы килер...

Җир-күкләрне көн дә нурга төреп,
Кояш чыга, төнлә ай калка.
Аллаһының рәхмәт йолдызлары
Ғаләмнәрдән сәлам балкыта.

Нурлы кояш, якты ай, йолдызлар
Җир-әнкәне сөя иркәләп.
Аллаһыга шөкерана кылып,
Бар тереклек яши бергәләп.
Тик берәүләр үзенеке итмәк
Басып алган чит-ят җирләрне.
Российская нация ясап,
Бетермәкче милли телләрне.

Тик кояшны, ай һәм йолдызларны
Бүрек белән буллый томалап.
Хак динебез – Кояш, телебез – Ай,
Ә йолдызлар – халык, миллионлап.

Кышлардан соң язлар килгән кебек
Татар язы, аяз көн килер.
Барысы да Аллаһ рәхмәтендә, –
Ирек яулап халык сөенер.

Март, 2017 ел.

Урыс «демократия»се

Агач башында утырган
Шыксыз козгын баласы,
Авызын каерып ачкан -
Ризык сорау чарасы.

Иртәдән карылдый башлый,
Әнкәсе ризык ташый.
Башкаларның да өлешен
Козгын баласы ашый.

Ачыргаланып кычкыра,
Һаваны дер селкетә.
Барча кош-кортлар куркудан
Аңарга ризык илтә.

***

...Мәскәү албастылары да
Ясакның сала дәвен.
Керемнең йөздән сиксәнен
Бирә буйсынган кавем.

Әрсез козгын баласыдай,
Мәскәүләр йолкый-талый.
Ил-җирсез калган халыкның
Чәсел-тамырын талкый.

Корыды, эзсез югалды
Борынгы хак кавемнәр.

Җинаять фаш ителерме,
Җавапны тотар кемнәр?

Рәсәй үз бәхетсезлеген
Башкалар аша күрә.
Халыкларны каршы куеп,
Мәкерле хәйлә үрә.

Гаепсезгә яла яга,
Ялган тарих тарата.
Буллмаганны булды, диеп,
Халыкларны каралта.

Илештер, Алтын Урдада
Кыргый халык яшәгән.
Әдәпсез надан татарлар
Илеш, кеше ашаган.

Ләкин татар угланнары
Читектән атта йөргән.
Мәгърифәтле татар илен
Барлык кыйтгалар белгән.

Ясакны да татар түгел,
Үз урыслары җыйган.
Калита кебек караклар
Байлыкны урлый торган.

Тик чабаталы урысның
Тормышы булган такыр.

Курше халыкны таларга
Яу чапкан ул һәр тапкыр.

Ачның ачуы яман шул,
Ул да әмәлен таба, –
Изге Болгар, бай Казанга
Утыз тапкыр яу чаба.

Пестрый башкисәрләре
Болгарга ябырылган.
Талау, көчләү, үтерүдә
Аларга тиң булмаган.

Явыз Иван ир-затларны
Кылыч аша үткәрә.
Гөрләвек булып аккан кан
Безнең төшләргә керә.

Миллионнарны һәлак иткән,
Мәңнәрне чукындырган.
Еллар буе халкыбызның
Асыл затларын кырган.

Аллаһ каргаган шул токым
Татарга нахак тага.
Имеш, без киртә булганбыз,
Урыс барасы чорга.

Аның артта калуында
Имеш, татар гаепле.

«Сәрхуш башыңны уйлат та
Үзеңнән тап гаепне!»

«Без серле» дип масаюдан
Тормышың алга китмәс.
Үзең яратмаган халык
Сине дә хөрмәт итмәс!

Юкса, имеш, без – татарлар -
Чакырылмаган кунак.
Идел-Йортны басып алды
Рәхмәтсез әрәмтамак.

***

Урыс үзен шәп дип саный,
Гөнаһсыз зат, имештер.
Әдәлия булып кылана,
Ә үзе залим иштер.

Кол ителгәннәрнең каны
Кулыннан тамып тора.
Басып алынган ил-җирләр
Ирек юктан сыкрана.

Кайда барма – урыс шауы,
Урыс рухы бөркелә.
Бүтән милләтләр канунда
Телдән мәхрүм ителә.

Сукыр шовинизм яуы
Үз халкын да телгәли.

Үзенә хас мәлгунь шайтан
Урысны вәсвәсәли.

Бөекдержавачыл зәхмәт
Аздыра аны һәрчак.
Һәм ул иблис тарафыннан
Һәлак булачак курчак.

Ә хәзергә һәр әсәрдә
Ул искиткеч баһадир.
Сурәттәге шул баһадир –
Тормышта явыз яугир.

Тарихы риваятьләрдән,
Ялганнан әвәләнгән.
Үз халкының әкиятләре,
Хыяллары шәйләнгән.

Ә чынлыкта бу халыкка
Шикләнеп карый җиһан.
«Халыклар төрмәсе» диеп,
Ленин дөрес атаган.

Урыс «демократия»се
Коллык белән буталган.
Илне яңадан ГУЛАГ лы
Итәсе генә калган.

Юкса Рәсәй аталадыр
Демократик ил диеп.
Хаксыз-хокуксыз халыклар
Югала бара эреп.

* * *

Абына-сөртенә Рәсәй,
(Илле ел алга киткән)
Илләр артыннан чаба.
Якынаясы аралар,
Тик һаман ерагая.

Дөнья халкы урысларга
Баскынчы итеп карый.
Кырымны алучыларны
Оккупант диеп, саный.

Рәсәй белән Украина
Җир өчен тарткалаша.
Ә Кырымның чын хуҗасы -
Татары бар лабаса!

Тик газ торбалары гына
Илләрне тоташтыра.
Торба шартлагандай хәтәр
Афәтләр булып тора.

Торбалардан нефть малы
Читләргә агып тора.
Мәскәү яулап алган җирләр
Урысны туендыра.

Тик шулай да державниклар
Масая, борын чөя.
Газ, нефть, алтын, алмазлар...
Урысларныкы, дия.

Юкса бит, туксан тугызы,
Рус басып алган җирләр.
Ул җирләрдә хәр-саулыкта
Яшәгән башка илләр.

Үз гореф-гадәтләрендә,
Үз кануннарын тотып.
Барысын да баскынчылар
Аягы китте сытып.

Илдә тоталь рәвеш алып,
Урыслаштыру бара.
Татар белән татар русча
Аралаша үзара.

Рәсәйдә урыслар гына
Яшәргә тиеш, имеш.
«Урыс илендә яшәгән
Урыс булырга тиеш!»

Шулай куша мәскәүләләр
Шулай ди, Кирилл агай.
Илнең сөйкемсез сөяге
Чик булдык әле болай?

Юкса бит князьлекләрне
Бер дәүләткә беркеттек.
Чик буйларын да ныгытып,
Урыс дәүләте иттек.

Инде Рәсәй дип аталган
Дәүләттә яшәсәк тә...
Чын күңелдән тир түгәбез,
Ни генә эшләсәк тә.

Җиренә җиткереп эшләү –
Татарның намус эше.
Миннән киткәнче дип әйтмәс,
Чын татар булган кеше.

Без – тынычлык сөйгән халык,
Бәхетебез – хезмәттә.
Урлау, талау, кеше хакы –
Хәрам гамәл бигрәк тә.

Иксез-чиксез далаларда,
Күккә ашкан тауларда,
Ата-баба ат уйнаткан,
Иген иккән кырларда.

Хәләл хезмәт белән яшәү –
Халкымның бәрәкәте.
Илгә, дингә тугры калу –
Гасырлар галәмәте.

Бисмилласын әйтеп яшәү –
Борынгылар гадәте.
Бүген дә мактауга лаек
Татарымның хезмәте.

Татар баласы яшьтән үк
Эшкә уралып үсә.
Корал тотып сафка баса,
Җанын бирә, кирәксә.

Ватан иминлеген саклау –
Ата-бабадан килә.
Татар егете Рейхстагның
Башына әләм элә.

Бүген Рәсәй дип аталган
Зур илдә без яшибез.
Иртыш-Дунай аралары –
Безнең әүвәл җиребез.

Иң борынгы заманнардан
Әби-бабаларыбыз,
Бу җирләрдә гомер чиккән
Иңләп-буйлап гомер итә
Бүген туганнарыбыз.

Себереме, Алтаемы,
Урталык та, Урал да...
Барысы – татар җирләре,
Татар хуҗа аларга!

Без бит бик борынгы халык
Тамырларыбыз тирән.
Данлыклы төрки кавемнәр
Төрле исемдә йөргән.

Булып скиф, һун һәм кыпчак...
Далада гомер сөргән.
Ватанпәрвәрлек әнкәйләр
Сөтләре белән кергән.

«Арысландай сугышырга,
Аттан каты эшләргә»...
Гәр борынгы гадәтләрне
Тырышабыз үтәргә.

Бу күркәм асыл сыйфалар
Ата-бабадан килә.
Әманәтнең канунлыгын
Чын татар яхшы белә.

Илне, динне, телне саклау –
Безнең мөкатдәс бурыч.
И татарым, бурычыңны
Берүк туләргә тырыш!

Илсез, динсез, телсез кеше –
Әйтәләр: «Үле кеше».
Илле, динле, телле яшәү –
Гәр халыкның үз эше.

И татарым, бер уйланып,
Кара әле үзеңә.
Чакырылмаган кунактай
Ятлар кергән өеңә.

Элгәреләр ләббәйкә диеп,
Башын иеп тормаган.
Үзен мәсхәрә иткәнне
Өйдәш итеп тотмаган.

Борынгылар үрнәгендә
Безгә дә җаен табып,
Ул йолкыш козгын баласын
Очырырга бик вакыт!

И кардәшем, горурлыгың,
Кайда рухың ныклыгы?
Дәүләтчелегең торгызу –
Булсын намус сафлыгы!

Үлтын Урда, биш ханлыклар
Дәррәү аякка бассын.
Борынгы ил-җиребезгә
Мирасчы татар кайтсын!

Август, 2015 ел.

Язмыш тамгасы

Мәңгелек бернәрсә юктыр,
Комга әйләнә таш та.
Казык очларында озак
Утыра аллый кош та.

Каргыш йоткан бу дәүләтнең
Терәүләре какшаган.

Шовинистлар каралтысы
Җимерелә башлаган.

Канлы, күз яшьле нигездән
Кача булыр бәрәкәт.
Денсез, имансыз дәүләтнең
Язмышында – һәлакәт.

Декабрь, 2015 ел.

Чарасызлык

«Тотса мәскәүләр якаң».
Г.Тукай.

Эгоист шовинистлыгы
Йөзендә калкып тора.
Эчендәге тәкәбберлек
Сүзеннән саркып тора.

Мәскәүнең баш чиновнигы
Кәпрәеп борын чөя.
Милли чүп-чарга тотарлык
Бездә акча юк дия.

Шул чиновник милләтләрне
Каезлап ясак җыя.
Булыр-булмас миллилекне
Ахыр чигенә куя.

Гыйнвар, 2012 ел.

Һәлакәт

Болыннарны, тугайларны, басу-кырны
Ямьгә төреп, шау чәчәкләр атар иде.
Җан иясе илаһи бу гүзәллекне
Газиз җаны сыман итеп саклар иде.

Аллы-гөлле чәчәкләргә хәйран калып,
Бар тереклек исләре китеп сокланды.
Җан-тәненә рәхәтләнеп сихәт алды,
Ата-ана, бала-чагалар шатланды.

Көтмәгәндә ерткыч көрән аю килде,
Тылсымлы бу гүзәллекне сытып изде.
Бал кортларын пыран-заран китерде ул,
Саф җирләрне аркылыга-буйга гизде.

Тетрәнде җир, сыкранды күк өзгәләнеп,
Җан-ияләр канлы күз яшьләре койды.
Аюның бу һәлакәтле ябрылуы –
Җир тетрәүгә, су басуга тәңгәл булды.

Июль, 2015 ел.

Ялган һәм чынбарлык

Күрше дәүләт фильм әмәлләде,
Миф, риваять белән тутырды.
Фантазия, яла-гайбәт туглап,
Җәмгыятькә ялган тоттырды.
Әдәп-әхлак, күркәм холык юктыр
«Урда» дигән нәфис фильмдә:
Янәмәсе кыргый каннибаллык
Хөкем сөрә Урда илендә.

Ханнар затсыз, сарайлары котсыз,
Урдалылар, имеш, ерткычлар.
Әшулай да, тел-лөгать, белем-гыйлем
Чәлдергән бит бездән урыслар.

Заманында мәшһүр дәүләт иде
Татарларның Алтын Урдасы.
Дөньяларга фән, мәгърифәт чәчте,
Кыйтгаларның булып хуҗасы.

Изелсәк тә дүрт йөз илле сәнә -
Саклап калды халык үз йөзен.
Урыс, татар авыллары әйтер
Кемнең кем һәм нинди икәнен.

Июль, 2013 ел.

Кем?

Ул исерсә, йә кәефе китсә,
Башлар кыеп күңлен күтәрде.
Хәмер эчеп, кәнизәкләр кочып,
Кан-яшь коеп гомер үткәрде.

Исән чакта, Галиҗәнап кенәз
Адәмнәрнең өзде гомерен.
Меңәрләгән башны чапты җәллад,
Бу залимнең үтәп әмерен.

...Еллар үтте. Илнең тарихында
Канлы мәхшәр «дан»га уралды.
Кешелеккә золым кылган тиран
Изге кеше булып танылды.

Башкисәрне чиркәү «святой» итте,
Тәхет саклый канлы балтасы.
Илбасарлык кәсеп булган илдә
Халкы ничек – шундый патшасы.

Ноябрь, 2015 ел.

Чиге бармы?

Залимнәрнең кылган явыз гамәлендә
Гафу итәр, гафу итмәс золымнар бар.
Коръән әйтә: үтерүдән үч алу -
Мөселманга рөхсәт ителгән хак карар.

Ирек өчен шәһит киткән ир-атларның
Хатыннары яңь-яшь килеш ирсез кала.
Дошманнардан канга-кан дип үч алырга
Җефетләре билләренә җиһад сала.

Шартлый йортлар, вокзал, мәктәп, тимер юллар,
Зур калалар тузан булып күккә оча.
Тирәләрнең тәкәббер кирелегеннән
Бер гөнаһсыз сабыйларны үлем коча.

Бу мәхшәрнең фанилыкта чиге бармы?
Кешеләрнең гамь-афәтен аңларлармы?
Әллә адәм Иблис – уттан алданамы?
Әллә тәкъдир яшеннәргә ялганганмы?

Хатын-кызлар ут кабызсын учагында,
Бала-чага булсын табын кочагында.
Явызлыклар кылып йөргән залимнәргә, -
Яшәү тәмуг уты булсын һәрчагында.

Май, 2011 ел.

Сабан туе галәмәтләре

Бер Президент Сабантуйда чыллмәк ватты, -
Татар иле азатлыктан колак какты.
Берсе катыктан тешенә тәңкә тартты,
Халкыбыз хаксыз-хокуксыз хәлдә калды.

Тагын берсе тимерчедә чүкеч тотып,
Чүкеп алды әзер тимер ат дагасын.
Хак Тәгалә ат дагасы язмышында, -
Чүкеч-сандал арасында калдырмасын.

Июнь, 2011 ел.

Килер бер көн!

Килер бер көн: (инде күп калмады),
Үзләштерер Кытай Себерне.
Бандит Ермак татарларны кырып,
Яулап алган иде бу җирне.

Татар белән кытай борынгыдан
Ут күршеләр булып яшәгән.
Җир эшкәрткән, иңләп көтү көткән,
Бертуганнар кебек көн күргән.

Килер бер көн: явыз баскынчылар
Җавап тотар гафу ялварып.
Асты-кисте алар, чукындырды –
Халкыбызны канга батырып.

Кунак ашы – кара-каршы булыр,
Таш аткanга ашлый атарбыз.
Хак Тәгалә кушканынча яшәп,
Мәхшәр илен җәннәт ясарбыз.

Май, 2014 ел.

Буталган мәгыйшәт

Гәртәр хайван, балык, кош-кортлар да
Бердәм булып яши дөньяда.
Гәммәсе дә аек, бер-берсенә лаек,
Үз кардәше белән һәркайда.

Парлашмый һич карга чәүкә белән,
Эт бүрегә чыкмый кияүгә.
Гәммәсе дә нәселдәше белән,
Бер гаилә булыр яшәүдә.

Ә татарның ир һәм хатын-кызы
Ятлар белән ятак бүлешә.
Халкыбызның милли хәзинәсен –
Мәни орлыкларын өләшә.

Акча бирсә, алар риза булыр,
Ни теләсә – шуны бирергә.
Үзе белән иманын да сатып,
Шайтан куенына керергә.

Күркәм әхлак, әдәп, гореф-гадәт,
Әби-бабаларның сафлыгы...
Татар белән бергә бетеп бара,
Борынгының рухи байлыгы.

Үзен сөйгән горур татар идек,
Сыртсыз токым килде аллашка.
Дәүләтебез торгызылган чакта,
Авыз ачып иде калласка.

Июнь, 2013 ел.

Соң булса да...

Вакыт – дәва дисәләр дә,
Сагышы кала икән.
Үткәннәрне сагынулар
Гомергә бара икән.

Үкенеп искә аласың
Ялгышлык – хаталарны.
Бер яхшы сүз җитәр иде
Ямарга яраларны.

Шул тылсымлы яхшы сүзне
Күңелдә саклап йөрдем.
Яшерен яну-көюне -
Егетлек диеп белдем.

Исән чакта ник әйтмәдем:
«Тик сине сөям» диеп?
Җанымда сулкылдый яра,
Бәгырьне телеп-телеп.

Тик соң инде. Көзләр җитте,
Аккошлар инде очты.
Мәхәббәткә сусаган җан
Сыкранып күккә ашты.

Җиргә ятып, күккә багып
Сөеклемә баш орам.
Һәүмез мәхәббәтем белән
Ялгызым басып торам.

Июль, 2011 ел.

Соңгы сүз

Акыллы ир үз хатынын яманламас,
Яшереп ул тотар йөрәк серләрен дә.
Чинди генә аяныч хәлләр күрсә дә,
Чит-ятларга сөйләмәс һичберләрен дә.

Бу кануни таләпләрне үтәмәдем,
Шуңа тойдым илнең кырын карашларын.
Үз башыннан үткәргәннәр генә белә,
Яшь гомернең сагышларда агышларын.

Үкенсәм дә, язганнарым дөрес-хактыр,
Бәгыремдә һаман сыкрау, ялкын-уттыр.
Үткәннәргә инде салават дисәм дә...
Хыянәтне истән чыгарасым юктыр.

Хәмер эчеп, сукбайлыкта йөргән ана, -
Яратуга, назга мохтаҗ ике бала,
Күңелемдә һаман гарьлек, әрнү, яра...
Барысы да зар елауда булып кала.

Мин боларны оныталлмый – гафу итәм,
Син дә кичер. Кичерегез мине гавам.
Кирәгеннән артык әйтеп, гөнаһ кылдым,
Бу соңгы сүз. Ярлыкагыл мине, Аллам.

Август, 2011 ел.

Эчтәлексез тормыш

Юл куюлар мөмкин иде...
Үзсүзле булып калдык.
Син үзеңчә, мин үземчә,
Тормыштан сабак алдык.

Үпкәләшмик инде хәзер,
Икебез дә гаепле.
Атка, тәртәгә сылтадык
Үзебезнең гаепне.

Икебезне ятим иттек,
Сыкраттык бәгырьләрне.
Югалттык бер-беребезне,
Белмәдек кадерләрне.

Сөю ашы бирер чакта,
Күңелләргә таш аттык.
Яшьлек мәхәббәтебезне
Кайтмас җиргә озаттык.

Гадәтсезлек корбаны без,
Гаепле үзебез тик.
Яшәүнең формасы калды -
Ләкин эчтәлеге юк.

Гыйнвар, 2014 ел.

Нәҗмиз иттең

Резеда кызыбыз истәлегенә.

Йолдыз булып әле яна идең,
Атылдың да – нурлар сибелде.
Очып киттең, безне нәҗмиз иттең,
Күңелләрнең уты сүрелдә.

Тамагыма төер тыгыла да,
Күз яшьләрем ага мөлдерәп.
Эчтән үксеп җаным-тәнем елый,
Сагыш талый җанны өзгәләп.

Шатлык качты, кайгы-хәсрәт басты,
Зар-сыкранып үтә көннәрем.
Үзәк өзгеч соңгы карашлары
Бәгырьләрнең айкый тирләрен.

Сагынулар аша, хәтер булып,
Уткәннәрнең кайта авазы.
Юксынудан иза чигүләрнең,
Хәерлегә булсын азагы.

Март, 2017 ел.

Тормышымның син йолдызы идең

Кара төннең күк гөмбәзен ертып,
Балкып торган йолдыз атылды.
Җем-җем иткән энҗеләрен чәчеп,
Күңелемнең таҗы ватылды.

Офыкларга чумып ул юк булды,
Кара япты күкләр йөзенә.
Бәгыремне парә-парә телеп,
Әҗәл алды сине үзенә.

Тормышымның син йолдызы булып,
Яна идең күңел күгендә.
Гомерлеккә җан ярасы булып,
Сагыш калды йөрәк түремдә.

Сентябрь, 2015 ел.

Яңарыш

Гашыйк булдым, башым җуйдым,
Ярсу хисләр күңелдә.
Мәхәббәт давылы уйный
Күңелемнең күгендә.

Йөрәгемне тишеп үтте
Чын мәхәббәт уклары.

Дәртем – яшен булып яшьни,
Ялт-йолт итә утлары!

Яңгырлар булып явам да...
Янә күкләргә ашам.
Әйтерсең, яшен ташы мин –
Җир-күкләрдә адашкан.

Җаным күкләр булып күкри,
Ажаган булып яшьним.
Ашкынулы хисләремне
Авызлык итеп тешлим.

Яшьлек язлар булып килде,
Ләйсән яңгырлар яуды.
Тойгыларым бөреләнеп,
Хисләрем яфрак ярды.

Ай-кояш елмаеп карый,
Нурлардан илһам алам.
Мәхәббәтемдә коенып,
Җаныма сихәт табам.

Июль, 2013 ел.

Әнием – Хәбибҗамал

Аллаһ миңа әниләрнең
Игелеклесен бирде.
Әни гомере буенча
Изгелек кылып йөрде.

Утыртты тайган буынны
Таҗәп осталык белән.
Савыгып китте өенә
Култык таякта йөргән.

Аның нәфис бармаклары
Тылсымлы иде сыман.
Төзәлде сырхау-сызлаулар
Кулы орыну белән.

Җан газабы кичергәнне
Терелтте дога укып.
Эчендәге чир-зәхмәтне
Әйтерсең алды йолкып.

Рамазан, мәүлид аенда
Тансык абыстай иде.
Иң Алласыз заманда да
Дин сабаклары бирде.

Әйтә иде: яхшылыкның
Очы-чиге юк, диеп.

Һәр изге эш-гамәлләрне
Башкарды ихлас сөеп.

Халкым табибәсе идең,
Әнием-Хәбибҗамал.
Аллаһ сөеклесе булып,
Мәңгелек җәннәттә кал.

Сентябрь, 2013 ел.

Чагылыш

Әниемнең теше төште,
Үзгәреп китте йөзе.
Төсендә – нурлар балкышы,
Әйтерсең, кояш үзе.

Битен яулык чите белән
Каплап сөйләшә сүзен.
Болыт япкан кояш сыман
Яшерә ярты йөзен.

Олыгаеп та китте күк,
Сүзләре дә мәгънәле.
Уйчанланды, җитдиләнде,
Килде җитлегү мәле.

Яулык читеннән сөйләшү -
Ак әбиләр гадәте.

Әдәплелек, әхлаклылык –
Булган киңел дәүләте.

Намуслары ак яулыктай
Чиста булган, пакъ булган.
Итагатьлелек, тыйнаклык
Дәрәҗә булып торган.

Вожданлы, оятлы булу да –
Борынгылар мирасы.
Вәкарьле милли горурлык -
Хатын-кызлар дөньясы.

Әниемдә бу сыйфатлар
Ай кебек калкып чыкты.
Кояш кебек нурлар чәчкән
Йөзенә күзем бакты.

Әбиләремнең нурлары
Гүя әнкәм битендә.
Җиде буын чагылышы
Балкый яулык читендә.

...Милләтебезне бизәсен
Инсафлы гореф-гадәт.
Черек теш төшүе генә
Булмасын моңа сәбәп!

Июль, 2015 ел.

Күкләр галәмәте

Килә болыт, ява яңгыр,
Елгалар ага ташып.
Җир-күкләр тантана итә,
Бер-беренә тоташып.

Ялт-йолт итеп яшен яшьни.
Ут-ялкын күкне коча.
Күкләрнең илаһилыгы –
Энҗе сандыгын ача.

Мин дә яшен булып яшьним,
Мин дә күкләр өлмәте.
Могҗизалы Җир-Әнкәнең
Мәхәббәт галәмәте.

Апрель, 2015 ел.

Ак болыт инде

Җир-күкләрне шатландырып
Күкләр күкрәде.
Иркен сулыш алды һава,
Җирнең күкрәге.

Шифа тамчыларын койды
Сәйәр болатлар.
Яшәешкә җан өрергә
Килгән тансыклар.

Бөтен дөнья җан иясе
Сихәтлек алды.
Күкләргә башларын иеп,
Догалар кылды.

Рәхмәт әйтте. Хәерле юл
Теләде гавәм.
Телле-телсез зекер итте
Күңеле белән.

Күкнең йөзен чуарлады
Кысыр болытлар.
Күләгә ясый торганнар
Күктә торыплар.

Мин үзем дә суын сипкән
Ак болыт инде.
Беркемгә күләгә булып
Төшмәсәм иде.

Июнь, 2015 ел.

Ялгышлыклар, хаталар...

Үйланам да ис-акылым китә,
Күпме хата, күпме ялгышлык.
Әйтерсең лә тормыш – үзе хата,
Ялгышлыклар хәттин ашырлык.

Ә бит, юкса, мин цземне (гафу),
Юньле кеше диеп санадым.
Изге ният белән гамәл кылу –
Намус эшем итеп карадым.

Яшәсәм дә милли әдәп-әхлак,
Дини гореф-гадәт сагында,
Ләкин әрсез хата, ялгышлыклар
Чрчи тора тормыш кырында.

Хаталарны искә төшерәм дә,
Оят булып китә цземә.
Балага да мәгълцм саташулар
Каян килә олы кешегә?

«Жиде цлчә, бер тапкыр кис», – диеп,
Дөрес әйткән зирәк бабалар.
Гай, бцгенге аң-акылым булса,
Азрак булыр иде хаталар.

Гәркем баса хәсрәт тырмасына,
Шул гадәтне буллмый бетереп.
Кылган хаталарны якасыннан
Их, аласы иде бөтереп!

Ләкин кеше цзе язмыш колы,
Хаталары тота якадан.
Дөнья булгач, төрле хәлләр була,
Кеше хали тцгел хатадан.

Февраль, 2016 ел.

Тормыш дәвам итсен!

Чәчәк аттың, әй ашкындың,
Гүлкәем – бәгырькәем.
Дөньябызны ямьгә төрдең,
Шатланды күңелкәем.

Сокланып карадым сиңа,
Афәрин. Рәхмәт диеп.
Тик чәчәкләр коелдылар
Шиңеп, башларын иеп.

Бу – яшәешнең кануны,
Ишекле-тирле ягы.
Гүзәлемнең бар, гөлләр кебек,
Балкып яшьнәгән чагы.

Мин дә, шул чәчәкләр сыман,
Гомер юлын үтәмен.
Дөнья белән саубуллашып,
Бәхилләшеп китәрмен.

Тормыш шулай яратылган –
Килгән – китәргә тиеш.
Оныкларым чәчәк атсын!
Шул булыр мөкатдәс эш.

Июнь, 2015 ел.



Рәис Сафин. Әнисе Хәбибҗамал, бабасы Галиулла, абыйсы Рәшит, сеңлесе Рәисә белән. 1944 ел.



Рәис Сафин. Әнисе Хәбибҗамал, хатыны Сания, уллары Расих һәм Ирек белән. 1978 ел.

Рәис Сафин хатыны Сания белән. 1963 ел.





Рәис Сафин хезмәттәше Хуҗин белән.



Шагыйрь Госман Садә, Рәис Сафин. 2005 ел.



Рәис Сафин рәссам Рушан Шәмсетдинов «Хәзинә» залында. 2009 ел.



Рәис Сафин хатыны Асия белән.



Рәис Сафин хатыны Асия уллары, оныклары белән.



Рәис Сафин улы Наил һәм Рәисә ханым белән.



Рәис Сафин бер төркем иҗат әһелләре белән.

II бүлек



Ләйлә көч-кодрәтенә
Шаккатып китәр исең.
О Кеше! Тиңсез Аллаһның
Могҗизасы син үзең.

Өч һәдия

(Тарихтан бер сәхифә)

Аллаһының рәхмәтләре яусын!
Өч сәхабә – дәрвиш өч кемсә,
Китергәннәр Болгар дәүләтенә
Символларда мөһим өч нәрсә:

Юл таягы – дәүләт таянычы, –
Ышанычы хәтәр чагында.
Күңелләрдә иман нуры балкыр,
Чалма торса өммәт сагында.

Дин-әхлаклы, кәлям, фикыһ фәнле -
Милләтебез дине саваплы.
Аллаһының кануннарын язган -
Татар Иле – кара савытлы.

Ата-баба ядкарь символларны,
Мирас иткән безгә соңыннан.
Газиз халкым изге әманәтне
Васыять итә буын-буыннан.

Июль, 2014 ел.

Ғаләмнәрнең бердәнбере

Торып-торып исем-акылым китәдер,
Тәре таккан саташып гомер итәдер.
Кемдер ясап куйган җансыз сурәт-рәсем...
Ғәм потларны ул Аллаһым дип йөртәдер.

Акыл заты булган кеше, күрә торып,
Үзен алдап көферлеккә башын ия.
Ике меңе ел нәсара дин әһелләре,
Ғайсә пәйгамбәрне безнең Аллаһ, дия.

Сын-гәүдәсе тора чиркәү, костелларда,
Сурәтенә багып халык дога кыла.
Өч затны* да Аллаһ сыйфатында күреп,
Ялган белән башкарыла дини йола.

«Аллаһны без уйлап табар идек» диеп,
Әйткән мәшһүр француз акыл иясе.
Уйлап тапкан адәм сурәтле «аллалар» -
Имештер лә, чиксез Ғаләмнәр иясе.

Тик Аллаһы охшамаган беркемгә дә,
Ул тумаган, беркемне дә тудырмаган.
Ләкин Ул бар: һәр тарафта, Ул һәр җирдә,
Ул – мәңгелек – әүвәл– ахыры булмаган.

Коръәнле һәр хак мөселман моны белә –
Аллаһыны күңел күзе белән күрә.

Адәменә илаһилык белән өргән,
Мәңге җанлы тәннәр генә гомер сөрә.

Тере Аллаһ иксез-чиксез Ғаләмнәрнең
Тиңе булмас хуҗасы һәм бердәнбере.
Җисемнәрнең хәрәкәтен барлап тора,
Дөньяларга яшәү бирә, булып тере.

Июнь, 2012 ел.

Аллаһының илаһияте

Кемнәр генә, нәрсә генә әйтсәләр дә,
Барлыгы һәм берлеге һәр нәрсәләрдә.

Көч-кодрәте дөньякуләм хәрәкәттә,
Хәрәкәттә булган барлык бәрәкәттә.

Тиңсезлеге иксез-чиксез Ғаләмнәрдә
Җан иясе кылган барлык гамәлләрдә.

Илаһилык – җисемнәрнең йөрешендә,
Мәхлукларның җирдә гомер сөрешендә.

Сер-хәзинә, аң-акылы җир-күкләрдә,
Яшәешне барлык иткән хикмәтләрдә.

Аның кылган гамәлләрен, һәрбер эшен,
*«Океаннарның суы җитмәс язар өчен».**

Ул җан өрә һәр цселлек, тереклеккә,
Куркәм нәсел калдырсынга киләчәккә.

Иген цсә, чәчәк ата, шыта цлән,
Гөл һәрберсе цзенә хас төсе белән.

Яшен яшьни Аның ут-ялкыны булып,
Бинһая Галәмнәрдә балкый тулып.

Белем-гыйлем, мәгърифәте чик-чамасыз,
Адәмгә Ул тормыш бирде шик-чарасыз.

Җир йөзендә яшәешне барлык итте,
«Гыйбадәт кылыгыз миңа», – диеп әйтте.

Хак мөселман ислamның биш баганасын
Фарыз итте. Ихлас белән кыла хаҗын.

Йөзләрендә Аллаһ нуры, иман нуры –
Инша Аллаһ, җәннәт юлы булыр туры!

И кардәшем, Аллаһыга гыйбадәт кыл,
Шәфкатенә рәхмәт әйтеп, канәгать бул!

---

* Коръән сүрәләреннән.

Август, 2014 ел.

Хисап бирәбез

Бу дөньяда кемнәр генә юктыр:
Яши булыр яхшы, яманы.
Аллаһының чиксез рәхмәтендә
Булып тора төрле заманы.

Яхшысы да, яманы да яши
Төрле юлда, төрле күңелдә.
Тик берәүләр яшәр Күк иленда,
Ә берәүләр каргыш телендә.

Без кешеләр – акыл заты булып,
Сынау өчен килгәнбез.
Кылынган һәр эш-гамәлләр өчен
Аллаһыга хисап бирәбез.

Дәһри бәндә бәлкем ышанмас та
Коръәндәге Аллаһ сүзенә.
Тик берәү дә, хәтта уй-фикер дә
Хуҗа түгел ләкин үзенә.

Башлар иеп, Аңа гамәл кылып,
Ләббәйкә ди Галәм дөньясы.
Җир-күкләрнең, барлык тереклекнең
Ул хуҗасы – тик бер Алласы.

Март, 2017 ел.

Мөнәҗәт

Әстәгъфируллаһ, әстәгъфируллаһ
Тәүбә вә әтүбү иләйһи.
Галәмнәрнең тиңсез син хуҗасы,
Син бердәнбер заттыр, Илаһи.

Өмет итеп Үзең ризалыгың,
Чын күңелдән, ихлас иманнан.
Фарыз булган гамәлләрен үти –
Гыйбадәттә мөэмин-мөселман.

Яшәешнең асыл мәгънәсе дә:
Аллаһыга тәкъва булудыр.
Аңа чиксез рәхмәтләрне әйтеп,
Биш вакытта намаз кылудыр.

Аллаһының кушканнарын үтә,
Дин-иманлы булсын дәвамчың.
Яшәешкә мәңгелек җан өргән
Затка булыр тулаем бурычың.

Апрель, 2017 ел.

* * *

Ирешдә Аллаһ рәхмәтенә
Асылында калсын вәҗданың.
Һәр эшеңдә, кылган гамәлеңдә
Сакта торсын намус мизаның.

Һәр гамәлең игелекле булсын,
Юньсез диеп халык әйтмәсен.
Мәгънәсез буш тормыш коруыңа
Үкенергә туры килмәсен!

Март, 2017 ел.

Аллаһыга сыгыныйк

Бербөтенне бүлгәләмик,
Хак Тәгалә – бердәнбер.
Җир йөзендә затлы кеше -
Вәкаләтле илчедер.

Аллаһ вәкил вазифасын
Аның аңына сала.
Идарә итүне инсан
Тәкъдире итеп ала.

Мәшһүр пәйгамбәрләренә
Изге китаплар иңә.
Илаһи Аллаһ сүзләре
Дәшә иманлы дингә.

Хак мөселман Аллаһының
Бар һәм берлеген таный.
Әманәтләрен үтәүне
Бурычы итеп саный.

Тик шаһәдәтсез бәндәләр
Фәнне тәүге димәкче.
Аллаһка кайтуны алар
Гаман инкяр итмәкче.

Бүлгәләнмик һәм бүлешмик,
Аллаһны танып белик.
Коръәнне хакыйкать итеп,
Ислам динендә гөрлик.

Сентябрь, 2013 ел.

Ике язмыш, ике юл

Хак Тәгалә адәм баласына
Камил акыл, ике юл биргән.
«Дөньялыкта үз иркеңдә яшә,
Асылыңда ләкин кал», – дигән.

«Уңга киткән – минем юлым булыр.
Рәхәтемнең хакын өзәрсең.
Күз күрмәгән, колак ишетмәгән
Оҗмах рәхәтләрен гизәрсең.

Уйлаганың – өстәлендә булыр,
Теләгәнең – килер каршыңа.
Гәммәсе дә тугел әҗәткәдер,
Гамәл-гыйбәдәт кыл тик миңа.

Сулга киткән – имансызлар юлы –
Иблислектә гөнаһ кылганнар.
Җирнең-Күкнең шәригатен бозган
Тәкәббер һәм дәһри булганнар.

Бу ишләр дә өлешләрен алыр –
Аруланыр тәмуг утында.
Бит алтын да затлы булыр өчен
Яну ала утлы ялкында.

Июнь, 2015 ел.

Бердәнбер

Шаккатамын күреп чәчәкләрнең
Аллы-гөлле сихри төсләрен.
Тылсымланып һуш-акылдан язам
Иснимен дә хушбуй исләрен.

Чәчәк тажы – могҗизалар язы,
Акыл җитми моны аңларга.
Яфракларның бизәкләре серен
Тик Аллаһтан мөмкин табарга.

Чәчәк тажы, яфрак... Чиксез Галәм, -
Тик Аллаһның акыл хикмәте.
Чәчәк тажы, яфрак, Галәмнәр дә
Акыл иясенең кодрәте.

Гәр үсемлек, һәрбер күзәнәккә
Хак Тәгалә яшәү иңдерә.
Тереклеккә сый-хөрмәтен биреп,
Яшәешкә нигъмәт күндерә.

Бу дөньяның барлык нигъмәтләре
Үсеп чыга адәм-балчыктан.
Кешенең дә яшәү мәңгелеге –
Җир һәм күкләр белән тоташкан.

Җир-күкләрне юктан бар итүче
Хак Тәгалә бар һәм бердәнбер.
Ул – мәңгелек нурлы балкыш булыр,
Акыл җитмәс гүзәл бөек сер.

Август, 2014 ел.

Фарыз булсын!

Коръәндә һәм хәдисләрдә,
Бер үк фикер, бер үк үйдыр:
«Бу дөньяда үзеңнән соң
Игелекле нәсел калдыр».

Итагатьле, гыйбадәтле
Булсын дәвам варисларың.
Гич исеннән чыгармасын
Иланы зат – Аллаһ барын!

Намус саклап, өмет аклап
Бу тормышны дәвам итсен.
Халыкларга үрнәк булып,
Милләтебез ерак китсен.

Шушы булыр бурыч үтәү –
Яшәештә гамәл җәпләү.
Гәркем хыялында йөрткән –
Гасырларга хәтер төпләү!

Август, 2015 ел.

Сөбхәналла

Табигатькә карап чиксез сокланабыз,
Могҗизалар күреп хәйраннар калабыз.
Искитәрлек гүзәл, үзе ямьле, ашы тәмле,
Игелекле, изге безнең җир-анабыз.

Җир-әнкәне ихлас сөеп, назга төреп,
Нурлы кояш, көмештәй ай балкып тора.
Галәмнәрнең акылына яшеренгән
Серле-сихри дөньялары шаккатыра.

Чал диңгезнең ялтыравык өсләрендә
Ай-кояшның ак нурлары җем-җем килә.
Дулкыннарның энҗе-мәрҗән очларында
Әйтерсең лә шаян нурлар уйный-көлә.

Дөньяларны дер селкетеп күкләр күкри,
Яшен угы ялт-йолт килеп ялкын бөркә.
Күкне япкан катлам-катлам болытларны
Сәйәр җилләр анда-монда себеркели.

Офыкларны-офыкларга тоташтырып,
Билбау аткан купшы салават күпере.
Буй-буй булып, гүзәлдән-гүзәл төсләргә
Әверелә бәллүр яңгыр бөртекләре.

Җир читендә көләч йөзле кояш ята,
Офыкларны нурга манып ал таң ата.
Галәмнәрдән шифа алып килгән нурлар
Болыннарны, урман-кырларны уята.

Төнге күктә йолдызларның балкышлары,
Ай-кояшның җиргә нурлар багышлавы...
Хатын-кызның елмаюлы карашында
Яшәешнең тантаналы алкышлавы.

Хатын-кыз да күкләр сыман илаһи зат
Күк күкрәтә, гөлләр кебек чәчәк ата.
Мәхәббәтне гомерлек юлдашы итеп,
Дөньяларда бу тормышны ул яңарта.

Ир кеше баш, хатын муен дисәләр дә,
Хатын-кызлар тәвәккәлли, ир булдыра.
Хатын-кызның мәхәббәтле күз карашы –
Ай-кояшны, йолдызларны таң калдыра.

...Җан-тәнемә ләззәт алып багам сезгә,
Әсир булам карап нурлы йөзегезгә.
Бу гүзәллек: зифа гәүдә, төс-кыяфәт...
Сөбхәналла, бик килешә үзегезгә.

Октябрь, 2014 ел.

Бер нәсихәт

Адәм – акыл белән яратылды,
Бар үз уе, бар үз фикере.
Акыллы зат булган адәмнәр дә
Аллаһының затлы фәкыйре.

Чөнки адәм – зәгыйфь җан иясе,
Тик акылы белән ул өстен.
Ләкин җирдә яшәүче мәхлуклар
Бер хокукта, алар – бербөтен.

Гәммәсе дә Аллаһыга мохтаж,
Рәхмәтенә Аның сыена.
Гәммәсе дә Аллаһ ярдәмнәрен
Тоеп яши гомер буена.

Адәм заты Аңа сәждә кыла,
Гөнаһларым диеп, ярлыка;
Җир-күкләргә яшәеш иңдергән
Аллаһ дигән тиңсез барлыкка.

Тик берәүләр акылыннан яза –
Тәкәбберлек ала өстенлек.
И кардәшем, бисмилланңы әйтеп,
Тәүбәгә кил, дөнья – өч көнлек.

Август, 2014 ел.

Җәза

Аллаһ Күкнең нурлы гарешеннән
Исе китеп Җирне күзәтә.
Татар иле ваем-мәшәкатьтә, –
Берәү – төзи, берәү – төзәтә.

Берәүләре, тырыш кырмыскадай,
Иртән торып эшкә керешкән.
Мөселманның биш фарызын үти,
Каллмас өчен бакый өлештән.

Әнә берәү, юха елан сыман.
Бөтерелә тирә алдында.
Ләббәйкә дип, табан асты ялый,
Эш-гамәле «шеф»ның җаенда.

Улы – кияү, кызы – килен булып,
Чит – ят белән никах бәйлешә.
Милләтенең нәсел орлыкларын
Тәре такканнарга өләшә.

Ә берәүләр сугыш – үтерештә
Урлап, талап хәрам мал җыя.
Үзе туйса, комсыз күзе туймый,
Бәндәләрне суя, җан кыя.

Чиркәүләрдә сынга табыналар,
Мәчетләрдә – табыш бәйлешү.
Гәр тарафта – зина-фәхишәлек,
Монафыйклы тормыш сөрешү.

Аллаһының тәзеллеге бетте:
Ут-яшенле давыл, җил купты.
Денсезләрне мал-мөлкәте белән
Цунамилы диңгез, Җир йотты.

Май, 2014 ел.

Сур мөгезе әле...

Җәйләрдән соң чуар көзләр килә,
Бәгырьләрне телә моңсулык.
Иртән ап-ак, кырпак кар тұшәлә...
Гомер ишек шакый моң булып.

Көзләр булып мыштым картлык килде,
Елларым да йөзгә сарылган.
Яшьлек узган... Гомер арбасының
Тәртәләре көзгә борылган.

Сур мөгезе әле уйнамаган,
Балкып торсын күкнең кояшы.
Изге гамәл кылган бәндәләрнең
Хозыр Ильяс булыр юлдашы.

Декабрь, 2013 ел.

Тарихтан бер сәхифә

Аны денсез Намруд* патша
Ут-ялкынга ташлаткан.
«Лә иләһә иллəл-лаһ» – дип,
Уттан ул янмый чыккан.

Потларга табынган халык
Аптырап хәйран кала.

«Аллаһ бар, Ул бердәнбер», дип,
Дөрес әйтәме бала?

«Нинди кодрәт Ибраһимны
Ялкыннан йолып алды?
Давылланып янган утта
Ул ничек исән калды?

Табынган потларыбыз да
Янмый калаллмас иде.
Кояш үзе дә бу уттан
Исән чыгаллмас иде».

Шулай уйлый җыен халкы
Шиксез могҗиза күреп.
«Утта янмаган Ибраһим
Әйтә булыр бик белеп».

«Ул – сихерче», – ди берәүләр, –
Яндыру кирәк аны.
Бабалар изге санаган
Мәсхәрәли потларны».

Халык төркемгә бүленде,
Күрде ялганны, хакны.
Әмма Намруд: «Дәһшәтле итеп,
ягыйк, – диде, – учакны».

Халык Ибраһимны яклап,
Кат-кат ураты алды.

Ибраһим галәйһиссаләмнең
Яныңда алар калды.

Аллаһ Ибраһим халкына
Салды рәхмәт-шәфкатен.
Мөэмин-мөселманга бирде
Мөбарәк бәрәкәтен.

**Намруд – мөшрик кавем патшасы.*

Гыйнвар, 2016 ел.

Могҗизалы терелү

(Риваять)

Зиннәтле вә затлы сараенда
Бер аксөяк ята – сырхаулы.
Йөзе кипкән, күздән нуры киткән,
Көннәре дә, бәлки, санаулы.

Заманында ут уйнаткан куллар
Аркан сыман аска салынган.
Җир җимертеп йөргән аякларга
Әйтерсең лә герләр тагылган.

Ярсу елга кебек йөрәкнең дә
Дәрте сүнгән, дәрмән туңелгән.
Ташып торган ирлек, сәламәтлек
Гомер юлларына сибелгән.

Калтырана мескен галиҗанәп,
Бәрелешә чек-чек тешкә теш.
Сихәт бирми тәнгә илдән җыйган
Мал-мөлкәтләр, алтын вә көмеш.

Әйтерсең лә, табибләрнең кемдер
Буып куйган белем чишмәсен.
Галиҗанәп сырхавының серен
Гичкем белми ничек чишәсен.

Кояш чыга, ай да көн дә калка –
Вакыт сүтә гомер йомгагын.
Аллаһ белә Әюп пәйгамбәрнең
Елый-елый тәүбә кылганын.

«Йа Аллаһым, – ди пәйгамбәр үксеп, -
Гөнаһларым минем ярлыка.
Шайтан вәсвәсәсенә бирелеп,
Табынганмын черер байлыкка.

Ибраһим күк хак мөселман булып,
Яшәремә Сиңа сүз бирәм.
Барлыгыңны, берлегеңне танып,
Хак динеңә иман китерәм.

Намрудныдай мине һәлак итмә,
Кавемемне итмә мәсхәрә.
«Лә иләһә илләл-лаһу» безгә
Гомер – бакый булыр гыйбарә.

Коткар мине котсыз бу сырхаудан
Катылыкта тотма бу хәтле.
Ҫаләмнәрнең тиңсез хуҗасы син,
Акыл иясе дә хикмәтле.

Син рәхмәтле, рәхим вә шәфкатьле,
Син кодрәтле Илаһ бердәнбер.
Терелт мине махау сырхавыннан –*
Тәмуг газабыдыр бу җәбер».

Шулчак Аллаһ Җәбраиле аша
Сүзен әйтеп, фәрман иңдерде.
«Фәлән җирдә фәлән үлән үсә,
Дәва булыр аңа шул», – диде.

Янә әйтте: «Ҫаскан җиргә типсен,
Ике төрле чыгар су гөрләп.
Кайнарыннан алыр шифа-сихәт,
Салкынында табар көч-куәт».

Әл-Җәбраил таш сарайга килде,
Сырхау Әюп яткан ятакка.
Сүнеп барган шәм-гәүдәне күрде,
Уйга калды тынып озакка.

Ҫәм Җәбраил Аллаһыга әйтте:
«Тапшырыйкмы әллә тарихка?»
Диде Аллаһ: «Син савыктыр аны.
Миннән сезгә хәер-фатиха».

Шулай диде Аллаһ, әмер бирде,
Пәйгамбәргә гомер теләде.
Кавемен дә, әйкә халкын кебек,
Гөнаһлак иттерәсе киллмәде.

Дверелеп кеше сурәтенә,
Әл-Җәбраил эшкә керешә.
«Агачтан – ди, – күркәм йорт салыгыз,
Мунчасы да булсын янәшә.

Намаз укып, изге теләк теләп,
Тәкбир әйтеп торсын кавеме.
Гөнаһ-хаталарын ярлыкауны
Аллаһыдан сорап һәркеме».

Күперделәр сырхау пәйгамбәрне,
Хуш ис аңкып торган йортына.
Күзен ачты, йөзе нурлар чәчте,
Иман нуры иңде җанына.

Таулардан ул яшь үлән чаптырды,
Кызу итеп мунча яктырды.
Яраннары шул мунчада юып,
Үләннәргә төреп яткырды.

Аллаһ әйткән үлән төнәтмәсе
Шифа булды сырхау тәненә.
Коенды ул госел, һәр биш вакыт
Намаз укый-укый көненә.

Пәйгамбәрнең изге догалары
Аллаһ тарафына иреште.
Илчесенең тәүбә-истигъфарын
Ожмах белән тәмуг бүлеште.

Әюп тәнен каплап алган чирне
Хак Тәгалә артка чигерде.
Башкаларга гыйбрәт булсын өчен
Икеләтә бала, мал бирде.

Хак Тәгалә тугры булганнарга
Миһербанлы, юмарт, рәхмәтле.
Сын-потларга табынучы адәм -
Мәңгелеккә булыр ләгънәтле.

Тәүбә итмәс мөшрик бәндәләрнең
Киләсе бар Аллаһ каршына.
Сәмуд кавме кебек кяферләрнең
Тәкәбберлек җитте башына.

Дәһриләрнең һәрчак баш очында
Булып торыр Аллаһ каһәре.
Җәзасыннан кемдер котылса да,
Газап чигәр нәсел-нәсәбе.

Июль, 2013 ел.

Пәйгамбәрне яд итү

Кешелекнең соңгы пәйгамбәре –
Хак Мөхәммәд Галәйһиссәлам.
Ислам динен безгә ирештергән
Ул – беренче мөэмин-мөселман.

Дин –иманын үз йөрәге аша,
Инануы аша кичерде.
Аллаһының изге ислам динен
Дөнья өммәтенә күчерде.

Аңа Җәбраил фәрештә аша
Изге Коръән иңде Аллаһтан.
Белем, гыйлем, дини тәгълиматны,
Мәгълүматны алды догматтан.

Аллаһының бар һәм бирлеген ул
Күңеленә салды өммәтнең.
Кыямәттә янә тереләсен,
Булачагын тәмуг, җәннәтнең.

«Исламның биш баганасын үтәү –
Фарыз, – диде мөэмин бәндәгә. -
Намаз уку, рузә тоту, зәкят бирү –
Бурыч үтәү булсын һәркемгә!»

Шулай диде тиңсез Аллаһының
Пәйгамбәре, колы, илчесе.

Дине өчен мең газаплар чиккән
Ике дөньяның да кешесе!

Ятим калган Ғабдулланың улын
Рәсүлүллаһ итте Аллаһы.
Миллиардлаган мөэмин-мөселманда
Аллаһ нуры вә Аллаһ рухы!

Ғыйнвар, 2016 ел.

О син, кеше!

О син, кеше! Үтә гаҗәп заттыр,
Күркәм сыйфатларны җыйгансың.
Мәңгелектә истә калыр итеп,
Син үзеңә һәйкәл коясың.

Бу дөньяда сиңа тиңдәшләр юк.
Син бердәнбер акыл иясе.
Җир-әнкәдә гыйбадәтле булыр
Аллаһының асыл нөсхәсе.

Әдәп-әхлак, тәртип кәлимәсе
Язмышыңа анык язылган
Ғамәлләрең ихлас булсын өчен
Сиңа белем, гыйлем хас булган.

Хак Тәгалә һәр кавемгә атап,
Үз холкына ярак тел биргән.

Уй-хисләрен яңгыратыр өчен,
Күңелләрдә сихри моң үргән.

Беркемдә юк синдәгедәй серле
Күз карашы, көлү-еллаю.
Болар бар да Аллаһ нигъмәтләре:
Бәхет-хәсрәт, шатлык-моңаю.

Хак Тәгалә сине төгәл, камил...
Могҗизаи итеп яраткан.
Уй-фикерле, хикмәти затына
Муллык биргән азык-ризыктан.

Тик шулай да, син тәкәббер затсың,
Масаясың, борның чөясең.
Инкяр итеп Аллаһ кушканнарын
Җан-тәнеңә гөнаһ өясең.

Син үзеңне мәңге яшәр кебек,
Кодрәт ияседәй тоясың.
Үзең ише адәмнәрне талап,
Үлә-бетә байлык җыясың.

Саташкан бер залим аркасында
Миллионлаган җаннар кыела.
Нәфесләре туймас ач күзләрдә
Бинһая байлык җыела.

Бар да кала. Череп юкка чыга
Хуҗалары – Аллаһ каршында.

Һәр мыскалы өчен җавап тоту
Кирәк булыр тәмуг утында.

О син, кеше! Акыл-аң иясе,
Бөрәкләреңә синең – асыл зат..
Бөрәкләреңә – байлык колы булган,
Кеше төсен җуйган кабахәт.

Шул денсезләр яралганнан бирле,
Риза булмый Аллаһ ашына...
Кан-яшь коя, хәрам мөлкәт җыя,
Кешелекнең җитәр башына.

Июль, 2015 ел.

Элгәреләр һәм бүгенгеләр

Адәм заты алгарышка дип ашкына,
Белмәк була Галәмнәрнең яшеренен.
Якынайган саен сергә – ул кыскарта
Кешелекнең бу дөньяда яшәр көнен.

Изге Коръән китабында Аллаһ әйтә:
«Элгәреләр сездән зирәк булдылар», дип.
Аллаһ гыйлем, белеменә якын килгән
Кавемнәрне һәлак итеп бетерде бит.

Июль, 2013 ел.

Чигеле дөнья

Хак Тәгалә бу дөньяны
Сөю белән сугарган.
Гашыйкларның якты нуры
Төшкән, димәк, югардан.

Яшәеш белән мәхәббәт -
Әйтерсең бер иҗектән.
Арба да ялгыз кузгалмас,
Аты булмаса җиккән.

Җирдә хәят булсын өчен
Кирәк кояш җылысы;
Мәхәббәт назлы булсынга -
Уй-хисләрнең чынысы.

Гәр нәрсәнең, һәркемнең дә
Пары бар бу тормышта.
Җир-күкләр дә бер-берсенә
Багланышлы булмышта.

Хак Тәгалә бу дөньяны
Мәхәббәт белән чиккән.
Менә шушы тибрәнештә
Яшәп ятабыз икән.

Август, 2013 ел.

Күк җәзасы

Коръән әйтә: «Элгәреләр
Акыллырак иде» – дип.
Чал мәһабәт һәйкәлләре
Торалар борын чөеп.

Серле Киек каз юлыннан
Әкәмәт затлар килгән.
Җир кешеләре аларны
Аллалар диеп белгән.

Сыннары чиркәү, йортларда
Тора шул «Алла»ларның.
Кяфер, нәсара табына -
Чынын белми Алланың.

Аллаһ – пот та, сын да түгел,
Дивардагы рәсем дә.
Тумаган, тудырмаган да
Түгелдер Ул җисем дә.

Үзен инкяр иткәннәргә
Аллаһ хөкеме катгый:
Су баса, давыл котыра -
Дөньяны һәлак айкый...

Октябрь, 2013 ел.

Бер кебек

Икесе дә алар илаһидыр,
Икесе дә тормыш куәсе.
Икенә дә бердәй табынабыз –
Алар безнең тормыш иясе.

Икесе дә алар көч-куәтле,
Дөньяларны юктан бар итә.
Җир-күкләрдә тормыш-яшәешне,
Кануннары белән беркетә.

Бар тереклек яши парлы-парлы,
Парлылыкта сере яшәүнең.
Тик һәркемнең тәкъдир-бизмәне бар,
Бер чиге бар ләкин үлчәүнең.

Тик Аллаһның башы-ахыры юк,
Мәхәббәт тә шулай мәңгелек.
Икенең дә бер үк сыйфатлары –
Икесе дә алар бер кебек.

Февраль, 2013 ел.

Никах

Туган-тумача җыелды
Никах мәҗлесенә.
Никахлашып яшәү фарыз,
Мөселман кешесенә.

Хәзрәт аятьләр укыды
Хатыннар сүрәсеннән.
Егет-кызны вәгазь кылды
Нәсыйхәт җөмләсеннән.

Аллаһының изге сүзе
Ошбу аятьтә иңгән.
«Ирле-хатынлы булырга
Яралттым сезне», дигән.

Иланы мәхәббәт хисе
Җан иясенә – терәк.
Бер-берсенә тугрылыклы
Булсын никахлы йөрәк.

Оят-намус гомер буе
Күңел сагында торсын.
Изге эш-гамәлләрегез
Айлы-кояшлы булсын!

Июнь, 2014 ел.

Камиллек

Сүзләренең хаклыгына раслык итеп:
«Иманым камил», ди берәү, күкрәк кагып.
Шул берәүләр белер-белмәс акыл сата, -
Үй-фикерен башкаларга димләп-тагып.

Адәмнәрнең, гамәлләрнең камиллеге
Белем аша, бәхәс аша безгә килә.
Тик дөньяда иманыңның ниндилеген
Бер Илаһи Хак Тәгалә генә белә.

Декабрь, 2011 ел.

Иншаллаһ

«Югалтканнарны табарсыз, –
Дия – Аллаһ Исламнан».
Чукындырылган татарлар
Аерылды иманнан.

Йөз миллион татар югалды, -
Әверелде кяфергә.
Чукынмый калганнары да
Кяферләр белән бергә.

Хәрәм ашый, хәрәм эчә,
Манкорт балалар үсә.
Милли асылын югалткан
Татар тамырын кисә.

Теленә богау салдылар
Мәктәпләрен дә ябып.
Балыкка әйләнде халык, –
Илсез, телсез дә калып.

«Югалтканнарны Исламнан
Табарсыз», дия Аллаһ.
Мәчет-мәдрәсәләр барда,
Югалмабыз, иншаллаһ.

Ноябрь, 2011 ел.

Бердән-бер юл

Аллаһ әйтә: «Югалтканны
Исламнан, – ди, – табарсыз».
Йөз миллион татар кырылды,
Каян аллаш табарбыз?

Ханлыгын җуйган татарның
Милли кояшы бата.
Ил-җиребез илбасарның
Табан астында ята.

Ятим калган халык үзгә,
Сатлык түрәләр үзгә.
Дәүләтебезне торгызыйк
Берләшеп динебезгә.

Октябрь, 2011 ел.

Әгәр...

Кешеләрдә нәфес дигән хаҗәт бетсә,
Туктап калыр иде безнең җирдә яшәү.
Чәчмәс иде, иген икмәс иде кеше,
Булмас иде ясау, төзелештә эшләү.

Бәлкем әле балалар да тумас иде,
Кайгысы да, хәсрәте дә булмас иде.
Бәхет-шатлык, көлү-елмаюларны да...
Сөю дигән ләззәтне дә белмәс иде.

Яшәр иде хайван сыман ашап-эчеп,
Хис-тойгысыз, мәхәббәтсез гомер кичеп.
Битарафлык, ваемсызлык кочагында,
Хәерчелек, бөлгенлек хәленә төшеп.

Нәфес юкта – әхлак та юк, әдәп тә юк,
Тәртип-тәрбия дигәннең – кирәге юк.
Әс-башларың алама, тәнең дә шакшы,
Аяк асты ризыгыннан тамагың тук.

Шуңа Аллах Адәменә нәфес биргән,
Бу хаҗәтне тик чамалап тот син, дигән.
Булганына шөкер итеп яшәгәннәр,
Аллаһының ике дөнья ямен күргән.

Алгарыш та, яңарыш та – нәфес эше,
Көч-куәте дөнья шарын тәгәрәтә.
Көнчелек, нәфес, хөсетлек тә булмаса...
Яшәп калыр иде кеше мәгарәдә.

Август, 2011 ел.

Мәңгелек көрәш

Безнең тормыш – көрәш, ызгыш, талаш,
Миллионлаган корбан сугышта.
Тереклекнең яшәү кагыйдәсе -
Бер-беренә азык булмышта.

Иблис-мәлгунь яман кешеләрне
Вәсвәсәли, канын котырта.
Кешелекне нәфес колы итеп,
Үз канына үзен утырта.

Ләкин кеше дигән җан иясе
Хаталарны тора кабатлап.
Алгарышлы яңа буыннарга
Үткәннәрне буллый яраклап.

Хикмәтле акыл иясе – кеше,
Галәмнәргә бага карашын.
Көнчелеге, нәфес, хөсетлеге...
Күзәтәдер зиһен ярышын.

Фани дөнья үтә каршылыклы -
Берәүләрнең Иблис ияптәше.
Тормыш үзе – яхшы белән яман,
Үлем белән яшәү көрәше.

Акыллы зат үз нәфесе белән,
Аллаһ Иблис белән көрәшә.
Җан-каныннан иблис рухын куып,
Шәхеслеккә кеше ирешә.

Август, 2011 ел.

Канун булсын!

«Сырхау кеше ураза тотмасын»,
Пәйгамбәрдән килә бу хәбәр.
Адәменә мәрхәмәтле булган, -
Аллаһка дан, Аллаһу әкбәр.

Уразада ашау-эчү... Хәтта,
Ярамыйдыр дару кабу да.
Татарны да берләштерү өчен
Кирәк рухи-милли кагыйдә.
Канун булсын дини кагыйдә!

Август, 2011 ел.

Барысы да Аллаһ кодрәтендә

Барысы да Аллаһ кодрәтендә, -
Ул хуҗасы чиксез Галәмнең.
Ләүхелмәхфүз тактасында булыр,
Язмышлары һәрбер адәмнең.

Татарның да тәкъдир-язмышында
Язылгандыр ниләр күрәсе.
Мәсхәрәгә калып, чит дәүләткә
Чәчмиз халык булып керәсе.

Мәшһүр Бәһадурны, Атиланы
Терелтәсе иде бер көнгә.

Карасыннар иде илен саткан,
Урыс телле татар мескенгә.

Гәм кырсеннәр иде умырылган,
Уч төбедәй татар ил-җирен.
Парә-парә килеп телгәләнгән
Чын татарның канлы бәгырен.

Татар данын Гарешләргә чөйгән
Кәһарманнар калыр шаккатып.
Бинисһая татар дәүләтләрен
Бетерде соң кемнәр таркатып?

Барысы да Аллаһ кодрәтендә,
Безнең тормыш – Аның карары.
Мәңгелектә калыр кавемнәрен
Тәкъвалыкта сынап каравы.

Аллаһ безгә хәер-фатихасын,
Иман нурын биргән яшәргә.
Үткәннәрдән кирәк гыйбрәт алып,
Гөнаһлардан тәүбә итәргә.

Май, 2016 ел.

Адәм

Иллә көләч, елмаюлы,
Якты-нурлы адәм йөзе.
Аллаһтан соң уйлы-хисле...
Акыл заты да ул үзе.

Адәм заты – илаһи зат,
Аллаһ аңарга җан өрде.
Җан белән бергә мул итеп,
Үз сыйфатларын да бирде.

Шуңа Адәм мәңге серле,
Мәшһүр галим, ул – төзүче.
Ул – акыл, фикер иясе...
Булмаганны бар итүче.

Адәм – балчык кына түгел,
Рухында Аллаһ көче бар.
Тик ул – табыныр зат түгел, -
Табынырга бер Аллаһ бар.

Адәм – Җирнең халифәсе, -
Ләкин Аллаһның бәндәсе.
Халифә булган бу затның
Бар әле беркөн үләсе.

Җир астына бар керәсе,
Аллаһка җавап бирәсе.

Нинди гамәл кылганлыгын
Мизанда күреп беләсе.

Җирне-күкне онытканны,
Аллаһның каһәре ора.
Акыл заты булган Адәм
Хата-гөнаһ кыла тора.

Күкрәк сугып, мин кем диеп,
Йөри җирдә балчык-адәм.
Җир-ананы йолкый-талый,
Чыгырдан чыкты ул тәмам.

Ул – нәфесле, ул – тәкәббер...
Аңа булсын бөтен әйбер.
Байлыгы баштан ашса да,
Нәфесе туймый барыбер.

Тау-ташларны актара ул,
Өстен астына китерә.
Җир өсте үсемлекләрен
Корыта, кырып бетерә.

Җир йөзендә яшәешне
Мәхшәр хәленә җиткерә.
Үз-үзенә тәмуг ясап,
Дөньялыкта газап күрә.

Җелеген, канын суырып,
Тереклекне җансыз итә.

Икейөзле бу тәкәббер
Үз башына үзе җитә.

Кайбер тәкәббер Адәмнәр
Үз-үзләрен «Аллаһ» итте.
Потка, сурәткә табынган
Адәм кяфер булып китте.

«Эт симерсә иясен дә,
Танымый башлар», ди, халык.
Халифә булган Адәм дә,
Яшәр эт көнендә калып.

Июль, 2011 ел.

Әйләнештә...

Сулар ага, җилләр исә, чорлар үтә,
Бу дөньяда бар нәрсә дә әйләнештә.
Еллар буе җир әйләнә Кояш тирә,
Әйләнә ул тәүлек буе күчәрендә.

Йолдызлар да һәрвакытта хәрәкәттә,
Хәрәкәттә булган гына бәрәкәттә.
Буыннарны яңа буын алыштыра,
Үткән белән бүгенгене кавыштыра.

Кеше туа, җир-бишектә гомер итә,
Бәхилләшеп китәр чак та килеп җитә.

Ахирәттә аны кемнәр, ниләр көтә?
Шушы сорау аны гомер буе өтә.

Нигә китә? Китә микән ул озакка?
Нинди тәкъдир әзерләнгән асыл затка?
Нигә кеше әҗәл белән бәйләнештә?
Ә бит сулар, җилләр һаман әйләнештә.

Җилләр исә, сулар ага, чорлар үтә,
Мәңгелек җан безне ташлап кая китә?
Әллә инде берәүләрнең яралгысы
Әнисенең карынында хәят көтә?..

Сулар, җилләр чорлар кебек әйләнештә,
Кешеләр дә яши булыр бәйләнештә.
...Иртән нурлы кояш чыгар, кич ай калкыр,
Кояш белән Ай бар чакта дөнья балкыр!

Июль, 2015 ел.

Хисап

Кеше – табигатьнең таҗы,
Акыл-фикер иясе.
Гамәлләре өчен аңа
Булыр хисап бирәсе.

Аллаһының кушканнарын
Үтәдеме хак диеп?

Яшәдеме тереклекне
Үзен шикелле сөеп?

Нинди изге гамәл кылды
Хак Ислам динен саклап?
Бәлагә дучар бәндәнең
Калдымы берсен яклап?

Канга – кан, үлемгә – үлем –
Гаепсез җаннар кыю.
Дөнья балкып торсын, дисәк –
Кирәк нәфесне тыю.

Май, 2014 ел.

Көрше хакы – Аллаһ хакы, диеп...

Һәр тарафтан чиркәү аваз сала –
Кыңгырау-чаң кага җилкенеп.
Ханнар аңа ризалыгын биргән,
Толерантлык җаен китереп.

Көрше хакы – Аллаһ хакы, диеп,
Татар күркәм эшләр майтара.
«Бусы минем хакым» дип күршесе
Золым кылып, әҗәт кайтара.

Юмарт татар илсез-йортсыз калды,
Җире дә юк мәчет салырлык.

Үз хакын да инде күршесеннән
Куәте юк кире алырлык.

Гаепсездән һаман ул гаепле
Зинданнарда татар милләте.
Эзәрлекләү, кыйнау, җәзалаудан
Иза чигә Ислам өммәте.

Таш атканга – аш атучы татар
Гыйбрәт алмый ачы ялгыштан.
Үлә-бетә күрше хакын хаклый,
Үзмышлар юк, имеш, язмыштан.

Хак Тәгалә шулай куша, диеп,
Күршесенең күрә күңелен.
Тамырына балта чаба-чаба
Һәлакәткә илтә килерен.

Эт, мәче дә бергә дус яшәми,
Толерантлык булмас берьяклы.
И татарым, бул Аллаһка хаклы,
Милли рухлы, милли сабаклы.

Май, 2013 ел.

Денсезлек

Тигез хокук талэп иткэн мөселманга
Вahһабчы дип, нахак бэла, яла якты.
Иманы хак кардэшлэргэ пычрак атты,
Шул монафикъ аркасында каннар акты.

Хуҗалары бу денсезне мактадылар,
Каһарман дип, тҗшенэ орден тактылар.
Каберлэрдэ каргыш, бэддогалар юллап,
Мэрхүмнэр дэ кыйблага карап яттылар.

Җир-анабыз тетрэнде бу яман эштэн,
Аллаһыдан вэхи иңде күк-гарештэн:
«Дэһриләргэ җэзам чиксез каты булыр,
Сакланыгыз ялган сүздэн, көферлектэн.

Ярлыкаусыз гөнаһ гамэл-хыянэттер,
Ияләре Иблис белэн янар утта.
Сатлык җаннар – тэмуг кисэүлэре булыр,
Котылалмас тэүбэ-истигъфар кылып та.

Сентябрь, 2012 ел.

Әйләнеш

Җирләр-күкләр бертуктаусыз әйләнештә,
Әйләнешле көрәш бара яшәештә.
Бүген җиңгән җан иясе – иртәгесен
Үзе корбан башкаларга җиңелештә.

Туу, яшәү, тормыш кору, гамәл кылу –
Барысы да вакытлыча бу дөньяда.
Хикмәт шунда: акыл заты булып җирдә
Яшәүеңдә тереклеккә бармы файда?

Аллаһының дин-иманлы бәндәләре
Яшәештә бәрәкәтле тормыш кора.
Әдәп-әхлак белән гомер итүеңне
Баш очында фәрештәләр санап тора.

Дөньяда бар рәхимсезе, кабахәте
Кеше рәвешендә булган хәшәрәтләр.
Байлык колы булып йөргән шул явызлар -
Тереклеккә китерәдер һәлакәтләр.

Җан иясе сан-сыйфатта җирдә яши –
Үз-үзенең холкына хас эшен эшли.
Керә алар төрле-төрле кыяфәткә,
Кем ожмахка, кем үрмәли кыямәткә.

Май, 2012 ел.

Кәһәрле кавем

Һәр кавемдә яхшысы бар, яманы бар,
Бар имансыз монафикъ һәм кяфер кавем.
Аллаһның хак ислам динен инкарь иткәч, -
Киллмешәккә калды алар, җуеп илен.

Тәкәббер һәм денсез булган бу кавемгә
Бер-бер артлы пәйгамбәрләр җибәрелде.
Гайсә пәйгамбәр тәрегә кадаклангач,
Залимнәрнең тәхете дә җимерелде.

Җир йөзенә таралышкан шушы кавем
Дәүләтләрне бер-берсенә каршы куя.
Дөньядагы халыкларның канын коя,
Ил-җирләрнең байлыкларын җыя-җыя.

Кан-яшь сеңгән, хәрам кергән мал-мөлкәтнең
Игелеген күргәне юк һичбер кавем.
Иблис белән алар Аллаһ кәһәрендә...
Адәмнәргә мәхшәр ясап яши бүген.

Декабрь, 2011 ел.

Бертуганнар

Сихри-серле, балкып торган нурлы
Күк йөзе дә, кеше йөзе дә.
Күктә – кояш, ай, йолдызлар нуры,
Иман нуры кеше йөзендә.

Күк йөзе дә безнең йөзгә охшаш:
Күзләре бар, кашы, керфеге.
Ястыксыман сәйяр болытлары,
Миң бөртеге, сипкел бөртеге...

Әйтерсең лә алар игезәкләр -
Күк йөзе дә, кеше йөзе дә.
Тик илаһи рухи сыйфатларны
Күктән ала кеше үзенә.

Күкләрнең дә төрле чагы була -
Таплар бар иң кояш, айда да.
Кешеләр дә гөнаһ кыллмый гына,
Яши аллмый фани дөньяда.

Яхшы-яман безне сынап тора,
Шулай язган тәкъдир-язмышта.
Күк йөзедәй кеше үзгәрүән,
Аллмашынып тора тормыш та.

Балкып кояш чыкса, ай калыкса,
Дөньяларга нурлар сибелә.
Ай-кояшлы йөзләр еллмайганда
Шиңеп калган гөлләр терелә.

Табигать тә, кешеләр дә җанлы,
Бер үк безнең фигыль-холыклар.
Табигать һәм кеше – бертуганнар,
Бер Кодрәттән безнең барлыклар.

Ноябрь, 2011 ел.

Иблискә ияреп

Иблис мәлгунь ут-ялкыннан яралтылган,
Көч-куәтне, сәләтне дә уттан алган.
Бу горур зат адәмнәргә баш имичә,
Аллаһының җәннәтеннән мәхрүм калган.

Хак Тәгалә тәкәббер бу фәрештәне,
Мәңгелеккә утлы җәһәннәмгә сөргән.
Сүз-фәрманын үтәмәүче шул Иблискә
Адәмнәрне аздырырга ирек биргән.

Кыямәткә кадәр Иблис җирдә яшәр,
Имансызны ул үзенә юлдаш итәр.
Юл яздырыр, вәсвәсәләп азындырыр,
Кыйбласызлар аның ише булып китәр.

Залимнәрнең уйларына коткы салыр,
Көнчел фикер, үч уятып, хәйлә корыр.
Күз буудан аңын җуйган мөшрикләргә,
Утлы тәмуг җәннәт шикелле тоелыр.

Хәләл гамәл хәрам эш белән буталыр,
Адәм заты нәфес колы булып калыр.
Оят-намус, әдәп-әхлак, тәртип дигән,
Күркәм, асыл сыйфатлары да югалыр.

Изге Коръән, Аллаһының кануннарын
Бозып сөйләр динсез мулла, денсез ишан.

Мәэминнәрне бер-берсенә каршы куяр,
Кыяфәте кеше сыман Иблис-шайтан.

Бу дөньяда тереклекнең яшәеше, -
Ут-ялкынның кем кулында булуында.
Шул адәмнәр иблис яманлыгын уза,-
Тиңнәре юк явызлыклар кылуында.

Июль, 2011 ел.

Адашу

«Динне кыенлаштырмагыз,
Бу – Аллаһы кануны.
Коръәндә ничек язылса,
Шулай үтәгез аны».

Шулай дия дин әһеле,
Хәзрәтләр – вәгазьләрдә.
Шулай диелгән хакыйкый
Китаплы кәгазьләрдә.

Тик берәүләр үтә динле
Булыргамы тырышып,
Хак дингә мөгез чыгара
Наданлыкта карышып.

Әллә ниләр уйлап таба
Газапка тара үзен.

Сөйли тузга язмаганны
Белмичә дин нигезен.

Кайсы – еландай шуыша
Сәждәдә булган чакта.
Берәве тәнен камчылый
Тәнен охшатып атка.

Шулай иткәндә, имештер,
Савабы була мулдан.
Тик бу үз-үзеңне алдау –
Дингә тагылма ялган.

Бу тамаша – каш ясыйм, дип,
Күз чыгарып маташу.
Шайтан юлында саташып,
Вәсвәсәдә адашу.

Август, 2015 ел.

Әҗәлгә бер сүз

Ничә тапкыр инде очрашсак та,
Үзара без таныш булсак та...
Син эшеңне төгәл башкарачак,
Гомер ахры җиткән берчакта.

Дөнья шулай итеп яратылган,
Гәрбер килгән тиеш китәргә.

Фанилыкта яшәү мизгелләрен
Аллаһ кушканынча үтәргә.

Исән чакта кылган гамәлләрең
Лаек булсын данлы мактауга.
Гасырларны кичәр игелекнең
Бәрәкәтен күреп саклауга.

Яхшылык та, явызлык та бергә –
Янәшәдә бара тормышта.
Икесе дә һәр җан иясенең
Тормыш иярчене буллмышта.

Җир-әнкәгә вәкил булып килгән
Кешеләргә акыл бирелгән
Вәсвәсәдә гөнаһ кылганнарга
Җәза каты булыр, диелгән.

Ике юлны сайлау хак-хокукын
Хак Тәгалә затка юнәлтә.
Бирәү хәләл, бирәү хәрам белән
Яшәештә булып көн итә.

Гомер үтә. Әҗәл килеп җитә,
Башкарырга теләп үз эшен.
Адәм заты диеп аталганның
Туктатырга йөрәк тибешен.

Әйе. Әҗәл иң куркыныч кодрәт,
Гәркемгә ул беркөн киләчәк.

Һәркем кылган эш-гамәле өчен
Аллаһыга җавап бирәчәк.

Гамәленә күрә сые булыр –
Тик буллмасын ул сый аяныч.
Сәҗдә китеп, гыйбадәтләр кылам,
Җәннәтеңдә, Аллаһ, бир тормыш.

Сентябрь, 2015 ел.

Кар сулары

Бөялеп торган кар суын
Кемдер ерып җибәрде.
Ургылып агып китте су -
Гөрләвекләр йөгерде.

Мыштым гына акты сулар
Өстен боз капласа да.
Ермак булып эзе калды
Бөтенләй туктаса да.

Кеше гомере дә шулай:
Ташкындай агып китә.
Тәкъдиренә язылганны
Кар суы сыман үтә.

Барысы Аллаһ кулында,
Барысын Ул хәл итә.
Берәүләрне җир-су итә,
Берәүләрне кар итә.

Сентябрь, 2015 ел.

Яшәү катламнары

Табигатьтә бар да катлам,
Аллаһ шулай яралткан.
Бар тереклек катламнарда
Яшәү урыны тапкан.

Кешеләр дә катлам-катлам
Бар өске, аскы катлам.
Яшәр өчен һәр кешегә
Акыл иңгән бер саплам.

Һәр катламның үз шөгыле,
Үз тормышы, үз көе.
Һәркемнең үзенә лаек
Үз кәсебе, үз юне.

Берәүләр азык эшкәртә,
Берәү идарә итә.
Шат-бәхетле яшәү өчен
Мал-мөлкәтләре җитә.

Тик бер адәм катламнарны
Болгатырга маташты.
Арканнан* ычкынган халык
Аллаһ юлын саташты.

Рухи байлык җилгә очты,
Хәләлне йотты хәрәм.
Әдәп бетте, әхлак китте –
Яшәгән гомер әрәм.

Бөтен дөнья катлам-катлам -
Катламнар бер Ходайдан.
Үзгәртермен дип уйлама,
Тусаң да син яңадан!

---

* *Автор Аллаһының арканын искәртә.*

Июнь, 2015 ел.

Лаеклы син?..

Халык әйтә: «Тиле таш җыяр», дип,
Намуссызлар хәрәм мал җыя.
Әйтерсең, ул мәңгелеккә килгән,
Нәфесенә белми чик куя.

Урлый, талый, канлы акча саный,
Кеше хакын йолкып кинәнә.
Йөзәр, меңәр гектар җир чәлдерә –
Өч аршин җир җитә үзенә.

Әнә, кош-корт, терлек һәм җәнварлар
Көнлек ризык белән көн күрә.
Запас җыймый, аш-сусыз да тормый,
Көн биргән Зат җанга юнь бирә.

Дөнья малы – дөньялыкта кала,
Патшалар да берни аллмаган.

Элгәреләр акыллырак булган,
Аларның да эзе каллмаган.

Матди байлык череп юкка чыккан,
Инсаннарын җуйган чал тарих.
Мирас булып Илаһи сүз калган,
Китапларда калган хак Әлиф.

Әй, син, адәм! Уй-фикерле инсан!
Лаекмы син кеше затына?
Бармы изге-дини гамәлләрең?
Нилəр кылдың Аллаһ хакына?!

Әй син, Адәм! Уйлы акыл заты!
Миллиардермы, ханмы, корольме?
Мәхшәр көнне сине җитәкләргә
Фәрештәме, Иблис килерме?!

Октябрь, 2014 ел.

Дәһри адәм

Бер имансыз: «Алла юк», – дип әйтә,
Ил-җирләргә ялган тарата.
«Әлифне таяк дип белмәгән» ул –
Аш бирүче Затка таш ата.

Көч-кодрәте тиңсез Аллаһыга
Бу иш адәм тел-теш тидерә.

Үзен сөеп, юктан бар итүче
Илаһ Заттан йөзен чөерә.

Ай-кояшны Аллаһ күккә элде,
Җир, су, һава, утны бар итте.
Галәмнәрне гүзәллеккә бизәп,
Тереклеккә бакый җан кертте.

Адәменә – күркәм төс-кыяфәт,
Чиксез хөрлек бирде җанына.
Җир-әнкәнең барлык нигъмәтләрен
Көйләп куйды аның җаена.

«Эт симерсә, хуҗасын – ди – тешләр»,
Бу адәм дә Аллаһ юк дия.
Тик Аллаһка шөкерана кылып,
Гәммә мәхлүк бердәй баш ия.

Август, 2014 ел.

Бер киңәш

Быел җәй коры килде, һай,
Игеннәрне сусатты.
Яфраклар да саргаешты,
Үләннәр җиргә яттылар.

Кибегеп калды инешләр,
Чишмәләр моңсыз калды.

Кошлар томшыкларын ачты,
Илне шом биләп алды.

Ә беркөнне бала-чага
Булганын кичәк җыйнап,
Бер-беренә су сибеште,
Ходайдан яңгыр сорап!

Могҗиза булды шул кичне:
Күктә болыт куерды.
Бала-чага уйнашкандай,
Чиләкләп яңгыр койды.

...Бәйсезлек тә үзе килмәс,
Әйтче, халкым, теләгең!
Хак Тәгалә: «Бирермен, – ди, –
Сорасыннар кирәген!»

Июль, 2015 ел.

Аллаһының бүләге

Җанашыма багышлана

Гомер кысыр болыт сыман узган мәлдә
Кыйбла яктан җилләр исте сәйәр хәлдә.
Җирләр-Күкләр килде шунда хәрәкәткә,
Хәрәкәтләр булды шатлык-бәрәкәткә.

Бәгырьләргә җәрәхәтле эзләр салган
Мәсхәрәле кара еллар узып китте.
Хак Тәгалә, Гарешләрдә никах укып,
Дин-намазлы Асияны бирәк итте.

Аллаһының хак бирәген кабул иттем,
Әлһәм укып Аллаһыга рәхмәт әйттем.
Гомер буе хатыныма шөкер кылып,
Сөеп һәм сөелеп ипле гомер иттем.

Асиямның холкы күндәм, үзе күркәм,
Эш-гамәле игелекле, изгелектә.
Аллаһының хакын хаклап, динне саклап,
Гыйбадәтен кылыр сабыр түземлектә.

Юмартлыкта аңа тиңнәр илдә аздыр,
Кешеләрне шатландыру – аңа бәхет.
Бар булганы белән телән уртаклашыр:
«Көн биргәнгә Аллаһ юнен бирер», диеп.

Намус дигән затлы сыйфат алдан йөрер,
Уйларыбыз аның белән тәңгәл килде.
Тормышыбыз хәләл белән көн күрәдер,
Йортыбызга бәрәкәтле бәхет иңде.

Мең-мең рәхмәт Асияма, өебезгә
Әдәп-әхлак, дин-Коръәнле иман кайтты.
Хатын мине сый-хөрмәтле ире итте, –
Гәм үзе дә үзенә тиң ярын тапты.

Мин – фиргавен, ул – пәйгамбәр булмасак та,*
Без яшибез ахирәтне өстен куеп.
Хак Тәгалә рәхмәтеннән ташламасын,
Яшәрбез, шәт, җәннәтләрдә әһел булып.

**Асия – фиргавен Рамзес IInең хатыны, бердәнбер хатын-кыз пәйгамбәр.*

Ноябрь, 2014 ел.

Комагай

(Гыйбрәтле хәл)

Тумыштан сукыр бер туташ
Чик-чаманы белмәгән.
Гәрнәрсәнең дә тәмамы,
Ахыры барын күрмәгән.

Туташ, кош баласы кебек,
Гич тә туя белмәгән.
Хәтта үзенең барлыгын
Башкалардан көнләгән.

«Берәүләр шәп файдалана, –
Өлеш-хакымны ала.
Тияремне кия алмыйм,
Тамагым туймый кала».

Шулай дигән сукыр туташ,
Ризасызлык белдереп.

Барына шөкер итәргә
Гич булмаган күндереп.

Беркөн туган-тумачалар
Бәйрәм ясарга булган.
Туташның туган көнендә
Мул итеп табын корган.

Әзерләнгән ризыкларның
Төрлеләрдән-төрлесе.
Сатып алынган туташка
Киемнең зиннәтлесе.

Утырган туташ табынга
Күлмәкне кат-кат киеп.
Тәмле-татлы ризыкларны
Куйган алдына өеп.

Тотынган зур ләззәт белән,
Дәһшәт белән ашырга.
Ризыкларның барысын да
Өлгергән ул башларга.

Күрмәсә дә, як-ягына
Каранган ул шикләнеп.
Берәрсе аның өлешен
Чәлдерүдән бикләнеп.

Кабаланып бүселгәндә
Туташ кинәт тончыккан.

Ғорчактай валчык кисәге
Ғарыр юлын адашкан.

Сулыш юлы капланганнан
Ул тын-һавасыз кала.
Табибләр өлгерми кала -
Тук җаны тәслим кыла.

Июль, 2015 ел.

Саранлык бәласе

Саранлык та, юмартлык та, –
Үз эшләрен башкара.
Артык юмарт булганнарның
Ғаиләсе ач кала.

Динне белми, зәкят бирми
Яшәсә саран посып,
Җәннәт әһеле булалмас,
Калыр ул малын кочып!

Ноябрь, 2015 ел.

Урталай...

Аллаһ хәрам кылган дуңгыз -
Адәмнең холкын белгән.
Дуңгызлыгын иткән дуңгыз -
Кешенең аңын бүлгән.

Уд берәүнең – табын тәме,
Сатып файда күргәне.
Ә берәүгә җәһәннәм ул,
Шайтан малы дигәне.

Ул – галимнәр бәхәсендә
Һәм дин, гыйлем телендә.
Бик зәхмәтле бер хәшәрәт
Яши диләр тәнендә.

Бу сүзләр юкка түгелдер,
Бардыр яшерен сере, -
Аллаһ тыйганнан тыелу -
Фарыз эшләрнең бере.

Тик Адәм дуңгыз үрчетә,
Ашый итен, маен да.
Гөнаһлы гамәл кылса да,
Дуңгызлык – үз җаенда.

Декабрь, 2006 ел.

Сабырлык турында

Сабыр гына кояш бата,
Ай-йолдызлар төн ката.
Сабыр гына ал таң ата,
Җир-әнкәгә көн кайта.

Тормыш шулай дәвам итә,
Кем килә, кемдер китә.
Сабырлыгын җуйган затны
Ай-кояшсыз төн көтә.

Тик сабырлар атын җигәр,
Үз юлы белән китәр.
Тәкъдире белән җайлашып,
Барыр җиренә җитәр.

Сабырлылык аять булып,
Коръәнгә күктән иңгән.
Сабыр булуны бабамнар
Алтыннан өстен күргән.

Ноябрь, 2014 ел.

Уйлан, Кеше!

Акыл, фикер иясе булса да,
Ләкин кеше мохтаҗ ярдәмгә.
Илаһи зат диеп табына ул
Җансыз сынга, потка, рәсемгә.

Берәүләре үзен «алла» дия,
Сыерга да берәү баш ия.
Табынулар ялган «алла»ларга –
Бидгәт гамәл, бозык тәрбия.

Хак Тәгалә рәсем, пот та түгел,
Соры сыер кебек мәхлук та.
Ул мәңгелек дөньяларны төзи,
Чигъмәтләре хәят кормакта.

Тик адәмнең комсыз дәһриләре
Хакыйкатьне инкяр итмәкче.
Галәмнәргә үзен хуҗа итеп,
«Җир читенә» барып җитмәкче.

Ә хыялый-уйлы галимнәре
Двигатель тапмак мәңгелек.
Тумаган һәм тудырмаган Аллаһ
Тик бердәнбер тере мәңгелек!

Ул илаһи кодрәтенә төреп,
Галәмнәрне юктан бар кылды.

Хак Тәгалә – мәңгелек хәрәкәт,
Хәрәкәттән – яшәү бар булды.

Дин – иманлы, игелекле булсын,
Хәрәкәтләр бирсен бәрәкәт!
Бисмилласыз, денсез кавемнәрне
Хәрәкәтләр итте һәлакәт.

Август, 2014 ел.

Соңгы чик

Без кешене акыллы зат дибез,
Чынлыкта ул акыл затымы?
Акыл заты диеп аталырга
Адәми зат чынлап хаклымы?

Яралганнан бирле кан-яшь коя,
Сугышмыйча торган чагы юк.
Җир-әнкәне талый, күкне даулый,
Нәфесенең иге-чиге юк.

Дөньядагы һәммә җан иясе
Табигатькә яши ярашып.
Кеше заты берсе белән берсе
Бертуктаусыз тора талашып.

Аңа һаман дөнья малы җитми –
Аннан йолкый, моннан умыра.

Җәннәткә тиң гүзәл җир-әнкәне
Мәсхәрәли, шәрә калдыра.

Йә әйт, кеше. Син кем? Гәм ни өчен
Яратылдың гүзәл бу җирдә?
Акыл, зиһен кебек сыйфатларың
Кирәк кадәр юкса үзеңдә.

Аллаһ сине хак вәкиле итте,
Китапларын сиңа иңдерде.
Дин-иманлы, намаз-гыйбадәтле
Кеше итеп җиргә күндерде.

Җир-әнкәдә тормыш булсын өчен
Хаким булу кирәк кешегә.
Динле булу, гыйбадәтле булу –
Син бәхетле булсын өченгә.

Тик син, кеше, үтә киребеткән,
Үз туксаның синең тик туксан.
Кырык ел син чүл-сахралар гиздең,
Арынмадың котсыз холыктан.

Ничә килдең, ничә киттең Җирдән,
Аллаһ сине кат-кат сынады.
Утка якты, күктән ташлар атты,
Суга батырып та карады...

Тик син һаман гыйбрәт аласың юк,
Башың бетәр эшләр кыласың.

Көч-дәһшәтле корал ясауларың
Үз башыңа, бел син, буласын?!

Уйла, кеше! Афәт якыная,
Акылга кил. Төзәт ялгышны.
Йә Аллаһка тәүбә итәсең, йә
Туктатасың җирдә тормышны.

Җир-әнкәне үз әнкәңдәй ярат,
Аның кебек бул син хикмәтле.
Акыл белән гамьле яшәгәндә
Булырсың син һәрчак җәннәтле.

Гыйнвар, 2016 ел.

Онытмыйк!

Әй татарым, мин синең бер улың,
Гомер буе ихлас яраткан.
Гомер буе сиңа тугры калып,
Җан-тәнеңә сихәт тараткан.

Бу дөньяда озын-озак яшәп,
Аңладым мин изге хаклыкны.
Язмышларны үзгәртерлек тиңсез
Тик Аллаһта кодрәт барлыкны.

Үз дәүләтле әгәр булыйк дисәк,
Арканына аның тотыныйк.
Сораганга бирермен, дигән Ул,
Сорый-сорый сәждә без кылыйк.

Үткәннәрдән сабак, гыйбрәт алып,
Хата-гөнаһларны онытыйк.
Аллаһының ярлыкавын сорап,
Тәүбә итәргә дә онытмыйк!

Май, 2016 ел.

Аллаһу әкбәр

Аллаһ Тәгалә бердәнбер
Аллаһу әкбәр.
Ул – Ғаләмнәрнең хуҗасы
Аллаһу әкбәр.

Табынып Аны зурлыйбыз
Аллаһу әкбәр.
Аңа бар мактауларыбыз
Аллаһу әкбәр.

Дан-дәрәҗәсе олугтыр
Аллаһу әкбәр.
Аның һич тә тиңә юктыр
Аллаһу әкбәр.

Ул – яшәеш бирүче дә
Аллаһу әкбәр.
Ул – нигъмәтләр бирүче дә
Аллаһу әкбәр.

Теләкләрне багышлыйбыз
Аллаһу әкбәр.
Ғөзерләребез юллыйбыз
Аллаһу әкбәр.

Хак мөселман аңа бага
Аллаһу әкбәр.

Иманлы кальбе сафлана
Аллаһу әкбәр.

Рәхим-шәфкатен бирмештер
Аллаһу әкбәр.
Җәннәтләреңә ирештер
Аллаһу әкбәр.

Июнь, 2016 ел.



III бүлек



Җырның ертыгы юк, диләр,
Ертык ертык инде ул.
Тылсымлы татар моңының
Рәхмәт фәрештәсе бул!

Лә иләһә илләл-лаһ *

Лә иләһә илләл-лаһ -
Аллаһы тик бер, дию.
Җамәл-гыйбадәтләр кылып,
Аны ихластан сөю.

Лә иләһә илләл-лаһ -
Мөхәммәдәр-рәсүлүл-лаһ.
Аның илче икәнлеген
Коръәндә әйтә Аллаһ.

Лә иләһә илләл-лаһ -
Мөселманның туграсы.
Лә иләһә илләл-лаһ -
Җәннәт ишек тоткасы.

Кушымта:

Лә иләһә илләл-лаһ,
Лә иләһә илләл-лаһ.
Аллаһ – Җәләмнәр Раббысы -
Бердәнбер тиңсез Илаһ.

---

* Рамил Курамшин көе.

Июль, 2015 ел.

И кардәшләр!

И кардәшләр! Бергәләшеп
Килик бер изге уйга.
Ата-бабалар дәүләтен
Керешик торгызуга.

Кушылма: *Ак калфаклы чал Идегә*
Елга-сулар тоташа.
Дөньяга сибелгән татар
Берләшә Казан аша.

Шанлы ата-бабаларның
Әманәтләрен үтик.
Алтын Урда, Идел-Йортны
Хокуклы дәүләт итик!

Дөньяны иңли татарның
Сабантуе, җыены.
Татарстан – халкыбызның
Мәңге яшәр урыны!

Ноябрь, 2015 ел.

Бердәм булыйк!

Рамил Курамшин көе.
Рәис Сафин шигыре.

Ил-җирләребез – берлектә,
Асылыбыз да – бердән.
Рухи байлыгыбыз – уртак,
Тел ләребез дә – күркәм.

Ата-баба бергә яшәп,
Мәшһүр дәүләтләр корган.
Язмышлар хәл ителгәндә –
Кардәшлек – өстен торган.

Борынгылар васыять итеп,
Бердәм булырга кушкан.
Без – бер ата балалары –
Каннар белән тоташкан.

Арабызга дошман кереп,
Аермасын бүлгәләп.
Тамырларның бердәмлеген
Саклыйк, дуслар, бергәләп.

Май, 2015 ел.

Әй, татар җанлы туганнар!

(Җыр)

Үткәннәрдән гыйбрәт алып,
Хаталарны уйга салып,
Берләш, татар! Аллаһының
Хәер-фатыйхасын алып,
Телең, динеңдә калып.

Кушылма:
Әй, татар җанлы оланнар, –
Адашканнар, ялгышканнар...
Асылда без бертуганнар, –
Бер атадан безнең каннар.

Үз илең бар, үз җирең бар,
Йөрмә киллмешәк булып.
Кайтар шанлы дәүләтеңне,
Торсын татарың тулып,
Яшә чын хуҗа булып.

Кушылма:
Әй, татар җанлы оланнар, –
Адашканнар, ялгышканнар...
Асылда без бертуганнар, –
Бер анадан безнең каннар.

Милли холык

Мәсгут Исхаков көе.

Кыпчак-татар Иртеш-Дунай арасында
Алтын Урда, Идел-Йорт дәүләтен корды.
Татар булып гомер итү җиңел түгел,
Ата-баба дошманнарга каршы торды.

Татар булып гомер итү– җиңел түгел,
Сынауларда чыныгадыр милли әһел.
Татар булу – дәрәҗәле, затлы булу,
Горурлыктан балкып торыр безнең күңел.

Татар булу – икеләтә авыр бүген,
Илсез калдык, телсез калып бара халык.
Аллаһ кушса, ил табылыр, тел дә кайтыр,
Җаныбызда саклансын тик милли холык.

Татар моңы

Гомер буе эчтән моңаямын,
Сагышланам, сызам, тетрәнәм.
Татарымның моңы кодрәтендә
Мин үзем дә моңга әйләнәм.

Моң канаты күккә чөеп ала,
Ак болытлар белән йөзәмен.

Җиселнәрнең серле авазыннан
Бабамнарның рухын сизәмен.

Җирләр-күкләр бергә тоташалар,
Гәр тарафны айкый сихри моң.
Дала-чүлләр, елга күлләр җырлый -
Бөтен дөнья тыңлый калып тын.

Моңда тарих. Мәшһүр бабамнарның
Дан-шөһрәтле юллар узганы.
Кыйтгаларны кочкан татарымның
Җан авазы – «Кара урман»ы.

Җаным сыкрый, үзәк өзгәләнә,
Югалтулар телә бәгырьне.
Күңелемдә җыр-моң ташкыннары,
Яшь пәрдәсе каплый күземне.

Җан тетрәткеч, һуштан яздырырлык
Илаһи моң кайсы милләттә?!
Ул моң бездә! Татар күңелендә, –
Ут – ялкынлы милли йөрәктә!

Февраль, 2012 ел.

Әй, җир-әнкәм...

Әй, җир-әнкәм, чал башымны иеп,
Мең рәхмәтләр әйтәм мин сиңа.
Аллаһ мине синнән яралткан, ди...
Кайтыр өчен кире куйныңа.

Әй, җир-әнкәм, яшеллекләр иле,
Үсемлекнең иге-чиге юк.
Мәрхәмәтең, сый-хөрмәтең мулдан,
Терекләрең яши синдә тук.

Әй, җир-әнкәм, синең кочагыңда
Җан-иянең эре, вагысы.
Хозурыңда бар да парлы-парлы,
Зикер әйтә сиңа барысы.

Әй, җир-әнкәм, тиңсез Аллаһ кебек,
Син илаһи, көчле-куәтле.
Галәмнәрдә синең кебек гүзәл,
Юктыр җәннәт синдәй зиннәтле?!

Октябрь, 2014 ел.

Бәрәңге җыры

Һәр туфракта үсәсең син,
Таралып, йомарланып.
Пешәсең хуш исләр бөркеп,
Парланып, ярмаланып.

Кушылма:
Бәрәңге, береңгекәем, –
Тормышыбыз шатлыгы.
Җан-тәннәргә сихәт биргән,
Хәләл ризык хаклыгы.

Иртә-кичен һәр кешенең
Син яраткан ризыгы.
Һәр табынның муллыгы син,
Һәр күңелнең тансыгы.

Син халыкның яратканы, –
Патшалар, ханнар сые.
Табыныбыз түрендә син
Һәркемнең гомер буе.

Аналар мәхәббәте

Һәм табигать, һәм мәхәббәт – илаһи көч,
Сихрилектә, гүзәллектә – тиңдәшсезләр.
Табигатьле, мәхәббәтле адәм заты, -
Дөньядагы тереклектә көндәшсезләр.

Табигатьнең, мәхәббәтнең үз кануны, -
Хак Тәгалә ирекле иткән аларны.
Бер-берсенә мәңге гашыйк ир, хатынның
Табигатьле, мәхәббәтле бакый җаны.

Хис иясе, акыл иясе – кешенең
Дөньялыкта мәхәббәте төрле-төрле.
Тик аналар мәхәббәте – бер үк төрле, -
Ул мәңгелек җан шикелле – яшь гомерле.

Июль, 2011 ел.

Туган йорт, туган нигез

И нигъмәтле туган йортым,
И мөкатдәс нигезем.
Ай-кояш кебек бердәнбер
Газизләрдән-газизем.

Кушымта: Туган йортым, чал нигезем,
Сез бертуган, бертигез.
Буыннарны тоташтыра –
Туган йорт, туган нигез.

Синдә әби-бабам рухы,
Нәселемнең узганы.
Дин-иманлы тәкъдирләрдә
Хак Тәгалә язганы.

Синдә әти-әниемнең
Хәләл хезмәте калган.
Мирас нигезне яратып,
Безгә яшәргә язган.

Кушымта: Туган йортым, чал нигезем,
Сез бертуган, бертигез.
Буыннарны тоташтыра –
Туган йорт, туган нигез.

Сентябрь, 2014 ел.

Әти бәгърем

Син сугышка китеп барган чакта,
Кочагыңа мине алгансың.
«Исән-сау бул. Дөрес яшә», – диеп,
Күңелемә ният салгансың.

Кушымта:
Әти, бәгърем, ятим үссәм дә мин,
Син һәрвакыт булдың янымда.
Син һаман да минем янәшәмдә,
Синең җаның – минем җанымда.

Син хәбәрсез югалгансың, әти -
Яу кырында шәһид киткәнсең.
Дошманнардан саклап илебезне,
Безгә яшәү бүләк иткәнсең.

Әманәтле изге васыятеңне
Намус белән үтәп яшәдем.
Гәрбер кылган эшем-гамәлемне,
Күңел бизмәнендә үлчәдем.

Кушылма:

Әти, бәгърәм, ятим үссәм дә мин,
Син һәрвакыт булдың янымда.
Син һаман да минем янәшәмдә,
Синең җаның – минем җанымда.

Гыйнвар, 2015 ел.

Әнкәй бәгърем

Әнкәй, бәгърем, син бит – җаным-тәнем,
Җир йөзендә яшәү берлегем.
Дөньялыкны миңа бүләк иткән,
Газизләрдән – газиз кадерлем.

Камиллектә сиңа тиңдәш юктыр,
Сыйфатлары синдә Аллаһның.
Яшәешне асыл затлы иткән
Син кодрәте тиңсез Иләһның.

Күңел күгең – диңгез тирәнлеге,
Ғаләмнәрнең чиксез колачы.
Әманәтле изге гамәлләрең -
Ғабамнарның хәер-догасы.

Милләтебез ай, кояшы булып,
Яшә, әни, кылып игелек.
Милләтебез һәрчак чәчәк атсын,
Ғалкып торсын булып мәңгелек!

Әнкәй, бәгърем, мең-мең рәхмәт сиңа,
Табып-багып кеше иткәнсең.
Җирләр-Күкләр иҗат иткән серле
Могҗизаның үзе икәнсең!

Март, 2015 ел.

Авылдашларга нәсыйхәтем

Мәсгут Исхаков көе.

Авылдашлар, аркадашлар,
Китмик туган туфрактан:
Йортларда учак сүнмәсен,
Өзелмик милли аштан!

Кушымта:

Авылдашлар, кан кардәшләр,
Сүзем ихлас күңелдән:
Китмәгез сез – җан яралган,
Ғазиз кендек каны тамган,
Изгедән-изге җирдән.

Сак-Соклар кебек булмасын
Җан белән кендек каны.
Икәве дә – бертуганнар,
Аермыйкчы аларны.

Кушымта.

Каллмасын шушы тәңгәллек
Сагынулы моң-зарда.
Сагыштан газап чикмик без
Туган җиребез барда.

Кушымта:

Авылдашлар, кан кардәшләр,
Сүзем ихлас күңелдән:
Китмәгез сез – җан яралган,
Газиз кендек каны тамган,
Изгедән-изге җирдән.

Сезгә дәшәм

Тәлгат Вәлиев музыкасы

Әй туганнар, әй кардәшләрем,
Әй кадерле дус-ишләрем.
Сез кояшым минем, сез аем,
Сездән башка мин соң нишләрем?

Ай-кояшны болыт япмасын,
Исмәсеннәр җилләр телгәләп.
Сый-хөрмәттә яшик бергәләп,
Барын-югын уртак бүлгәләп.

Яшик әле сөеп-сөешеп,
Күңелләрнең назын бүлешеп.
Хәл белешеп, кунак йөрешеп,
Чын күңелдән куллар бирешеп.

Мәхәббәтле итик гомерне,
Үкенечтә булып калмасын.
Җир җәннәте ясыйк дөньяны,
Татып аның сихри алмасын.

Язлар булып гөрлә гомеркәй,
Җәйләр кебек итик тормышны.
Бәхет-шатлык бүләк итсен ул,
Мәрхәмәтле итсен язмышны.

Якты нурлар җанда уйнасын,
Тормышыбыз чәчәк коймасын.
Күңелләрдә хисләр яңарсын,
Тойгыларның татыйк яңасын.

Бу дөньяга кеше бер килә,
Яшәеше аның бер мизгел.
Мәк чәчәге кебек гомерне
Юрый күрмә безгә, искән җил!

Күңелне яшәртеп, ямь итеп,
Озынайтыйк яшьлек гомерен.
Бу дөньяның чигеп рәхәтен,
Яшәүләрнең белик кадерен.

Аты елгасы буенда

Бик борынгы нәселдән без –
Данлы Казан артыннан.
Кыр казларыдай тезелеп,
Куш авыллар калыккан.

Кушылма:
Субаш-Аты, Урта-Аты,
Югары, Түбән-Аты.
Аты елгасы буенда
Халкым бәхетен тапты.

Ата-бабам гомер иткән
Иделгә ул тоташа.
Гасырлар язмышы ага
Безнең тамырлар аша.

Буыннарны илгә бәйләп,
Ага Аты елгасы.
Суын эчеп, тормыш корып,
Безгә яшәп каласы,
Киләчәккә барасы!

Кушылма:

Субаш-Атым

Рамил Курамшин көе

(Җыр)

Субаш-Атым – затлы йортым,
Сокланам сиңа карап.
Асылташлы беләзектәй
Чишмәләр алган урап.

Кушылма:
Чишмәләреңә кушылып
Мин дә Иделгә актым.
Болыт булып күккә аштым,
Яңгырлар булып кайттым.

Субаш-Атым – айлы йортым, –
Гомеремнең юл башы.
Дин-иманлы мәчетебез –
Авылым йөзек кашы.

Субаш-Атым, күккә бактым,
Таң булып синдә аттым..
Күктән эзләгән бәхетне
Газиз җиремдә таптым.

Субаш-Атым, ата-бабам,,
Догалы нигез салган.
Мәңгегә синдә калырга
Тәкъдирем итеп язган.

Кушымта:

Чишмәләреңә кушылып
Мин дә Иделгә актым.
Болыт булып күккә аштым,
Яңгырлар булып кайттым.

Яшә, Арчам!

Рамил Курамшин көе

(Җыр)

Туган җирем, газиз җирем, –
Ата-бабамнар җире.
Син җаныма иң кадерле
Җирләрнең бердән-бере.

Кушымта:

Яшә, Арчам – шаһлар иле! –
Туган телебез тажы.
Илаһи көч, илһам бирә
Шанлы чорлар авазы.

Җир-суларың бәрәкәтле,
Табының – сый-хөрмәтле.
Язмышлар хәл ителгәндә -
Син арыслан йөрәкле.

Кушымта.

Мәшһүр әдипләрең белән

Горурлан Арча халкы!
Бул кодрәтле, дан-шөһрәтле,
Милли рухыңда балкы!

Кушылма:
Яшә, Арчам – шаһлар иле! –
Туган телебез тажы.
Илаһи көч, илһам бирә,
Шанлы чорлар авазы!

Илле яшь ул...

Илле яшь ул – бәрәкәтле август ае:
Җиләк җимеш белән тулы бакча ягы.
Кешенең дә дәверләрне тоташтырып,
Ил алдына исәп-хисап тотар чагы.

Илле яшь ул – бәрәкәтле август ае:
Гомернең дә дәрәҗәле челлә мәле.
Дөньялыкта кылган изге гамәлләрнең
Игелеген күрер көннәр алда әле.

Илле яшь ул бәрәкәтле август ае:
Үткәннәргә каерылып бер карар чак.
Эш-гамәлең милли төсен югалтмасын,
Нәсел-нәсәп җебе булсын кулда һәрчак.

Гыйнвар, 2013 ел.

Илаһи җыр

Ғаләмдә бар да тугандаш,
Әйтерсең, агай-эне.
Дөньяны назлап иркәли
Ай, Кояш төне-көне.

Кушымта:

Бөтен нәрсә камиллектә,
Барысы да гадәти.
Табигатьнең һәр почмагы
Могҗизалы Илаһи.

Җирдә, Күктә нур балкышы,
Ғаләм ямьгә төренгән.
Күккә гашыйк гөл-чәчәкләр
Ай, кояшка үрелгән.

Талгын җилдән дулкынлана
Нурлы иген кырлары.
Башакларның, чәчәкләрнең
Егет-кыздай чорлары.

Сокландыргыч җир-әнкәне
Сөеп кадерен белик.
Кабатланмас яшәешне
Изгелек белән бизик.

Апрель, 2015 ел.

Хәят нуры

Дөньяларны нурга манып,
Колач җәеп таң ата.
Кояшның назлы нурлары
Баштан сыйпап уята.

Кушымта:

Нурларда безнең яшәеш,
Нурларда безнең язмыш.
Якты нурлар сабагында
Чайкала бәйге тормыш.

Нурлар уйный җирдә-күктә,
Уйный кеше йөзендә.
Гәркемне асыл зат иткән
Кояшы бар үзендә.

Шул кояш җанны җылыта,
Шатландыра-көлдерә.
Нурлары белән иркәләп,
Яраттыра, сөйдерә.

Күңелнең хәят кояшы
Ямьле таңнар аттыра.
Яхшы сүздән, нурлы күздән
Гомер юлы яктыра.

Июль, 2015 ел.

Сөю турында

Яз җиттеме, моңлы сайрап,
Кошлар канат кагына.
Сихри кояш нурларыннан
Сөю уты кабына.

Җир-ана гөлләр үстерә
Җан җылысына төреп.
Кояш хисләр бүләк итә,
Чурлардан сөю үреп.

Мәңгә җаннар әле гөлгә,
Әле кояшка бага.
Язгы иләс күңелләрдә
Сөю дәрьясы ага.

Кушымта:
Күктә кояш балкып торсын,
Язлар елмаеп-көлеп.
Гүзәлем яшәсен рәхәттә –
Сөю ләззәтен белеп.

Август, 2012 ел.

Мәхәббәт манзарасы

Кояш нурларына кунып,
Очынып бер кош сайрый.
Парлашып бергә очарлык
Бердәнбер ярын сайлый.

Кушымта:

Кошлар сайрашып таныша,
Кеше – хисләр алыша.
Ике мәхәббәт кавыша -
Кояш нурлары аша.

Гүштан язарлык иттереп,
Сайрый ул эзләп парын.
Сайрый ул әйтеп үзендә
Ялкынлы сөю барын.

Өзгәләнеп бер кош сайрый
Табигать калган тынып.
Язын мәхәббәт елмая
Күңел кылына кунып.

Август, 2012 ел.

Мәхәббәт аҗаганы

Әбәү, бәгърем, син кешеме?
Аллә күкнең йөземе?
Илаһи нурлар сибүче
Ай, кояшның үземе?

Йөзеңдә Йосыф нурлары,
Ләйләнең гүзәллеге.
Серле-сихри күзләреңдә
Галәмнең тирәнлеге!

Дугадай керфекләреңә
Энҗе-мәрҗәннәр кунган.
Йолдызлар булып җемелди
Төнге күк йөзе сыман.

Кояштай елмаеп куйсаң,
Ачыла күк капусы.
Тылсымлы карашларыңда -
Алсу таңнар балкышы.

Бу кадәр сихри гүзәллек
Булса да булыр икән!
Аллә Илаһи нурларын
Аллаһ бөркеде микән?!

Аяз көндә яшен сукты,
Йөрәгемдә – ялкыны.
Күңелемне урап алды
Мәхәббәт аҗаганы.

Декабрь, 2013 ел.

Син – мәхәббәт бит үзең

Сөбхәналла, күз тимәсен,
Карыйм сиңа сокланып.
Күңел бакчамда яшьнисең
Гөлләрдәй чәчәк атып.

Күзләреңдә – Галәм нуры,
Йөзләреңдә – ай, кояш.
Йолдызлар булып балкыйсың,
Әйтерсең син асылташ.

Серле-сихри карашларың
Җанда мәхәббәт үрә.
Күңелләрне хискә төреп,
Йөрәкне җилкендерә.

Елмаюлы көләч йөзең
Иреннәреңә кунган.
Табигать сине тылсымлы
Сөйдергеч итеп кылган.

Йа, Ходаем! Мәңгүн булган
Гашыйкларга бир түзем.
Дөньяда яшәү бар иткән
Син – Мәхәббәт бит үзең!

Октябрь, 2014 ел.

Мәхәббәт нуры

Аллы-гөлле дә түгел син,
Салават күпере дә.
Тик сиңа тиңләшә алмый
Чәчәкләрнең берсе дә.

Әйтерсең, Ай белән Кояш
Ике зәңгәр күзең дә.
Ай-кояшны сокландыргыч
Нурлар балкый йөзеңдә.

Чәчләреңдулкыннарында –
Иген кырлары моңы.
Күңелләрне әсир итә
Чулпыларыңның чыңы.

Буең-сының, кыяфәтең
Хикмәти көчкә ия.
Син – йолдызлы, сихри-серле,
Тылсымлы күкләр гүя.

Мәхәббәт галәмәте

Җир-күкләрне балкытасың,
Син әллә таң йолдызы?
Фиргавенне гашыйк иткән -
Әлләме пәри кызы?

Йөзләреңдә Йосыф нуры,
Зөләйха чибәрлеге.
Ай-кояшлы күзләреңдә -
Гүзәллек чынбарлыгы.

Сихерләдең мәхәббәтнең
Татлы газабы белән.
Өнемдә дә, төшемдә дә –
Күңелем синең белән.

Җил-давыллы мәхәббәтем
Әермә булып дулый.
Акылдан язган хисләрем,
Йөрәккәемне турый.

Февраль, 2015 ел.

Ана булу

(Җыр)

Мине тапкан, сөеп баккан
Син – кадерле әнием.
Буй җитсәм дә, зур үссәм дә,
Мин һаман да бәбиең.

Кушылма:
Җир-әнкәнең син килене,
Аллаһының бүләге.
Безне багып үстерәсең,
Син дөньяның бизәге.

Болыт килми, яңгыр яумас,
Яшен булмый күкрәүсез.
Мәхәббәт тә ут-ялкынсыз
Җимеш бирми икәүсез.

Гамәлләреңә изгелектә,
Үй-теләкләреңә күркәм.
Ана булу – мәхәббәтнең
Илаһилыгы икән.

Июль, 2016 ел.

Үзәкләремне өзә

(Җыр)

Казаным кызы – Фәнүзә,
Үзәкләремне өзә.
Ут-ялкынлы йөрәккәем
Әле дә ничек түзә.

Бер күрүдә гашыйк булдым,
Мәхәббәт белән тулдым.
Күңелем мөлдерәп ташый
Хисләремә уралдым.

Мәхәббәтне, яратуны
Алмасалар да сорап.
Йөрәгемне тәкъдим итәм
Күзеңә туры карап.

Бул минеке, мин – синеке,
Гомер кичерик бергә.
Тормышларны ямьгә бизәп,
Яшик бергә гомергә.

Июль, 2016 ел.

Татар кызы!

Синдә далалар киңлеге,
Тауларның горурлыгы.
Гәммә төрки кавемнәрнең
Затлы борынгылыгы.

Синдә Себер иркенлеге,
Кырымның күркәмлеге.
Фигыль-холкыңда Иделнең
Сабырлык тирәнлеге.

Уңганлыгың, булганлыгың
Татарлыктан дан ала.
Милләтең килене булу –
Дәрәҗәле санала.

Син – ата-бабай мирасы,
Әманәтле байлыгы.
Шул байлыкта халкыбызның
Мәңгелек татарлыгы!

Кушымта:
Таңнар йолдызы,
Язларның язы.
Чәчкәләр тажы,
Син – татар кызы!

Август, 2017 ел.

Ихлас күңелдән

Җир-күкләрдә нур балкытып,
Алсуланып таң атты.
Адел-Алсу күңелендә
Мәхәббәт чәчәк атты.

Күктә никах укылсынга
Аллаһ фатиха бирде.
"Бер-берегезне яратып,
Рәхәт яшәгез", - диде.

Ихласлы изге теләкләр
Сезгә тели без без дә.
Никах вәгъдәсенә тугры
Булыгыз икегез дә.

Игелекле сәламәтлек
Җан-тәнегездә булсын.
Шат-бәхетле тормышыгыз
Мөлдерәп ташып торсын!

Хисләрегез сүрелмәсен
Гомерләр үткәндә дә.
Үзара тансык булыгыз,
Картайган көннәрдә дә.

20 ноябрь, 2016 ел.

Котлау сүзе

Артем, син Әлмәт егете,
Фәнүзә – Казан кызы.
Сезгә әйтер сүзем шул:
Тату гомер кичерегез,
Үзара бирешеп кул.

Тәһир-Зөһрә мәхәббәте
Илһам бирсен гомергә.
Дөньяның рәхәтен татып,
Яшәгез бергә-бергә.

Гомер итегез берлектә
Игелекләр алмашып.
Изге гамәлләр кылуда
Гомер буе ярышып.

Хак Тәгаләнең рәхмәте
Гәрвакыт юлдаш булсын.
Мәхәббәтле бәхет-шатлык
Нурларын чәчеп торсын.

Җаннарыгызны беркетеп,
Укылды ике никах.
Күктә – җирдәге никахның
Хаклыгын саклар Аллаһ!

Июль, 2016 ел.

Кыр чәчкәләре – гүзәлләр

Күз явын алыр чәчкәләр
Болын-кырларда үсә.
Ак, зәңгәр, алсу таҗларын
Назлап талгын җил исә.

Кушылма: Кыр чәчкәләре гүзәлләр,
Иркендә үскәнлектән.
Чәчкәләрдәге затлылык -
Табигый гүзәллектән.

Аллы-гөлле чәчкәләрне
Иркәли нурлар иртән.
Әйтерсең, болын-кырларга
Ай-кояш төшкән күктән.

Нәзакәтьле чәчкәләрнең
Күңелләрдә хуш исе.
Әнкәйләребез йөзендә -
Кыр чәчкәләре төсе.

Кушылма: Кыр чәчкәләре гүзәлләр, –
Җир-әнкәй яме белән.
Кыр чәчәкләре хуш исле –
Җилләрнең тәме белән,
Җир-күкләр гаме белән.

Апрель, 2008 ел.

Әй, Чулпан

Ай күргән, ко яш алганмы
Сабакташым-Чулпанны.
Шәм яндырып эзләсәң дә,
Табармын димә аны.

Кушымта: Укытучылар борчыла,
Аптырый сабакташлар.
Кайчан бу Чулпан дәрестән
Качып китүен ташлар?

Таң йолдызы шикелле ул
Күренеп кенә ала.
Күренеп кенә ала да, -
Йолдыз сыман югала.

Кушымта.
Әллә качышлы уйнарга
Уйлаган инде Чулпан?
Әллә үзе йолдыз булып,
Зәңгәр күкләргә ашкан?

Кушымта: Укытучылар борчыла,
Аптырый сабакташлар.
Кайчан бу Чулпан дәрестән
Качып китүен ташлар?

Октябрь, 2011 ел.

IV бүлек



Ил анасы булган Аналарга
Саф алтыннан һәйкәл куярлык.

Ана

Кадерле әнием Шакиржан кызы
Хәбибҗамал истәлегенә.

I

Сабырлыкны, әнкәм, кайдан алдың?
Мин үзем дә белмим, әлбәттә...
Хәсрәт чигеп ачлы-туклы яшәү
Гаварнәрдә керде гадәткә,

Кырык бернең ачы салкынында
Туң җир чукып, окоп казу да,
Кояш белән торып, ай тулганчы
Урак уру уттай кызуда,

Бил тиентен карга бата-чума
Урман кисү, тиргә чыланып,
Туң сазлыкның салкын базларында
Интегүләр, торф чыгарып.

Күтәртмәле чабаталар киеп,
Симәнәгә таңнан йөгерү, —
Чана тартып, иңгә биштәр асып,
Язгы ташуларда юл йөрү.

Салкын көздә, кышкы бураннарда
Иген сугу ачык ындырда...
Үгез җигеп, ашлык тапшырулар,
Көнен-төнен буран-яңгырда.

«Юл газабы – гүр газабы,» – диләр,
Бу мәхшәрнең кайда азагы?
Гүргә кереп ятудан да яман
Карлы суда йөрү газабы.

Гәммәсе дә синең баштан узган,
Гәммәсен дә үзең күтәрдең.
Мич артына кереп еласаң да,
Тешең кысып, сабыр үткәрдең.

Барысы да җаның аша үтте,
Йөрәгеңә яра, эз салып.
Гомереңне эшкә багышладың,
Сөйгәнеңнән яшьләй тол калып.

Ышанмадың соңгы сулышкача
«Ирең үлде» дигән хәбәргә...
Әтиемне үзеңнән дә артык
Син сөймәгән булсаң әгәр дә,

Язмас идем шигъри бу кыйссаны
Газиз әнкәм, минем, сөеклем.
Миллионлаган кызлар, тол Аналар
Тугрылыгын күреп мин үстем.

Сөйгән ярым кайтыр, диеп алар,
Өмет баглап юлны күзләде.
Соңгы сулышында, аны дәшеп,
Бердәнберен көтте, эзләде.

Әтиемне сагынулардан син дә,
Шашар хәлгә җиттең кайчакта.
Күңелеңне сагыш баскан чакта,
Улың булды кайнар кочакта.

Үзең кебек дөрләп, өзгәләнеп,
Ярсып янган учак каршында.
Үчти-ячти сөйдең син улыңны,
Бәйнә-бәйнә сөйләп барсын да.

Габдуллаҗнан килгән өчпочмаклы
Юл хатларын укып юандың.
Җан җылысы сеңгән шул хатларны
Күкрәгеңә кысып еладың.

Түземлекнең дә бардыр бер чиге,
Ач торуның чиге – зиратта.
Кызыл балчык өемнәре артты,
Кемнең кадерлесе чиратта?

Ай-һай, авыр булды көн күрүләр,
Аягында иде чабата.
Авыл халкы черек бәрәңгедә,
Үйсулыкта әле кар ята.

Былтыргыдан калган башакларны
Басулардан җыеп йөрделәр.
Гәм берәүләр зәңгәр башакларның
Агуыннан чирләп үлделәр.

Иң авыр чор: базлар – бәрәңгесез,
Әигеннәр әле – серкәдә.
Керосин һәм шырпы алырлык та
Акча дигәне юк кесәдә.

Эш көненә тигән өлешләрне
Җиткераллмый үтте үзәкләр.
Өс-башларда – калдык иске-москы,
Яу өсте яу кұлмәкләр.

Алабута, кузгалак, кычыткан
Сөттә пешкән авыл ашын да.
Киемнәрдән бет яңгыры яуды,
Кыздырганда мунча ташында.

Бүлештегез, кайгы-хәсрәтләрне
Кич утырып, калып төннәрен.
Ир-атларның укып фронтлардан
Килгән, яхшы-яман хәбәрен.

II

Чыдаса да Кеше чыдар икән,
Тұзәр икән шундый тормышка.
Яртыавыл ачлык кочагында,
Әҗәл йөри очтан бер очка.

Аяк баскан, таяк тота алган,
Ашъяулыкка төреп булганын,
Сырхауларга җылы шулпа илтә,
Сөт-каймакның баздан алганын.

Син дә, Анам, күршең Әминәгә,
Алып кердең тары боткасы.
Мәрхәмәтлек, бер-береңә ярдәм,
Булды чорның тормыш тоткасы.

Син дә, Анам, йөрәк-җан җылыңны
Нәүмизләргә юмарт өләштең.
Үзең кебек, тол калганнар белән,
Әметле тел белән сөйләштең.

Кайдан килде сиңа мондый кодрәт?
Иңнәреңә илне күтәрдең.
Изге эш-гамәлләреңне күреп,
Рәхмәтләре иңде күкләрнең.

Язлар килде, кояш балкып көлде,
Инсаннарга шатлык өләште.
Бер иртәдә дөнья көлә-көлә,
Сихри яме белән бүлеште.

Сөенечтән энҗе кебек балкып,
Күз яшьләре акты бәйрәмдә.
Бүгенгеләр кебек кермәдең син
Кеше өлешенә, хәрәмгә.

Синең кебек изге Аналарга
Алтыннардан һәйкәл куярлык.
Ә син бүген – бер кадерсез карчык,
Икмәкгең юк тамак ялгарлык.

Хөкүмәтнең «Онытмадык!» – дигән,
Шигаре дә ялган сүз булды.
Үлемтеккә җыйган көмешеңне
Тартып алды, җилгә очырды.

Габдуллаңнан калган киемнәрне
Ялгый-ямый гомер итәсең.
Гадәтеңчә, тыныч, сабыр гына,
Шыпырт кына әҗәл көтәсең.

III

Сөт, йомырка, ипи, бәрәңгене
Ашың итеп гомер кичердең.
«Уфалла»ңны тартып, утын, печән,
Башка кирәгеңне китердең.

Ач булсаң да, салым түләттеләр,
Йомыркасын, йонын өйдереп.
Үзең капмый, ул үстердең сөеп,
Кырык җамау ыштан кидереп.

Бәхет эзләп, киләчәген күзләп,
Улың китте шахта – Донбаска.
Көч-гайрәте булган яшь егеткә
Нигә акча эшләп алмаска?

Тик син көткән, заргып, өмет иткән,
Бәхет тәтемәде: аяныч.
Картлыгыңда улың, оныкларың
Булалмады сиңа таяныч.

Улың гына түгел, күпләр шулай
Офыкларга карап юл чыкты.
Тик кубесе хәмер дәрьясында,
Маржа кочагында тончыкты.

Тәүфыйкь китә икән – аерылсаң,
Бисмиллалы анаң ашыннан.
Кайгы йөрми агач башларыннан,
Кайгы йөри адәм башыннан.

Алыштырсаң, әгәр сатсаң динең,
Гореф-гадәт, ислам йоласын.
Үз анаңны, туган телне җуйсаң,
Чит-ятларга кадер кыласың.

Балаң кылган гөнаһ-хаталарны
Баш орсаң да буллый төзәтеп.
Язмышларны Аллаһ хәл итсә дә,
Тормышыңны була үзгәртеп.

Табигать тә гел үзгәреп тора...
Кыш үтүгә, ямьле яз килә.
Табигатьнең кеше – асыл заты,
Кануннарын аның ул белә.

Ата-ана фатыйхасын алган
Гаиләләрдә иман терәге.
Сәрхүш баштан кушылганнарның тик
Җимерелә нәсел терәве.

Хат язмады улың бер тапкыр да,
Күңтәнәч тә сиңа салмады.
Шахталарга төшеп вафат булды,
Аны Алла шулай каргады.

IV

Сөялгән дә карчык җил капкага,
Терәп куйган җиргә таягын.
Әйтерсең лә беренче кат күрә,
Хәйран калып күзли як-ягын.

Йа, Илаһым, нинди гаҗәп дөньяң!
Гәр тарафта камил төгәллек.
Акыл җитмәс серле бу дөньяңда,
Төгәллектә икән гүзәллек.

Җисемнәрнең Галәм хәрәкәте
Арасына кыл да сыймаслык.
Табигатьнең тиңсез могҗизасын
Бер күрүе үзе зур шатлык.

Өй түрендә шомырт чәчәк аткан,
Карчык белән бергә картайган.
Киртә буйлап үскән кычытканнар,
Тирә-якта үлән буй алган.

Язгы шаян, иркә, җылы нурлар
Куеннарга кереп оялый.
Шифа биреп тән, күзәнәкләргә,
Тамырларда йөреп дәвалый.

Күпме газап чигеп көн итсәң дә,
Картайсаң да, килә торасы.
Бар тереклек Җир-Анага гашыйк,
Дөнья үзе тылсым оясы.

Хәйран калып басып тора Ана –
Кешелеккә дәвам бирүче.
Җиргә хуҗа итеп җибәрелгән,
Аллаһының мәгърүр илчесе.

Басып тора илгә ир, ул биргән
Ихтирамга лаек гали зат.
Акыл-фигыль, гүзәллекне аңа
Мөлдерәмә биргән табигать.

Инде саулык, көч-куәте дә ким,
Буй-сыны да калган бөрешеп.
Намаз саен мең рәхмәтләр әйтә,
Булган кадәренә килешеп.

Шөкерана кыла яшәвенә,
Таласа да үзен мең сырхау.
Бүгенгедәй гүзәл ал таңнарны
Өлмет бирә күрү, җан чыкмау.

Ире, улы чыккан бусагалар
Ишегалды якка чүккәннәр.
Таягына ауган хуҗасы күк,
Каралтылар тузып беткәннәр.

V

Хәбибҗамал карчык үткәннәрне
Кабат-кабат барлап күңлендә,
Ничәнче кат хәтер катламнарын
Әйләндерә йөрәк түрендә.

Әнә, алар Габдулласы белән
Тормыш башлый сыңар кашыктан.
Көзен мунча кадәр йорт коралар,
Эш көненә тигән ашлыктан.

Габдулласы — дан балта остасы,
Йортлар салды, илгә ялланып.
Үзе чүвәк, читек-кәвеш текте,
Өч-дүрт сәгать төнгә ял алып.

Тырыш табар, ташка кадак кагар,
Калкып чыкты күркәм яңа йорт.
Яңа йортның күрке булсын дисәң,
Нәсел агачыңны син утырт.

Көнләшепме нәни шул бәхеттән?
Илдә купты сугыш афәте.
Туган җирне, мәхәббәтне яклау —
Ир-атларның асыл нәүбәте.

Урамнарны урап бәхилләште,
Саубуллашты гаярь ир-затлар.
Үзәк өзгеч аһәң, җыр-моңнардан
Тетрәнеп куйды пар атлар.

Габдулласы, тальян гармун уйнап,
Уртасында булды арбаның.
Иңнәреннән кочаклашкан ирләр
Тирәннәрен салды яраның.

Сагыш тулы ярсу җан җырлары
Бәгырьләргә керде уелып.
Кочактагы имчәк балалар да
Шиңгән гөлдәй калды боегып.

Төсе булып тик гарморуны калды,
Җылы куенында – баласы.
Ирен, улын югалтудан алган
Әрнеп торган йөрәк ярасы.

Ирсез калды, газиз улсыз калды,
Илкәеннән нәрсә, ни алды?
Чит җирләрдә ирләр туфрак булды,
Нәсел-нәсәбәләр югалды.

Җиргә килеп, үксез ялгыз торып,
Күрде нинди тормыш рәхәтен?
Көнне төнгә ялгап эшләсә дә,
Ишетмәде иле рәхмәтен.

И син, Ана, хәйлә, мәкер күрдең,
Белдең ирең, улың әҗәлен,
Хәләл ризык ашап гомер иттең,
Бирсен Алла савап, әҗерен.

Моң

(Трагик ода)

Гәр тарафтан татар моңы ташый –
Ерак гасырларның тавышы.
Шушы аваз, шушы моңлы аһәң
Татарымның тормыш агышы.

Татар моңы телә бәгырьләрне,
Үзәкләрне өзә таңнарда.
Сагыш ташый, өмет хыял ташый,
Ярсу хисләр ташый аңарда.

«Кара да гына урман, караңгы төн
Яхшы атлар кирәк лә үтәргә.
Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк гомер итәргә».

Яхшы атлар, дус-иш кирәк булган
Дөнья көтәр өчен бабама.
Тормышлары – кара урман сыман,
Кайсы гына чорны карама.

Сыенган да урман куенына,
Ут тергезеп, гомер кичергән.
Кичке учак ялкынына карап,
Аһ-зарларын моңга күчергән.

Тирән, тиңсез моң сагышы аша
Оныкларга гыйбрәт сөйләгән.
Утта янган данлы Идел-йортын
Үҗәтләнеп кат-кат сипләгән.

Ач бүредәй кансыз, явыз дошман
Янә килеп, Илне туздырган.
Халкын, хәтта сабыена кадәр,
Канлы кылыч аша уздырган.

Күз алдымнан үтә бабамнарның
Кан-яшь түккән мәхшәр заманы.
Ыңгырашып ауган манаралар,
Тынып калган җомга азаны.

Ил күкрәген кылыч ярып үткән,
Илбасарның тәре кулында.
«Лә иләһә илләлаһу» – диеп,
Васыять әйтә ата улына.

Татар иле алсу шәфәкъ төстә.
Илбасарның кулы пәкедә.
Чукынмаган ата-аналарны,
Балаларны тынчый бәкедә.

Туган белән туган якалаша
Бер-беренә ядрә, үк атып.
Татарымның көнчел-хөсетлеге
Ханлыкларны китте таратып.

Төтен, сөрем, янгын эчләреннән
Ишетелә бала тавышы.
Богауларны өзеп, азат итәр
Көч-кодрәтле вакыт агышы.

Һәр тарафтан татар моңы ташый.
Җыр-моңнарда сагыш, ут, көрәш.
Бугазымда чорлар зар-газабы,
Күзләремдә мөлдерәмә яшь.

Әрвахларның җәрәхәтле җаны
Укси сыман моңга кушылып.
Бәддогасы ташый илбасарга,
Рәнҗү-каргыш ташый моң булып.

Ассалар да аны, киссәләр дә,
Иманында калган чын татар.
Гаделлекне даулап зур көрәшкә,
Баскан татар өчен таң атар!

Һәр тарафтан татар моңы ташый —
Аерылганның ачы язмышы.
Бүленгәннең бүре арасында
Койрык кысып гомер узмышы.

Улы-кызы тол анасын ташлап,
Читкә киткән, чыкса бер җае.
Икмәк эзләп шахталарга җиткән
Ач-ялангач татар малае.

«Шахтер егет күмер кисә,
Кемнәр ала исәбен?
Гомерем бетеп, таш басмаса,
Ташламам җан кисәгем».

Донбассларда кыйбла югалтканның
Кемнәр алыр икән исәбен?
Маржа кочагында шыңшый-шыңшый,
Көчек булган татар кисәген?

Киллмешәккә калган гореф-гадәт,
Иман-әхлак, эреп югалган.
Үзен Гена иткән Габдуллажан,
Балалары урыс саналган.

Чучка белән хәмер буталганнан
Манкорт дигән бәндә яралды.
Ике арада калган буфер татар
Кара күмер сымак каралды.

Кылган гөнаһ, ялгыш-хаталарны
Сылтап булыр иде заманга,
Гәммәсенә, имеш, чор гаепле,
Шул аклану бездә һаман да.

Тик берәү дә сырлы стаканнан
Авызларга хәмер салмады.
Шайтан коткысына бирелгәннәр
Упкыннарга таба атлады.

Мөлдерәмә күз яшьләрем аша
Үткәннәрне барлыйм сискәнеп.
Ачлы-туклы ятим бала чагым,
Йөргәннәрем эттәй иснәнеп.

Язмыш безнең баштан сыйпамады
Иңгә салды тормыш тәртәсен.
Бала чактан авыр камыт киеп,
Башладык без гомер иртәсен.

Чүл-далада үскән лалә кебек,
Кечкенәдән шиңдек, бөрешмәк.
Бәхетсезлек, кара сакал булды,
Ялган белән һәрчак күрешмәк.

Илнең гигант төзелешләрен иңләп
Күп чөмердек «Лаеш шулпасы»н.
Тапканнарны каптык күмәкләшеп,
Кыерсытмый урыс йоласын.

Алдау-йолдау, ялган, буш вәгъдәләр
Татар балаларын таратты.
Дала кылганыдай сөрелгәннәр,
Себер китеп башын югалтты.

Һәр тарафтан татар моңы ташый,
Урыс җырлый татар җырына:
«Утыр әле яннарыма,
Ял булсын җаннарыма».

Шешә тотып җырлый, биш торгач,
Якынайтты җанга араны, —
Йомшак җәеп урыс катысына
Утырттылар мескен татарны.

Ир-егетләр маржа кочагында,
Урыс цбә татар чибәрен.
Ата-улны, ана-кызны белми,
Тоймый татар гүргә кергәнен.

Манкорт татар бүген табан ялый,
Мулла белән мулла чәкәшә.
Татар йөзле егет-кызларыбыз
Чит-ятларга токым өләшә.

Күпме кияү, күпме килен өчен
Сукыр тиен милләт кыйммәте.
Тәре таккан кяфер кочагында
Гарипләнә ислам өммәте.

Туй ясаган йөзнең кырык дүрте
Кушылганга башка милләткә.
Милли хисе, милли горурлыгы
Җилгә оча — каллый илəктə.

Чит-ятларга күркәм кырык дүрт пар —
Алар мәллә сөю әсбабы?
Бүгенгенең Камай, Шаһгалие
Бетсен диме татар нәсәбе?

Милләтенә, үз-үзенә хөрмәт
Чик юк безнең Галәм, Галиядә?
Үз кыйбласын гомер таптаячак
Гибрид үсә катнаш гаиләдә.

Гибрид егет, гибрид кыз баланың
Богы да юк, юктыр Алласы.
Денсез-динсез, Коръән һәм Инҗилсез
Гыйффрит иле – Урыс дөньясы.

Аен җуйган бисмилласыз татар
Көнем өчен диеп көн күрә.
Эттән туган бүре балаларын
Эт үз итми, бүре ят күрә.

Мин – фәкыйрең, булам дәң әтисе
Төссез, хиссез шушы токымның.
Урыс телле шушы корбан токым
Нурын куа ата йортының...

Киленнәрем кяфер, оныкларым –
Бисмилласыз татар барысы да.
Иа Аллаһым, ни дип җавап бирим,
Хозурыңа баргач, каршыңа?

Ни дип җавап бирим кылыч аша
Шәһит киткән бабам рухына?
Милли хис вә милли горурлык бир,
Урыс телле кызым, улыма.

Иман бирсен Аллам онытма,
Кул күтәреп дога укырлык.
«Монда минем дәү әтием», – диеп,
Каберемә зират кылырлык.

И татарым, җиләр кан алмашу,
Урыс булуыңда ни мәгънә?
Теш ыржайту, талаш, кыйнаш, сугыш...
Шул булдымы милли хәзинә?

Гәр тарафтан татар моңы ташый –
Ерак гасырларның авазы.
Шушы аваз, шушы моңлы аһәң
Татарымның күңел, җан сазы.

Әле язгы ташкын булып ташый
Кырлар ята моңга төрелеп.
Әле иртәнге җил, талгын гына,
Назлый сыман биттән үрелеп.

Шау чәчәкле гүзәл иркен дала
Моңга сарган гүя кодрәтен.
Чуен койган болгар остасының
Җырлы иткән хәләл хезмәтен.

Илләр иңләп йөргән дәрвиш кебек
Җыр-моң сөйли вакыт агышын.
Дан-шөһрәтле олпат бабамнарның
Дошман белән билләр алышын.

Чын татарын сөя һәм иркәли
Тальян моңы, курай аһәңе.
Ул үзенчә сыный татарлыкны,
Татарына бирә бәһане.

Илаһи моң! Илһам, коч-кодрәтең
Рухи сафлык бирсен татарга.
Коръән, Иман белән култыклашып,
Насыйп булсын бергә атларга!

Йә, әйт, Хаким! Мондый илаһи моң,
Сихри моң бар кайсы милләттә?
Кайсы милләт үзен, моңын саклап,
Исән калган мең кат иләп тә!

Кайсы милләт күрше дәүләтләрен
Асыл ирләр белән ныгыткан?
Әнә шулар төркиләрнең башын
Урыстан да узып кырыккан.

Алтын-көмеш, бүләк, мал-мөлкәтләр
Гүшын алган сатлык затларның.
Дәүләтләрен килеп тар-мар иткән,
Сатлык улы шул үк татарның.

Каршы куйган патша милләтләрне,
Мөселманны берсен-берсенә.
Кардәш-ыруг кайсы башын салган
Гәм хыянәт иткән үзенә.

Бер ишләре динен, хак, намусын
Алыштырган урман, җир-суга.
Әйтерсең лә морза мохтаҗ, булган
Киң Урдада дала, басуга.

Аң-акылын, җирен, динен саткан,
Илен сатып, җанын саклаган.
Читтә абруй, шөһрәт казанса да,
Барыбер дә мәхлук саналган.

Шул гавәмнең бүген варислары
Кан койдыра, сала җәбергә.
«Без бүленмәс ватан – Рәсәй» – диеп,
Ил улларын кертә кабергә.

Котырынган явыз ярсый-ярсый
Афәт, үлем илтә барсына.
Бүгенгенең сатлык җаннары да
Халкын сата тамак хакына.

И татарым! Уйлап, тәвәккәллән
Кәһарманлык кыл бер үзеңә!
Хаталардан сабак, гыйбрәт алып,
Язмышыңны ал үз иңеңә.

Газиз халкым! Йөгең зур булса да,
Якын итмә ятлар арбасын!
Исеңдә тот: үрләр меңгән чакта,
Йөгең белән төшеп каласын.

Һәр тарафтан татар моңы ташый,
Киләчәккә әйдәп татарны.
Колшәрифләр, олуг Мөхәммәтләр
Яу алдыннан йоклап ятармы?!

И татарым! Ишәйт сафларыңны,
Карашыңны юнәлт кукләргә.
Көрәшләргә дәшкән моңың белән
Язгы кукрәү булып кукрәргә!

Җыры белән, дәртле моңы белән
Әби-бабам әйткән сәламен.
Оныкларга, гасырларга юллыйк
Әманәтле чорлар әләмен!

Ахирәткә* хат

(Поэма)

1. Әсәр башына дога

Бисмиллаһ-ир-рахман ир-рахим

Бу хат, бәлкем, анда барып җитмәс,
Тик шулай да, булдым язарга, –
Килер көннәр, шиксез, теләр безне
Чал тарихтан эзләп табарга.

Кайсы чорда, ничек яшәгәнбез,
Нинди хәлләр баштан үткәннәр?

Кемнәр соң без?! Һәм без нинди заттан –
Шул дәвердә гомер иткәннәр?

Таң җилләре белән ирешсеннәр
Безнең хисләр, безнең тойгылар, –
Барып җитсен хәбәр ахирәткә:
Кемнәр җуйды, кемнәр җыйдылар...

Безнең тормыш, бәлкем, сабак булыр
Хата-ялгышларга тарманска, -
Килер буыннарга гыйбрәт булыр
Ярык тагараклта калмаска...

Еллар буе хәләл хезмәт хакын
Ала аллый йөрдек интегеп.
Яшәмәсен, димен, килер буын
Тираннарга – бездәй бил бөгеп.

**Ахирәт – үлгәннән соң булачак теге дөнья.*

Бу дөньяга барлык җан иясе
Шыр ялангач туа анадан.
Җир-әнкәдә аның үз өлеше
Билгеләнгән тиңсез Алладан.

Һәркемнең дә хакка хокукы бар -
Артыгы да түгел, киме дә.
Мал-мөлкәтен, беләм, ахирәткә
Алып китә аллый беркем дә!

Данга-малга хуҗа байбәтчәләр
Халкын талый, бирми яшәргә.
Ил – җилкәнсез кораб: эшләр харап,
Чыга аллый ерак сәфәргә.

Эшсез-ашсыз калган илнең халкы
Тормыш сазлыгында чайкала.
Ач-ялангач гавам мәйданнарда
Хезмәт хакы даулап айкала.

Кайный халык базар казанында.
Бар кәсебе – нидер сатуда.
Тән сатыла монда, җан сатыла,
Бөтен гамәл – табыш алуда.

Юл буенда ярым шәрә калып,
Фәхишәләр баскан тезелеп.
Ундүрт яшьлек сәрхүш, наркоманнар
Клиентларны көтә өзелеп.

Юл читендә әнә карт ветеран
Хәер сорый, сузып кулларын.
Җем-җем итә орден-медальләре
Хәтерләтеп сугыш елларын...

Котырынып көн дә үскән бәя
Бугазыннан алды халыкның.
Шушы илгә хезмәт ит тә инде,
Бар михнәтен күр син картлыкның.

Бөлгенлеккә төшкән илнең халкы –
Яр читендә тора... яртылаш, -
Гәр тарафта каһәрләнгән язмыш -
Кыз яшьләре, каргыш, ыңгыраш.

Очын-очка ялгый алмаганның
Иңнәрендә – тормыш газабы.
Чиләкләрдә тормыш... Бу яшәүнең
Нәрсә белән бетәр азагы?

Үзен «бөек» диеп йөргән ил бу,
Ә халкымы? Ачтан интегә.
Фатирына тулы алмаганнар
Бомжлыкка чыга иртәгә.

«Акыл белән аңлап булмас ил»дә*
Ахмаклыклар кыла хакимлек.
Бәрәкәт һәм иман качкан моннан,
Үксеп-үксеп елый ятимлек.

---

*Тютчев сүзләренә ишарә («Россию умом не понять»).

Җәбер-золым, мәсхәрәгә калган
Кешеләрдә өмет өзелгән.
Кара каргыш төшкән шушы илме,
Сөяк өсләрендә төзелгән...

Кемнәр алар – юлын югалтканнар,
Милли фаҗигагә тарганнар –

Чит дәүләтнең гадәтләрен алып,
Ана телсез, өнсез калганнар.

Тарихларын, ата-бабаларын,
Нигә әле алар оныткан?
Изге динен, кыйбла югалтканнар
Коллык газабына юлыккан.

Алла каргадымы? Илнең халкы
Килеп керде шайтан туена.
Үзе дә бит урыс михнәт чигә,
Җәфа чигә гомер буена.

Советларда – «кухарка»лар булды,
Эш башында хәзер – уллары.
Берөзлексез реформалар талкый,
Тик билгесез барыр юллары.

Олигарх – комсыз... Илне талый,
Чиновниктан хәтта уздырып.
Ил байлыгын үз байлыгы итә,
Чит банкка куя яздырып.

Өметләре сүнгән кешеләрне
Битарафлык алган уратып.
Көне-төне ул тамаша карый,
Шамакайлык үрчи җайлашып.

Концертларда ир «хатын-кыз» чыга,
Ялган күкрәк элеп түшенә.

Маймыллану, шайтан булып уйнау
Берни түгел ир-ат кешегә.

Әхлаксызлык, әдәп тәрбиясезлек
Чолгап алды бөтен дөньяны.
Җир-әнкәбез елый, күкләр сыкрый, -
Афәт булып килде зыяны.

Цунамидан, җилле давыллардан,
Гәлакәттән Аллам сакласын!
Ачы язмышларның кочагында
Ил-җиребез инде калмасын.

Әнә, көчле диңгез дулкыннары
Котырынып бәрә ян-якка.
Беллибезме?! – Зур һәлакәт яный
Бер урында торган корабка.

Хак Тәгалә тузан бөртегеннән
Без яшәгән җирне яралткан.
Җисемнәрнең хәрәкәтен җайлап,
Бер-беренә бәйләп җеп аткан.

Көн күрергә кояш кабызган ул,
Төн йөрергә айны калкыткан.
Биниһая йолдызларын сибеп,
Чиксез галәмнәрне яктырткан.

Җир-әнкәне кече җәннәт иткән,
Чәчеп анда мең-мең үсемлек.

Хисабы юк җанвар-җәнлекләрнең,
Кош-кортларга биргән тереклек.

Адәм затын ипләп иҗат иткән, -
Мәхәббәткә төреп «әсәр»ен.
Һәм җан өргән, яшәү асылы биргән –
Мал-мөлкәтле итеп яшәрен.

Ләкин әдәм һаман туя белми,
Нәфес җене аңа уелган!
Ләкин тормыш кануннары кырыс,
Нәфескә дә чикләр куелган...

Вәсвәсәдән өстен кал син, Кешем,
Коръән белән һәрчак бергә бул, -
Ахирәткә көчләп чакырмыйлар,
Ул – бердәнбер туры, тугры юл...

Тышауларны үзәр өчен тудык,
Без чабабыз тормыш атында!
Дөньялыкта – яшәү мәгънәсе бар,
Безнең уйлар – шулар хакында...

2. Син кем идең?..

Мәрхүмнәргә тел тидермә, диләр.
Читкә китмим шушы йоладан, -
Үбнаһларың ярлыкауны сорап,
Калдырмыймын сине догадан.

Миңа, бәлки, үткәннәрне бакмый,
Берни әйтми синең хакыңда, –
Яшәү тиеш... Син бик ерак миннән,
Сын-сурәтең әмма якында!

Кирәктер дә дәшмәү... Тик бәгырьдә
Яраларның тынмый сызлавы.
Күңелемне борчый, җанны талый
Сорауларга җавап булмавы.

Нишләп болай чәлпәрәмә килде
Җай башланган безнең тормышлар?
Юлыбыз да сикәлтәсез иде,
Кайдан, нидән булды ялгышлар?

Сорау арты сорау талкый мине,
Узганнарны күздән кичерәм.
Әйтерсең, мин – «вакыт машинасы»,
Үткәннәргә кат-кат күченәм.

Җил исмичә яфрак селкенмидер,
Болыт йөзми җилләр кумаса.
Тиктомалдан йөрәк үрсәләнми,
Борчылырлык сәбәп булмаса.

Вакытында әгәр утамасаң,
Бакчаны да котсыз чүп баса;
Күркәм гадәт, әдәп тәрбиясе
Бала чактан җанда булмаса.

Табалмассың, димәк, уңган кәләш,
Әкияттәге кебек, ук атып.
Җәясеннән бер ычкынып китсә,
Язмыш угын буллмый туктатып!

Чик кешеләр – акыл ияләре –
Гыйбрәт аллмый икән үткәннән?
Ата-бабасының хаталары
Кабатлана «киребеткән»нән.

Көтү башы сикереп үтсә әгәр
Җирдә яткан берәр таякны.
Арттагылар, таяк буллмаса да
Кабатлыйлар шул ук «трюк»ны.

Бу дөньяга туган һәрбер буын,
Алып килә үзгә яңаны.
Ул үзенчә тормыш кора башлый,
Бутап бик еш яхшы-яманны.

Кеше үзе утны-суны кичми,
Акыл керми аңа йөдәтә.
Ләкин тормыш кануннары кырыс, -
Сынауларын биреп өйрәтә.

Чүп үләннәр кайчак басып китә
Шаулап үскән иген кырларын.
Тарих белә кешеләрнең ничек
Яшәгәнен... һәм кырылганын.

Таяк тотып аягына баскан
Адәми зат күккә караган...
Җиргә-сугa, чиксез Галәмнәргә
Хуҗа булырлыгын аңлаган.

Син дә минем җилсу вакытымда
Килеп кердең җанга очынып!..
Яшәп киттек, хәят кырларына
Ике балабызны очырып...

***

...Акча боза адәм балаларын,
Ә ул синдә – булды санаусыз.
Төнге сменада ирләр белән,
Буфетыңда калдың караусыз.

Ир-атларның татлы сүзләреннән
Чичек шулай башың әйләнде?
Бәйрәмме соң тормыш? Әллә инде
Ямьсез буталышлар бәйләме?

Башка эшкә сине димләсәм дә,
Ниятләрем терәк тапмады.
Ашханәне җитәкләгән ирләр,
Аяк терәп сине яклады.

«Бер хатасыз кеше юктыр, – имеш, -
Без канәгать аның эшеннән...»
– Аерылсам синнән – аерылам,
Аерылмыйм, – дидең, – эшемнән.

Өзгәләнеп әйткән сүзләремә,
Үзеремә исең китмәде.
Хыянәт һәм хәмер төеннәрен
Өзгәләргә тешем үтмәде!

Чибәр идең! Йөзең балкып тора.
Җем-җем итә иде тешләрең...
Буең-сының коеп куйган кебек,
Уңай бара иде эшләрең.

Кем нәфесен тыеп кала алсын,
Табындагы татлы җимештән! -
Бәйрәмнәрдә зур-зур тирәләр дә
Авыз иткән синең «өлеш»тән.

Югыйсә бит, мин дә дәрәҗәле,
Ихтирамга лаек ир идем, -
Йолдызларга буем җитмәсә дә,
Башкалардан юктыр ким җирем.

Тиңгел идем төшеп калганнардан,
Җилләр куып йөргән бер надан.
Ярлар сөеп, шәхси тормышымны
Башлый ала идем яңадан...

Бу гамәлне, беткә ачу итеп,
Тунны ягу итеп карадым.
Акылыңа килеп, асылыңа
Кайтасыңа өмет багладым.

Чөнки җилгә каршы төкерүләр
Үз битеңә килеп сылана.
Үз хатынын кулда тоталмаган,
Ир гаепле булып санала.

Безнең гаеп ике якта булды,
Гөнаһлымын Аллаһ каршында.
...Әрнеп, сыкрап, сиднән гафу сорап,
Басып торам кабрең каршында.

Йа, Аллаһым, бәндәң Саниянең
Хата-гөнаһларын ярлыка!
Унике ел намаз калдырмады,
Тәүбә итте, барды Хаҗ якка.

«Үткән эшкә салават», – ди халык,
Тайпылмыйча шушы йоладан.
Җәннәтләрдә булуыңны сорап,
Калдырмыймын көн дә догадан.

Син идеңме минем мәхәббәтем,
Син идеңме яшьлек сердәшем?
Мин юксынып һәм сагынып сине,
Әрнеп-сыкрап яшим, мин ятим...

3. Үткәннәрдән кыйтга...

Үткәннәргә әгәр күз ташласам,
Бугазыма төер тыгыла.
Йөрәгемне нидер әчеттереп,
Тырнап үтә, тыным кысыла.

Гомеремнең чәчәк аткан чоры
Хатын назы күрми бөреште.
Уллар үсте... Әле ярый алар
Әниләрне бергә бүлеште.

Сагышлардан, сине юксынудан
Тонykланды кебек күзләре.
Уйнап-көлеп йөргән булсалар да,
Борчу япкан иде йөзләрен.

Әле ярый, үсте безнең уллар,
Китермичә йөзгә кызыллык.
Дәү әниләренең тәрбиясе
Нигез булды чын ир булырлык

Аллаһ миңа мәрхәмәтлек салды,
Изгелекнең бирде олысын, –
Соңгы сулышыңа кадәр сиңа
Бирә алдым күңел җылысын.

Сеңлең Зәйтүнәгә әйткәнсең ич:
«Бик үкенәм, – диеп, – бүлмышка.
Рәхмәт инде, Рәис ташламады,
Ул кайтарды юньле тормышка».

Кабат сине Ана кеше итеп,
Хөрмәт иттек, ихлас яраттык.
Тормыш учагын без өр-яңадан
Оныкларны сөеп яңарттык.

Рәхмәт сиңа, соңгы дистә елың
Намаз укып үтте, тәүбәдә.
Вазифаңны күркәм тота белдең,
Эшләсәң дә шул ук сәүдәдә.

Ләкин миндә ике «мин» яшидер,
Берсе сине ихлас ярата.
Икенчесе бәгыремне ерта
Йөрәк яраларын яңарта.

Гомер буе шулай ут белән су
Алмаш-тилмәш кайный җанымда.
Гомер буе газап чигәчәкмен
Бу тәнемдә җаным барында.

Нинди гөнаһ шомлыклары өчен
Җәза алдым соң мин язмыштан?
Тик Аллаһның тиңсез шәфкатьлеге
Саклап калды хата кылмыштан.

Бәгыремне телгән җәрәхәтләр
Йомылса да, җөе калса да,
Вакыт-вакыт искә төшергәләп,
Сыкрап куйса, кадап алса да...

Илаһи көч җанга нур бөркеде,
Күңелемә инде сабырлык.
Хаталарның хакын тиләр өчен
Тәүге никахың да калырлык!

Тик сөекле бәндәсенә Аллаһ
Сынауларның бирә һәр төрен.
Иланһи хис булган мәхәббәтнең
Ғелмәс идек, юкса кадерен.

Ғалаларга син дә тансык әни,
Дәү әнисе... инде ұлсәң дә.
Ғалкып торган йөзле, киң күңелле
Ғулып калдың алар күңелендә.

Син идеңме минем мәхәббәтем?!
Искә алам, назлап исмеңне.
Яшьлегемә кайтсам, мең гөнаһтан
Йолып алыр идем үзеңне!..

4. Ә күрешсәк әгәр...

Мәрхүм кем һәм нинди булмасын ки,
Ғадәттә ул яхшы шәйләнә.
Ғомер үтү белән тираннар да
Әүлия бер затка әйләнә.

Аның белән бер күрешер өчен
Ғомереңне бирер буласың.
Аллаһ рәхмәт кылса, җәннәтендә
Күрешергә өмет корасың.

Ә очрашсак?.. Чинди кыяфәттә
Ғулыр икән җан һәм тәнебез?
Ғулырбызмы ит һәм сөяктән без,
Бер-беребезне ничек белербез?

Еллар үтеп, үзгәрешеп бетеп
Танымаслык буллмыйк әле дә.
«Теге очлар «бу очныкылар»ны
Белешмиләр хәзер Шәледә.

Искә төшә янә айлы төннәр,
Синең белән булган яшь чаклар.
Чуерташ күк шома тәннәреңнән
Таеп китә иде бармаклар!..

Бит уртаңда балкып торган миңең
Калды микән һаман сакланып?
Әсир иткән зәңгәр күзләреңә
Карар идем мәңге сокланып.

Исән чакта җаның сөйгәннәрнең
Кадерләрен белми яшисең.
Уч төбендә йөртер идең дә бит...
Эш узган шул инде, нишлисең?!

Мәрхүмнәргә дога багышлыйбыз...
Алар, ләкин, безгә эндәшмәс.
Искә алу... Корбан чалулар да
Хәтер белән һич тә тиңләшмәс.

Хак Тәгалә үз җаныннан бүлеп,
Адәм баласына җан өрә.
Кылынган һәр эш-гамәлләреңне
Үз бизмәне аша үткәрә.

Мәгълүм Аңа тойгы-хисләребез,
Уйларның да яхшы, яманы.
Тыкмы-чәчмы кукләр теркәп куя
Гамәл дәфтәреңә аларны.

Тик алар да инде ябылгандыр,
Хәбәрсездер савап, гөнаһтан.
Ярлыкауны гөнаһ-хаталарны
Сорау бездән тик бер Аллаһтан.

Көч-кодрәтле, тиңдәше юк Аллаһ...
Гәм дә җаннар безнең мәңгелек.
Адәменә үзеннән җан өргән
Бөек затта чиксез изгелек!

Игелекле гамәл тик – Аныкы,
Начарлары – иблис кулында.
Ата – улын, ана – кызын белмәс
Дәһриләрнең шайтан туенда.

Анда тәртип, күркәм гадәтләр юк,
Хәмер хуҗа, хәмер – тамада.
Исерешеп, ярым шәрә калган
Фәхишәләр «чыжлый» табада.

– Әче-әче! – диеп кычкыралар,
Әхлаксызлык шуннан башлана.
Үбешүнең санын җуйган табын
Ялашырга үзе ташлана.

Яман гадәт, азгын уй-теләкнең
Юк ахыры бүген, юк чиге.
Совет заманнары сәрхүшлеге -
Бу заманның бары «көчеге!»

Чүпкә дә ул безне санамады,
Тәкәбберле иде колачы, -
Кешеләрне «винтик» урынына
Борып йөртте Совет влачы...

Алласызлык, денсез-динсезлектә
Хөкүмәтнең булды терәге.
Җитмеш өч ел илне айкый-чайкый
Йөрде коммунизм өрәге.

***

Айлар буе өйгә кайтмый йөрдең,
Алып кайтсак, качтың иртәсен.
Ата-анаң елый-елый әйтте
Азгын юлның кая илтәсен.

Чичек кенә үгет-нәсыйхәтләп,
Өндәсәк тә хәләл ризыкка.
Ә син һаман шул хәмер тугланган -
Ашкындың ич хәрәм табакка.

Ике улың, күз яшьләрен түгеп,
«Әни, китмә!» – диеп үтенде.
Ә син киттең, безне нәүмиз иттең,
Күңелләрнең чите кителде.

Ни гаебе булды балаларның?
Укыдылар яхшы, тәртипле.
Әйбәт ана булсаң, өйдә торсаң,
Булыр иде алар бәхетле.

Балаларны ятим итмим, диеп,
Таралышмыйк, диеп, як-якка.
Син теләгән эштә эшләтергә
Риза булган идем ул чакта.

Безнең ихлас изге уй-ниятләр
Чәлпәрәмә килде һаман да.
Кая гына эшкә керешсәң дә,
Гамәлләрең булды яманда.

Гомереңнең асыл вакытлары
Сукбайлыкта йөреп үтте бит.
Хәмер пары, уенчыктай итеп,
Кулдан-кулга сине йөртте бит...

Яшәр йортың ташлап, безне ташлап,
Син бәхетне читтән эзләдең, -
Булганына шөкерана кылып,
Ипләп кенә яши белмәдең.

Үзең кебек сәрхүш калдыгыннан
Урам эте кебек кыйналдың.
Әүмәкләшеп шулар өерендә
Адәм көлкесенә син калдың.

Михнәт чиктең, ачлы-туклы йөрдең,
Җир-әнкәгә килеп кунакка.
Нинди явыз көчләр этәрделәр
Еллар буе «бомж» буллмакка?

Гомер буе тынгы бирми сорау:
Ни-нәрсәдән ачы ялгыштың?
Ятьнәп торган күркәм гаиләне
Хәмер сазлыгына алыштың?

Ни эзләдең, ни җитмәде сиңа?
Бер кайттың да, әле бер киттең.
Гаепсезгә миңа яла ягып,
Сәрхүшлекне һаман иш иттең.

Кирелегең, юләр цҗәтлегең
Өзгәләде безнең бәгырьне.
Синең өчен буфет чумарасы,
Хәрәм акча булды кадерле.

Кемдер акча вәсвәсәсе, дияр,
(Юк, акчага яклыйм гаепне!)
Хатын-кызның түбән төшцендә
Ихтыярсыз ирләр гаепле!

Шушы ахмак хаталарым өчен
Гафу итә алмыйм цземне.
Чик алмадым сине кочагыма,
Сабыр булып, җыеп түземне.

Хатын-кыз ул – ургып аккан елга.
Язгы ташкын сыман кайчакта.
Аның шашкын күңел дулкыннарын
Тыеп була бары кочакта.

Ир-ат булып, яхшы ир-ат булып
Ир үтәсен ирлек хезмәтен.
Мәхәббәттән, наздан аермасын
Хатын дигән Аллаһ нигъмәтен!

Бер нәрсә дә үтми эзсез генә,
Барыбызга җитте афәте:
Хәсрәтеннән шашкан әниеңнең
Фаҗигале булды вафаты.

* * *

Гомер көзең җитми киттең
Кире кайтып булмас җирләргә.
Вафат булганнарны ямьсез итеп
Кирәкмидер, бәлки, сөйләргә.

Тик хурлыклы бу хәлләрнең эзе
Күңелләрдә калды уелып.
Йөрәктәге тирән яраларның
Әрнүләре тормый тыелып.

Ул һаман да сызлый, җәрәхәте
Гомергә дә, ахры, йомылмас.
Нәсел йөзендәге бу кара тап
Һич җуелмас инде, җуелмас...

Нинди зәхмәт чире йокты сиңа? -
Сәбәпләрен безгә әйтмәдең.
Башка эшкә сине димләсәм дә,
Шул сәүдәдән ләкин китмәдең.

Югыйсә бит, син – сөекле ана...
Хатын булдың миңа бердәнбер.
Өйдә үзең хуҗабикә идең,
Ошамады болар нигәдер.

Тормышыбыз җайга салынганда,
Көйле генә барган чагында...
Күз тидерткән сабый бала кебек,
Туздырдың да аттың барын да.

Көтмәгәндә үзгәрдең дә куйдың,
Өйгә саллмыш кайта башладың.
Бәйрәмнәрдә эштә кунып калдың,
Тора-бара безне ташладың.

Мин дә читкә киттем, күреп синең
Сәрхүшлектән шешкән йөзеңне.
Дисәләр дә: «Бөкре төзәлми», дип,
Гаепле дип саныйм үземне.

Сизеп юри читләшкәннәремне,
Син дә бездән һаман читләштең.
Чик-аралар ераклашкан саен,
Ачу итеп эчтең, үләштең.

Кирәк булган... Ләкин бик соң инде,
Үткәннәрне буллмый кайтарып.
(Бу дөньяда беркем үкенмәстер
Минем кебек, ташка баш орып).

Шушы ахмак хаталарым өчен
Гафу итә аллыйм үземне.
Чик алмадым сине кочагыма,
Сабыр булып, җыеп түземне.

Хатын-кызлар хис-тойгыда яши,
Үй ташкыны кич тә, иртә дә.
Чалуларда чана мәтәлдә -
Гаепледер ат та, тәртә дә.

Сәрхүшлектән, мәгънәсез тормыштан
Оныкларны Алла сакласын, -
Якласын Ул. Чәсел ишекләрен
Хәмер зәхмәтләре какласын!

* * *

Син идеңме минем мәхәббәтем?!
Син языммы минем, көземме?
Үткәннәргә кайтсам, синең өчен
Мин гаепле саныйм үземне.

Бер күрешсәк әгәр... Әй, күрешсәк! -
Телләремдә назлап исемеңне,
Туган якның яшьлек тугаена
Урлап китәр идем үзеңне.

5. Шушы болын, шушы кырларда...

Сугыш чорын кичкән яшүсмерләр
Һәм балалар иркә белмәде.
Балачакның назлы йокысында
Татлы төшләр безгә кермәде.

Җиде-сигез яшьтән, таңнан торып,
Зурлар белән эшкә керештек.
Шул заманның барлык мәшәкатен,
Авырлыгын уртак бүлештек.

Ундүрт-унбиш яшьлек үсмерләрнең
Язын, кышын, җәен, көзендә.
Басуларны сөреп, чәчеп-урып...
Көн-төн үтте колхоз эшендә.

Сука тарталмаган арык атка
Камчы белән алдык сыдырып.
Түбә саламыннан «гарык» атлар
Хәлсезлектән яттылар сузылып.

Әнә язның үзле пычрагына
Кереп баткан арба көпчәге.
Агай атын шашынып каезлый,
Ат сыртында уйный күсәге.

Дүрт аягын терәп көчәнсә дә,
Йөкле арба тирән утырган.
Тиргә баткан атның арык тәне
Җәя кылларыдай тартылган...

Киерелеп янә ул ыргылды,
Ал аякларына тезләнеп.
Пар бөркелә, тәне дер калтырый,
Газапларга, ахры, тұзмәде.

Келтә кебек, мескен, җиргә ауды,
Күз яшьләре ага мөлдерәп.
Тәртә арасында елап яткан
Атны чыгардылар өстерәп.

Күтәрәмгә калган корчаңгы ат
Җан көченә тартты арбаны.
Кеше белән иңне-иңгә куеп,
Янәшәдә атлап барганы...

Газапларын сугыш елларының
Аң-акылга буллмый сыйдырып.
Игелекле, тугры ул атларга
Алтын һәйкәл салыйк, койдырып.

Син дә күрдең авыр бу хәлләрне,
Син дә булдың заман баласы.
Кан, яшь белән узган ул елларның
Бәгырьләрдә калды ярасы.

Апаларың белән син үзең дә
Печән җыйдың кысыр басудан.
Көянтәңдәй үзең дугаландың -
Иңнәреңне йөгең басудан.

Алып кайткан синең бәйләмнәрне
Чак күтәрә иде әтиең.
Юкса әле буыннарың көчсез,
Талчыбыктай сыек син идең.

Басуларның тырпа камыллары
Табаннарга кереп кадала.
Чебиләгән аяк битләреннән
Бөрчек-бөрчек булып кан ага...

Үсәр иде иген кырларында
Төркем-төркем булып чәчкәләр.
Таҗларына кунып тибрәнделәр
«Тәмле тамак» – барча бөҗәкләр.

Һаваларда канат җилпәүләре
Ишетелеп торды гөж килеп.
Кояш нурларыннан куәт алган
Тук башаклар төште иелеп.

Басу өстен салават күперелдәй
Төскә бизәп рәшә тибрәнә.
Аллы-гөлле кояш нурларыннан
Әкияти сынга әйләнә.

Унбер бала, унбер бертуган сез,
Алтынчысы булып син үстең.
Тапмаган да булыр иде анаң...
(Үзәкләрен аның син өздең).

Теле белән кеше әйтмәсә дә,
Тыя аллас күңел рәнҗүен.
Дөньялыкта назга мохтаҗ анаң
Ахирәттә күрсен әҗерен.

Шәле* болынының чәчкәләрен
Такыялар итеп үрдәң син.
Өзеп алган чәчкәләрең кебек,
Балкыдың да... Ышнәп сүндең син.

*Шәле – Питрәч районындагы авыл.

6. Язмыш хөкеме

Якын дуслар миңа, көтмәгәндә,
Суд буласын хәбәр иттеләр.
Мин теләсәм, мин хәл итсәм әгәр,
«Эш»не ябачакны әйттеләр.

Ике утның уртасында калдым,
Икесе дә җанны өтәли:
«Төрмәдә ул нишләр? Ә иректә?!»
Күреп буллый сине үтәли.

Төннәр буе уйлар давылында
Юл табаллый чыктым адашып.
Ике якны бизмәннәргә салып,
Уйда үтте көннәр, саташып.

Хатынымны шулай күрәләтә
Бер дә килми тоткын итәсем.

Әмма белмим, «азгын» дилбегәсе
Кай тарафка аны илтәсен.

«Туктатыгыз», – дисәм аңга килеп,
Сәрхүшлектән айный алырмы?
Әллә һаман «кызыл борыннар»га
Бер җилбәзәк булып калырмы?

«Аллам! – дидем. – Сиңа тапшырамын,
Рәхмәтеңнән үзең ташлама.
Дөрес юлга чыгар хатынымны,
Өйрәт яңа тормыш башларга...»

Һәм шәфкать Аллаһ гозеремне,
Күңеленә тәүфыйк индерде.
Себер төрмәсендә игелекле
Һәм әхлакый юлга күндерде.

Асылына кайтты, иман тапты,
Биш вакытта басты намазга.
Үтәде биш фарыз гамәлләрне,
Кылды изге сәфәр ул Хаҗга.

Кайгы йөрми агач башларыннан,
Ул йөридер адәм башыннан.
Бериш кеше акылына килми
Авыз итми «лаеш ашын»нан.

Хак Тәгалә кодрәтеннән башка
Җилләр исмәс, яфрак селкенмәс.

Җир йөзендә һичбер нәрсә ҹсмәс,
Адәм балалары көн күрмәс.

Аллаһ сөеп, ышанычлым, диеп,
Хуҗа иткән Җирдә Адәмен.
Җир астына салган байлыкларын,
Җир өстенә биргән тәгамен.

Бу дөньяда яшәү серен әйтеп,
Изге китапларын иңдергән.
Гөнаһлардан тыелырга кушып,
Кешеләргә әмер күндергән.

Коръән-Кәрим – кешеләргә җирдә
Дөрәс яшәү өчен бирелгән.
Аллаһының кушканнарын үтәү –
Мөселманга фарыз, диелгән.

7. Төштә күргәннәрдән

Аллаһ фәрман, изге кануннарын,
Хәбәрләрен тора җиткереп.
Кайчак кеше чиксез Галәмнәрне
Урап кайта, сәер төш күреп.

Мин дә күрдем ифрат гыйбрәтле төш,
Чем караңгы үттем торбадан.
Каршы алды мине өч ир заты,
Ак чапаннан, ап-ак чалмадан.

Өчесе дә яшел киң болынның
Басып тора калку җирендә.
Уртадагы Галиҗәнаб ирнең
Чурлар балкый иде йөзендә.

Ул каршыма минем килде дә,
Әйтте: «Килгәнсең, – дип, – син иртә.
Кайт өеңгә, бездән вәхи килер,
Дини-рухи сине эш көтә».

Мин карадым күккә, бактым җиргә,
Күңелемә җыйдым аңымны.
Илаһи нур, тылсымлы рәхәтлек,
Кочып алды бакый җанымны.

Тирә-якка карап, гаҗәп ямьле
Табигатьне күреп сокландым.
Яктылык та анда – сөт төсендә,
Мин үзем дә сөттәй акландым.

Әйләнәдә хәтфә яшеллекләр,
Урман-кырлар ята җәелеп.
Тулып пешкән җиләк-җимешләре
Җил исүгә төшә өзелеп.

Көмеш сулыКәүсәр чишмәләре
Әйтерсең лә, Фазыл чишмәсе.
Агышлары моңлы һәм аһәңле,
Җырлый кебек Айның Зөһрәсе.

Бөеклеген үзенең белеп ага,
Ширбәт елгалары тын гына.
Хак мөселман намаз-гыйбадәттә,
Баскан гүя Идел ярына.

Кая бакма – сый-хөрмәтле табын,
Инсаннары юмарт, ягымлы.
Ризык-нигъмәтләре бисмиллалы,
Бу соң әллә туган ягыңмы?!

Монда юктыр патша сарайлары,
Хаким итми ерткыч көчлелек.
Юктыр анда бездәгедәй нәфес,
Гөм хөсетлек, һәм дә көнчелек.

Тормыш ямьле, ашлары да тәмле,
Бөтен тараф серле тынлыкта.
Табигать ул – җанлы! Ул – илаһи!
Җан тантана итә чынлыкта.

Бу мизгелләр акыл, зиһенемә,
Хәтеремә кереп уелган.
Гөнаһ кылганнарга Аллаһының
Җәннәтенә керү тыелган.

Кылу өчен изге эш-гамәлләр,
Хак мөселман булу кирәктер.
Җир-Әнкәдә гыйбадәтсез яшәү -
Оҗмах ишегендә элмәктер.

Төштә күргән гаҗәп бу күренеш
Үтеп китте мизгел эчендә.
Киләчәктә Җирдә яшәү рәтен
Күргәнмендер, бәлкем, төшемдә.

Тик тормышта яшәү серен әйтеп,
Китапларын Аллаһ күндергән.
Гөнаһлардан тыелырга кушып,
Бу дөньяга әмер иңдергән.

Иман барлап, кушканнарын үтәп,
Тормыш кору – Аның теләге.
Җәннәт күрке булыр Җир-Әнкәбез, -
Аллаһының тиңсез бүләге.

8. Җир – кешенең яшел бишеге

Хатым, бәлки, сиңа барып җитмәс,
Таба аллмас үзенең иясен.
Андый чакта инде тик бер өмет:
Бәлки әле табар, диясең...

Бу хатыма Галәм юлларында
Туры килер озак йөрергә, –
Габделһади кызы Саниянең
Үзен тиеш табып күрергә!

Син җәннәттә микән? Әллә инде...
Җәһәннәмдә? (Аллам сакласын!)
Инша Аллаһ кылган гамәлләрең
Ачсын серле җәннәт капкасын.

Аллаһының рәхмәтләре чиксез,
Гафу итәр булган гөнаһны.
Иманы саф мөэмин-мөселманга
Бүләк иткән тиңсез оҗмахны.

Шул оҗмахның гүзәл сараенда
Бакчаларын, бәлкем, гизәсең?
Бәрәкәтле зәмзәм суын эчеп,
Оҗмах җимешләрен өзәсең...

Ә елгалар хәтерләтә булыр
Тал-тирәкле Мишә буйларын.
Шул талларга басып, өзеп-өзеп,
Я зын сандугачлар сайравын.

Охшаганнар микән урманнары
Чарат урманына Шәленең?
Тиңе бармы анда бездәгедәй
Урман аланнары яменең?

Безнең болыннарда шаулап үскән
Чәчкәләрнең бармы тиңнәре?
Җир-әнкәнең канат кагышыдай
Исә микән сәхра җилләре?

Бармы анда, әсир итәр нәрсә –
Хәтфә кебек уҗым кырлары?
Шул кырларда алтын башакларның
Бездәгедәй сихри җырлары?

Авыз суың ташый, кулга алсаң,
Күпереп пешкән бодай күмәчен.
Алсу кызыл ап-ак күмәчләрдә
Кешеләрнең йөзен күрәсең...

Алар бүген гөрләп бәйрәм итә,
Хезмәтләрен күреп күмәчтә.
Тик намуслы хезмәт кешеләрне
Гасырларга илтә үлгәч тә.

Кеше мәшһүр бөек эше белән,
Эше белән данга урала.
Иң зур бәхет – башкаларга шатлык
Бүләк итү булып санала.

***

Әле генә сытык көзләр иде,
Дулый иде кышның бураны.
Ала-кола җирне юып китте,
Язның тәүге ләйсән яңгыры.

Бар дөньяны гүзәллеккә бизәп,
Җылы нурлар бөркеп яз җитте.
Гөлләр керфек какты, күзен ачты,
Гашыйк күңелләрне җилкетте.

Бозны төртеп умырзая шыта,
Зәңгәр чәчәкләре вак кына.
Яз сафлыгын иң беренче булып,
Бүләк итәргә ул ашкына.

Бар табигать җәйге күлмәк киде,
Дөнья яшеллеккә күмелде.
Каеннарның бала яфраклары
Кояш нурларына үрелде.

Лепелдәшеп усак яфраклары
Бер-берсенә серен бүлешә.
Йөзен куеп кояш тарафына
Миләш тәлгәшләре көлешә.

Бакчаларда җимеш агачлары
Шау чәчәккә төрде дөньяны.
Гәр тарафтан тәмле хуш ис аңкый,
Кемнәр бөркн икән соң аны?

Күк күкри, яшен яшьнәп ала,
Утлы уклар телә күкләрне.
Кояш чыга! Салават күперләре
Кочып ала офык-чикләрне.

Гәр тарафта – сафлык, көләч шатлык,
Җир-әнкәбез чиксез сөенә.
Бөтен җан иясе иркен сулап,
Кояш нурларында коена.

Дөнья шундый матур! Чидән икән?!
Хатын-кызлар – нурлы, чибәрләр, –
Әни булып, апа-сеңле булып,
Җәннәтне дә алар бизәрләр.

Бармы анда сөю, яратулар?
Үзәкләрне өзәр сагышлар?
Бер хәсрәтсез затлар булмас кебек,
Югалтусыз юктыр табышлар.

Бармы тормыш, иртән кояш чыгып,
Чур чәчәме җир һәм күкләргә?
Бит кешелек яши җиң сызганып,
Яшәешкә хезмәт иткәнгә.

Бармы көләч иген басулары,
Чайкаламы иркә җилләрдән?
Бөтерелеп күтәрелә микән
Дулкын-рәшә тып-тын күлләрдән?

Бездәгедәй бармы сихри язлар?
Чәрсә чәчеп, нәрсә уралар?
Ризыкларын ничек пешерәләр?
Чәрсә ашап, кайда торалар?

Җәннәт халкы торган сарайларны
Чи-нәрсәдән, кемнәр төзиләр?
Бармы анда берәр җитәкче, зат?
Эш барышын кемнәр күзлиләр?

Ир-хатыннар кайда хезмәт итә?
Ә заводлар нинди соң анда?
Җимеш татып, шәраб йотып кына
Яшәмиләр булыр беркайда.

Тамакның тук, өснең бөтенлеге –
Кием тегү, иген игүдә.
Миллиардлаган җәннәт әһелләрен
Яшәтәсе бар ич мәңгедә.

Тик ялкаулар гына яши булыр,
«Ходай бирер» – диеп, ризыкны.
Күрдек инде, эшсезлектән азып,
Кырын яткан азгын халыкны.

Эшләмәскә төрле хәйлә кора,
Сәбәп таба бу иш хөрәсән.
Җәмгыятьнең соры корты булып,
Яши алар качып хезмәттән.

Күзәнәккә һәрчак азык кирәк,
Тырыш хезмәт бирә ашамлык.
Җан иясе шулай җайлатылган,
Ашамлыксыз тормыш, яшәү юк.

Җир-Анабыз үз әнкәбез кебек,
Игелекле, юмарт, шәфкатьле.
Җан иясен алып кочагына
Туендыра, биреп нигъмәтне.

Бәйрәм ашы – кара-каршы булу,
Данлы эшләр бизи кешене.
Бу дөньяда син яшисең икән,
Үтәү фарыз изге эшеңне.

Канун шулай: кырыс кышлар була,
Көләч йөзле дәртле яз килә, -
Ямьле җәй кояшы иркәләгән
Ризык булып көзләр өлгерә.

Һәрбер фасыл үз хезмәтен үти,
Һәрбер нәрсә белә үз эшен.
Орлыклардан күкрәп иген үсә,
Һәр үсемлек бирә җимешен.

Бер үк җирдә, янәшәдә үскән
Һәрнәрсәнең үзгә җимеше, –
Аллаһы бу тиңсез могҗизаны
Гыйбрәт өчен безгә бирмеше.

Табигатьне буйсындырам дигән -
Ул акылдан шашкан, тилергән.
Табигать ул – Аллаһ тарафыннан
Тереклеккә бүләк ителгән.

***

Иксез-чиксез Галәм. Һәм бер нокта...
Аллаһ аны Җир дип атаган.
Шуның үзле кызыл балчыгыннан
Аң-акыллы кеше ясаган.

Бөртек кадәр шушы җан иясе
Аллаһының тиңсез әсәре.
Могҗизаларның да ул могҗизасы,
Кодрәтенең тиңсез әкбәре[1].

Хак Тәгалә Кадыйр[2], Халикъ[3] заттыр,
Ул Гадел дә, тиңсез Галим дә.
Тереклеккә Ризык бирүче дә
Мәшһүр Тәрбияче Галәмдә.

Җирдә кешем рәхәт яшәсен дип,
Якты, нурлы кояш кабызган.
Төнлә юлга чыккан адашмаска
Көмеш айга якты тамызган.

Дөрес яшәр өчен кануннарын,
Изге китапларын иңдергән.
Фарыз гамәлләрне үтәгән зат,
Җәннәт әһле булыр, диелгән.

Никахлашкан хәләл җефете белән
Торганнарга бирә фатыйха.
Дин-иманлы бала тәрбияләү –
Иң саваплы изге вазыйфа.

Яшә җирдә хак мөселман булып,
Коръән кушканнарга тиң итеп.
Мәүҗүд[4], Әхәд[5], Хәййө[6] икәнлеген
Хак Тәгалә тора искәртеп.

---

[1]Әкбәр – бөек; [2]Кадыйр – көче җитүче; [3]Халикъ
[4]Мәүҗүд – бар; [5]Әхәд – бер; [6]Хәййө – тере.

9. Үз теләге белән тумый кеше...

Хаталардан кеше хали түгел,
Хаталану хастыр кешегә.
Гөнаһлары ана карыннан
Мәгълүмдер Хак Тәгаләгә.

Гәрнәрсәнең әүвәл – ахыры бар,
Дәрьяларның башы – чишмәдән.
Адәмнең дә азгын гамәлләре
Ислам тәрбиясе җитмәүдән.

Тәртипсезлек, әдәп-әхаксызлык –
Ата-анасының өлеше.
Хәрәм ашау, хәмер эчен яшәү –
Нәсел-нәсәбенең җимеше.

Яр ишелеп торса, су болгана,
Буып куйсаң, юлын югалта.
Залимнәр дә язмыш ярын ишеп,
Гомер йомгакларын чуалта.

Явызларның яман сыйфатлары –
Гәлакәткә илтә яшәүне.
Әнә, тормыш кыл өстендә тора –
Язмышка һич якмыйк гаепне.

Бар гамәлләр – Аллаһ кодрәтендә,
Тик ул хуҗа җирдә һәр эшкә.
Ул – бердәнбер! Моны әйтү кирәк,
Сүз калдырмый имеш-мимешкә!

...Җан иясе үз теләге белән
Бу дөньяга килми, китми дә.
Вакыт җиткәч туа, вафат була,
Мизгелне дә хәтта китми дә.

Үзе белән беркем берни алмый,
Гәммә нәрсә кала бу Җирдә, –
Гәм кешенең кылган гамәлләре
Балкып торсын һәрчак әҗердә!

Иҗтиһатлы булсын, уйлар корсын,
Игелекле акыл эшендә.
Искитмәле сәнгать әсәрләре
Иҗат итсен гомер эчендә.

Акыл биргән, зиһен биргән безгә
Галәмнәрнең тиңсез хуҗасы.
Яшәү биргән... Шушы гомер юлын
Кешеләрчә безгә узасы!

Итәгатьле, мәрхәмәтле булып,
Адәмнәргә тормыш корасы.
Җәннәт кебек гүзәл Җиребезгә
Игелекле эшләр кыласы.

Тик кешелек көн-төн корал коя, –
Сугыш мәйданында тормышы.
Җир-Әнкәне талый, күкне даулый,
Гәлакәтле юлда булмышы.

Аллаһының байлык, мал-мөлкәте,
Адәмнәргә бирми тынгылык.
Кан-яшь аша җәмгыятьләр ава,
Гамәлләрдә әле кыргыйлык.

Нәфесеңнең күзе туймый торып, -
Аллаһыдан җәннәт сорама!
Нәрсә җитми сиңа? Йә, әйт, Кешем!
Тәүбә итәреңә соңлама...



V бүлек



Кеше дигән җан иясе акыллымы?
Бу дөньяның эргәсендә ул калырмы?
Әллә инде дәһшәтле кораллар ясап,
Үз-үзенә җәллад булып кул салырмы?

Дини мотивлар

***

Күк йөзендә кояш чыкса, ай калыкса, -
Җир йөзендә, димәк, тормыш дәвам итә.
Кояш чыккан, Ай калыккан Җир-әнкәдә
Изгенең дә, явызның да көне үтә.

***

Бу дөньяның азгын-явыз бәндәләре,
Фанилыкта яшәсә дә мул-рәхәттә...
Ләкин алар бар да тәмуг кисәүләре,
Изге гамәл кылганнар булыр җәннәттә.

***

Ай, кояш, йолдызлар балкый зәңгәр күктә.
Байларга да, ярлыга да бер үк микъдар.
Берәүләрнең зиһен ягы хәттин ашкан,
Берәүләрдә – тинтәклек мул. Кем хөкемдар?

***

Әйтәләр: «Теге дөньяда рәхәт булыр,
Монда ярлы – тегесендә кәеф кылыр».
Кәеф кылу, – гөнаһ кылулардан торса,
Оҗмахларда кемнәр генә торып калыр?

***

Азгын хисләр урап алса кеше җанын, –
Котсыз нәфес кочып аллак булыр барын.
Җефетләре, хур кызлары җитмәс аңа,
Җәннәттә дә тартып алыр кеше ярын.

* * *

Ике җенес булган җирдә мәхәббәт бар,
Мәхәббәтнең җимешләре – ул балалар.
Дөнья булгач, яхшы, яманы да туа,
Ата-ана бала өчен гөнаһ кыла.

* * *

Гауга купса – ызгыш-талаш, сугыш китәр,
Сәрхуш бәндә бер-беренең башын тишәр.
(Тьфү-тьфү) алар җәннәткә дә керсә,
Шәраб инеш-елгалары кибеп бетәр.

* * *

Җәһәннәмдә газап чигә бер адәмнәр,
Аларның нинди гөнаһ һәм гаебе бар?
Фанилыкта язмышлары язган юлны
Кайгы-хәсрәт, михнәт чигеп үтте алар.

* * *

Аллаһының әмер-фәрманы иңмичә
Яфрак та селкенмәс, диелгән Коръәндә.
Туган көннән алып үлгән көненәчә
Хак Тәгалә рәхмәтендә яши бәндә.

* * *

Мөселманга дүрт хатын да рөхсәт, имеш.
Ярый әле дүртнең берсе булса һәйбәт.
Якты дөньяң болыт белән капланачак,
Дүрт ягыңда яшен яшьнәр булып гайбәт.

* * *

Искиткеч гүзәл, дисәк тә фани дөнья,
Ошбу тормыш кайгы-хәсрәтләрдән тора.
Аллаһ безгә хис, мәхәббәт бүләк иткән,
Шуннан кеше илһам алып тормыш кора.

* * *

Күкләр Җиргә бүләк иткән хатын-кызны
Могҗизалар алиһәсе итеп күрдем.
Табигатьнең үзе кебек гүзәл затка
Гомер буе сөеп вә сокланып йөрдем.

* * *

Күккә бактым, ямь-гүзәллектән шаккаттым,
Игелекле Җир-анага сәждә кылдым.
Хатын-кызлар таифәсе нинди гүзәл!
Андый гүзәлләргә һәрчак – гашыйк булдым.

* * *

Кояш, айның йөзен, кайчак, болыт каплый,
Якты нурлар җиргә багыр урын тапмый.
Хатын-кызны кайчак болыт капласа да,
Ай-кояштай йөзләренең нурын саклый.

* * *

Әгәр булсаң сөеклесе хәләл ярның?
Иң бәхетле кешесе син бу дөньяның.
Яхшымы ул, начармы ул – ул никахлы,
Кадерен бел яныңда яшәгән барның.

* * *

«Язмышитан узмыш юк». Ышан дөреслеккә,
Баеклап бирелгән ул синең үзеңә.
Язмыш юлын кайчак урап үттең исә,
Килеп төшәсең янә иске эзеңә.

* * *

Гомер буе баш күтәрми мин казгандым,
Ач-ялангач, кайчак мәхәббәтсез калдым.
Күпме генә тырышсам да, тырмашсам да,
Язмышымда язылганын гына алдым.

* * *

Кайгы-хәсрәт, авырлыклар күп күрсәм дә,
Язмышымнан бик канәгать булып йөрдем.
Җәннәт кеби ошбу гүзәл дөньялыкта
Могҗизага, тылсымга тиң хәят күрдем.

* * *

Кеше гомере хата-ялгышлардан тора,
Елганы да уңга-сулга агым бора.
Бер кат түгел, мең кат туып яшәсәң дә,
Шул ук хата-ялгышлыклар саклап тора.

* * *

Кеше җаны күк-гарешкә аша, диләр,
Кайбер җаннар җиргә кабат кайта, диләр.
Тик кайтмас ул инде синең сын-гәүдәңә,
Җиргә сеңеп юкка чыга бит гәүдәләр.

* * *

Аллаһ әйткән: «Сезгә мәңгелек җан өрдем,
Җир йөзендә яшәр өчен ризык бирдем.
Бирдем зиһен, бирдем сихри сөю хисе, –
Адәмемне акыллы зат итеп күрдем».

* * *

Бар тереклек җир-туфрактан яшәү ала,
Кем гөлчәчәк, кем агач булып ярала.
Яктылыкмы, күләгәме күбрәк төшә -
Гәммәсе дә җир-туфракта ятып кала.

* * *

Коръәнеңдә каһәремнән курык, дисең,
Куркаклыкта хөрмәт юклыгын белмисең.
Куркаклар бит икейөзле монафикълар,
Бу ишләрне үзең дә бит, Син сөймисең.

* * *

Хак Тәгалә җан өргән без бәндәләрен,
Дүрт төрле хаклык-тереклектә яшәтә.
Күркәм холык, әдәп-әхлак һәм мәхәббәт
Акыл безне хайваннардан өстен итә.

* * *

Иң бәхетле адәмдер – бу җиргә килгән,
Ай, Кояшлы һәм Йолдызлы Күкне күргән!
Мәңгелекнең мизгелендә кеше булып,
Җир йөзенең бер мизгеле булып йөргән.

* * *

Дүрт хатынга өйләнгән бер мөселман ир
Җитмеш хур кызын кочмакка бик кызыга.
Җитмеше дә аллаш түгел татарымның
Итагатьле, саф-инсафлы бер кызына.

* * *

Аяз төндә күзәтәм мин сихри күкне,
Энҗе-мәрҗән җемелдәшә назлап безне.
Гарше-әгъләләргә ашкан бу Галәмдә
Нинди язмыш, нинди көчләр йөртә безне?

* * *

Көчле белән мәйданга чыгып көрәшмә,
Байлык белән сөлге тотып бил алышма.
Син җиңсәң дә җиңелде диярлар казыйлар, -
Казыйлары да бит аның бай абзыйлар.

* * *

Бу дөньяда тормыш итүләре авыр,
Яшим дисәң, булу кирәк бик тә сабыр.
Хак-хакыйкать дигән асылың җуелса,
Тик сабырлык яшәү көчен җанда табыр.

* * *

Җирләр, күкләр... Гәр тараф сергә уралган,
Бу дөньяны меңләгән микроблар чолгап алган.
Кеше гыйльме, аң-акылы белми әле,
Мәңге яшәү серен алар каян алган?

* * *

Күк йөзенә карыймын да хәйран калам,
Йолдызларның җем-җеменә, әй, сокланам.
Әйе, кешем, нурлар чәчеп син дә балкы,
Тылсымлы һәм бик тә серле йолдыз сыман.

* * *

Дәрьяларны чык-тамчылар тәшкил итә,
Халыкларны зат-кешеләр барлык итә.
Туган телем, моңлы көем, асыл динем
Милләтемне гасырдан-гасырга илтә.

* * *

Безнең дөнья гүзәлләрнең дә гүзәле,
Монда яшәү – гүзәллекнең гүзәл мәле.
Кайгы-хәсрәт, борчу-мәшәкатьләре дә
Гүзәллекнең үзенчә бер төре, яме!

* * *

Бу дөньяга кеше булып килү – бәхет,
Күрү, тою, ишетүләр – чын сәгадәт.
Телебез бар, моңыбыз бар, динебез бар,
Халкыбызны бизи күркәм гореф-гадәт.

* * *

Кешеләрнең бәхет-шатлыкларын алма,
Кайгы-хәсрәт, җәбер-золымнар да салма.
Гүяркемнең дә гомеркәе тик бердәнбер,
Канкоючы явыз булып истә калма.

* * *

Җылэр белэн тапма да син һэм бүлешмэ,
Эш-гамәллэр кылырга да һич килешмэ.
Мэсхэрэгэ калырсың ил-җир йөзендэ,
Җылэр дигэн язма булыр белешмәңдэ.

* * *

Бэрәң яшәң лэззәте таба эчүдэн,
Бэрәң ала тәм-лэззәтне тик эшеннэн.
Эштэн лэззәт алганы да, эчкәне дэ,
Бара булыр ата-бабалар эзеннэн.

* * *

Керлэнгэнне чиста итеп юып була,
Ялгыш сүзне, үй-фикерне тыеп була.
Тик юып та, тыеп та буллмый намусны, -
Бер керлэнсэ, ул мәңгегэ шулай кала.

* * *

Бу дөньяга гариза биреп киллмилэр,
Язмышында ни язганын да белмилэр.
Тормышларын үз кулына алганнары
Язмыш артыннан ияреп тә йөрмилэр.

* * *

Мин бәхетсез диеп, һэрчак шыңшып йөрмэ,
Әнэ кояш иртэ таңнан үз эшендэ.
Аның кебек көләч йөзле, нурлы булсаң,
Бэлкып торыр бәхетең дэ һэр эшеңдэ.

* * *

Җитмеш бишкә кадәр яшәү күп шикелле,
Тик борчулы уйлар тырный күңелемне.
Кайгырттыммы милләтемне, ил-җиремне?
Әллә бушка уздырдыммы гомеремне?

* * *

Миннән соң да бу дөньяга язлар килер,
Назлы гөлләр кояшка таба үрелер.
Тик мин буллам, гөл-чәчәкләргә үрелмәм,
Тик бер тапкыр чәчәк ата безнең гомер.

* * *

Китәргә дип килсә дә дөньяга кеше,
Изге эш-гамәлләр кыла затлы ише.
Мәңге яшәр һичнәрсә дә юк дисәк тә,
Ләкин бар ул. Ул – Аллаһның акыл эше!

* * *

Акыл бит ул бирелмәгән һәркемгә дә,
Чәчәк атарга өлгерми кай гөлләр дә.
Акыл, зиһен, зирәклегең булганда да
Чәчәк атар мөмкинлек юк кай илләр дә.

* * *

Гүч заяга үткәрмә син гомереңне,
Бел, оныклар дәвамында килереңне!
Игелекле хәзинәләр мәңгелектер,
Изге җир-туфракта калдыр үрчемеңне.

* * *

Берәү әйтер: «Үгет-насыйхәт сөйләмә,
Төйнәлгәнне икенче тапкыр төйнәмә.
Коръән дә бит үгет-насыйхәт вәгазьли,
Вәгазьләрнең асылында хак өндәмә.

* * *

Көфер сүзләр әйткән кеше имансыздыр,
Андыйларның калеб-күңеле буш-такыр.
Юкса мәшһүр акыл ияләре язган
Әсәрләрнең нәсыйхәтсезләре юктыр.

* * *

Сәрхуш кеше – күз көеге, ил череге,
Сәрхушләрнең эчү булыр җан кирәге.
Шул сәрхушлек баткагында гаип булды
Зур әдипләр – әрни шуңа ил йөрәге.

* * *

Офыкларга кояш алтын билбау атты,
Көмеш нурлар җирдә яңа көн уятты.
Аллаһының илаһи рәхмәте белән
Мәрткә киткән тереклек яшәүгә кайтты.

* * *

Бер иш затлар үз-үзләренә кул сала,
Мондый бойрык-фәрманны ул кемнән ала?
Дөнья белән алыш-биреш өзүчеләр
Чәселенә мәсхәрәле тамга сала.

* * *

Әй, кешем! Син язмышыңнан алда чапма,
Сабырыңны түземең бетсә дә сакла.
Бу дөньяның мизгелен дә һич югалтма,
Гомереңне шайтан коткысына сатма.

* * *

Азгынлыкны, фәхешлекне көсеп итеп,
Яши берәү сәрхушлектә әүмәкләшеп.
Милли төскә әйләнгән бу гадәтләрен
Балалары арттыралар күмәкләшеп.

* * *

Бу дөньяда фанилык тауларын кичтем,
Гомер буе куенымда аш-су йөртәм.
Туган телне саклап калган буыннарга
Милли-рухи байлыгымны ядкәр итәм.

* * *

Һич акланмыйм, булды миндә хаталар да,
Хатасыз юк һичберәү дә бу дөньяда.
Бу тормышның изге кагыйдәсе шулдыр:
Кеше башын, кеше хакын ашамауда.

* * *

Ил-җирләрне яулаган гаярь Искәндәр,
Газраилдән ала беркөн шомлы хәбәр.
Бинһая байлыкларга ия хәким
Тик кәфендә уралып кабергә иңәр.

* * *

Ғаләмнәрнең иң яманы – ул хаинлык,
Хаинлыкта безнең бүгенге кыенлык.
Дәүләтләрен, ил-җирләрен җуйган кебек
Үзен-үзе җуеп бара безнең халык.

* * *

Көне-төне телевизор экранында
Сугыш, атыш, үтереш кебек тамаша.
Ярты халык илне талый, илне сата,
Ә яртысы шуларны эзләп маташа.

* * *

Бетте әхлак, бетте әдәп, гореф-гадәт,
Илне басты фәхишә, сәрхуш бергәләп.
Олигарх әфәнделәр мал бүлешә,
Фәкыйрьлеген өстери ярлы мыскәләп.

* * *

Кая басма – һәр җирдә адәм сөяге,
Ғәр тарафта – яман кешеләр өрәге.
Кайсы кеше, кайсы өрәк – аермассың,
Кемнәргәдер аларның да бар кирәге.

* * *

Җиргә килеп, адәм заты зур юл үтте,
Үзгәреп ул, бу заманга килеп җитте.
Ғәр заманның начар гадәтләрен җыеп,
Ул үзе дә яманга әйләнеп бетте.

* * *

Әлифне таяк дип белмәгән адәмнәр,
Чалма киеп, хәзрәтләргә әйләнделәр.
Тәмугъ белән тәкъва затларны куркытып,
Хәрәм ашап, хәрәм эчеп кинәнделәр.

* * *

Бериш хәзрәт теле белән вәгазь сөйли,
Азгын нәфсе сылу-чибәр кызлар эзли.
Күзе белән вәсвәсәдә зина кыла,
Ул намаздa инде тәһарәтсез була.

* * *

Ике чабата – бер кием дисәләр дә,
Аерма бар чабаталы кемсәләрдә.
Берсенең эш-гамәлендә котсыз мәкер,
Икенченең хак-иманлы изге сүздер.

* * *

Берәү белән хаталанып борчу алдым,
Унҗиде ел мин хуҗабикәсез калдым.
Сукбайлыкта йөреп безне газаплады,
Дөньялыкта яшәвендә җәза алды.

* * *

Язмыш белән канун талкый кешеләрне,
Кол хәлендә тота гавам ишеләрне.
Бу дөньяда адәм заты бер уенчык,
Тегесендә тәмуг утына – утынчык.

* * *

Заманында Кашпировский һәм Чумак,
Йөргән иде бөтен Рәсәй халкын алдап.
«Изге урын буш тормый», – дип, әйтә халык,
Һәм бүген дә халкын алдый икәү парлап.

* * *

Тыялмыйча үз нәфесен җиләр ашый,
Кирәксезен шлак итеп чүпкә ташлый.
Ашау өчен генә яшәгән адәмнәр,
Үзләре дә чүп-чарга әйләнә башлый.

* * *

Бу дөньяга мин кунакка килдем димә,
Тормыш җебен мәңгелеккә диеп төйнә.
Нинди ният белән җирдә тормыш корсаң,
Тегесендә мәгълүм булыр бәйнә-бәйнә.

* * *

Алдап-йолдап, талап ул хәрәм мал җыйды,
Тәкәбберлек белән җиргә күсәк орды.
Тик кабере өстендә берни дә үсми,
Хәтта шайтан таягына кадәр корды.

* * *

Акыллы сүз кешеләргә зиһен бирер,
Барлык эш-гамәлләрендә алдан йөрер.
Изге сүзләр, изге уйлар фикер булып,
Мәңгелеккә – Гареш күңеленә керер.

* * *

Сүзнең яхшы, яманын да бер тел әйтә,
Сүз кешенең бәгыренә барып җитә.
Тел берәүгә җир-күкләрне бүләк итә,
Ә берәүне тел вакытсыз гүргә кертә.

* * *

Бер карасаң, нәфес коточкыч нәрсә күк,
Комсызлыгы, кансызлыгы чиктән ашкан.
Ләкин нәфес җан асрау өчен тырыша,
Мәңгелек җан ике дөньяга тоташкан.

* * *

Хак Тәгалә Адәменә акыл биргән,
«Җир йөзендә кунак булып яшә», – дигән.
Җирнең астын өскә китерә шул адәм, –
Бу кадәрле тиле-тинтәк каян килгән?

* * *

Бу дөньяга миллиардлаган кеше килә,
Төсмугы да, оҗмахы да бар тормышта.
Ә яшәүнең иң-иң асыл мәгънәсе шул:
Изге гамәл, игелекле эш кылмышта.

* * *

Бу дөньяга миллиардлаган кеше килә,
Миллионнар сугыш кырларында үлә.
Иректән һәлак ителгәннәр җаны
Үч алырга җир йөзенә янә килә.

* * *

Бу дөньяга миллиардлаган кеше килә,
Берәүләре дөнья малын кочып ала.
Исә җилләр, күңә чүлләр, кибә күллəр...
Изге гамәл, хикмәти сүз торып кала!

* * *

Халык әйтә: «Тәвәккәллек – дип – таш ярыр,
Булдыклылар кыя-ташка кадак кагар».
Тәвәккәлләр сират күперләрен үтеп,
Җәһәннәмнән чыгар юлны эзләп табар.

* * *

Барлык төсне кара төскә буяп була,
Тик кара төс башка төстән калкып чыга.
Кул-аяксыз, бер коралсыз гап-гади су, –
Тау-кыялар тишеп чишмә булып ага.

* * *

Аттан ала да, кола да туа, диләр,
Гайрәтле дә, җебегән дә була ирләр.
Ала-кола ил белән идарә итсә,
Яклаучысыз, саклаучысыз кала җирләр.

* * *

Ялагайның төпле үз фикере буллмый,
Тегеңә дә, моңа да ул койрык болгый.
Шуңа күрә аңарга: «мөнафыйкъ», диләр,
Мөнафыйкъны эт урнына тота илләр.

* * *

Ялтыравык нәрсә күрсәк шаккатабыз,
Әсәрләнеп мәхәббәт угы атабыз.
Ялтыраган һәрнәрсә дә алтын түгел,
Пыяладай челпәрәмә килә күңел.

* * *

Безнең тормыш гөнаһ-хаталардан тора,
Ялгышлыклар аша кеше тормыш кора.
Ә син: «Тәүбә вә әтәүбү иләйһи», – дип,
Аллаһыдан гафу-ярлыкауны сора.

* * *

Тимер ишек артларына халык посты,
Симергәннең арт шәрифләре бөреште.
Ачлы-туклы халык сугыш елында да
Бар булганы белән үзара бүлеште.

* * *

Нәфесенә хуҗа түгел – комсыз кеше,
Хәрам җыяр курыкмыйча Аллаһыдан.
Әсир булып сихри шайтан коткысына,
Җиңелә ул явызлыгы тарафыннан.

* * *

Иман нуры – Хак Тәгалә нуры булып,
Мөэминнәргә җаны белән бергә иңә.
Коръән нурлы милли гадәтле татарны –
Дошман түгел, хәтта чёрт та алмас җиңә!

* * *

Утны-суны, кояшны, сулар һаваны
Алыштыра алмый һични табигатьтә.
Татарлыкта – тел дә, дин дә, милли рух та...
Безнең җанда, безнең канда, хакыйкатьтә!

* * *

Көнбатышның дин кояшы батып бара,
Кәферләрнең күк йөзендә болыт кара.
Борынгыда мөселман булган кавемнәр
Аллаһының хак диненә кайтып бара.

* * *

Мөселманлык – Аллаһның бирлеген тану,
Итагатьле, гыйбадәтле Аңа булу.
Ялгышлыкта йөз таяк җәза урынына,
Йөз сабак салам учмасы белән сугу.

* * *

«Ишәк изге Коръән күтәреп йөрүдән,
Ул динче дә, хак мөселман да булмастыр».
Коръән тотып, ашау өчен ашка йөрү, -
Безнең хәзрәт – абыстайларга да хастыр.

* * *

Бу дөньяда бөтен нәрсәләр дә пардыр,
Һәфеснең дә бар изгесе, бар яманы.
Изге нәфес матди, рухи байлык барлый,
Яман нәфес – байлыкны талап алганы.

* * *

Җирнең эче куышланып, бушап калса,
Тартым көче, егәре аның югалыр.
Җил очыртып йөрткән ач кандала кебек,
Ул да Галәм бушлыкларына юл алыр.

* * *

Учак уты үз алдын гына яктырта,
Кызуы да казан өчен генә җитә.
Кояш якты нурлар бөркеп җылытса да,
Тик аналар җылысы тамырга үтә.

* * *

Безнең тормыш шундый хәлгә килеп җитте:
Чын табигый рәвеш бетте, хәләл бетте.
Кешеләрдән оят китте, намус китте,
Нәфеслене акча җене әсир итте.

* * *

Кешеләрнең уннан тугызы ахмактыр,
Яшәүләре – су уңаеннан акмактыр.
Адәмнәргә кирәк кадәр белем биргән
Хикмәкти серләр иясе – Аллаһ хактыр.

* * *

Эткә әйтсәң, әйтмәсәң дә – ул бичара,
Җәй-челләдә телен аска салындыра.
Аллаһ сыйфатлары булган кешене дә,
Вәсвәсәле тормыш үзе азындыра.

* * *

Зур бәхеттер, дәрәҗәдер мөселманга
Рәсүл Мөхәммәтнең өммәтендә булу.
Хак динебез – Ислам белән Аллаһыга
Итагатьле булып, изге гамәл кылу.

* * *

Гүнч кенә дә ышанасым килми әле,
Инде җитмеш биш яшьлек карт булуыма.
Аллаһыга шөкер итәм, рәхмәт әйтәм,
Ил-җиремә һаман хезмәт кылуыма.

* * *

Заманында бер меңә татар кырык меңне
Урак урган сыман итеп кырып салды.
Шул каһарман татарларның варислары
Бүген куркак, мәми авыз булып калды.

* * *

Аллаһ кушып, берәү «алтын балык» тотса,
Үзен «алтын чалма» кигән итеп тота.
Башкаларны санга сукмаган ахмакны
Тәкәбберлек, мин-минлеге кабып йота.

* * *

Алып батыр кебек куәтле булсаң да,
Ил-җирләрне кисәкләп ерта алмассың.
Күккә ашкан тауның башына менсәң дә,
Асылың да тик үзең булып каласың.

* * *

Берәү әйтә: «Балта биреп, шөшле алдым,
Күршемдәге бер татарны алдаладым».
Чит милләттә улың – кияү, кызың – килен,
Балта, шөшлесез дә калма, әй татарым?!

* * *

Икейөзле булган мөэмин-мөселманнар
Кәферләргә дуслык кыла, кода була.
Татарның да тырә дигән зыялысы
Чит-ятлардан тәре таккан хатын ала.

* * *

Тотынма син көчең җитмәстәй нәрсәгә,
Буең җитмәгән нәрсәгә дә үрелмә.
Аллаһ сине бер нәрсәгә дә көчләми,
Фарыз булган гамәлдән тик йөз чөермә.

* * *

Хак Тәгалә кешелеккә җәза итеп,
Гыйбрәт өчен яңа чирләр биреп тора.
Азганнарны, туры юлдан язганнарны,
Яман чирләр, СПИД дигән афәт кыра.

* * *

Аллаһының иксез-чиксез хозурында
Мәңгелек дин – Ислам дине генә хактыр.
Тот, тәрегә табынганнар ник саташа –
Чебен дулап тәрәз ватканы да юктыр.

* * *

Һәр изге сүз, һәр игелекле бәрәкәт
Аллаһының тарафыннан иңгән безгә.
Иблис-шайтан явызлыкны – яхшы итеп,
Азгынлыкны бизәп күрсәтәдер күзгә.

* * *

Тиңсез асыл сыйфатында һәм затында
Бердән-бер Аллаһ чиксез Галәмнәрдә.
Аңа мәңге тугрылыклы була белик, -
Галәмдәге кояш кебек, гамәлләрдә.

* * *

Йә, аяныч, йә көлке хәлендә булып,
Үткән заман һәр тормышта кабатлана.
Һәр буынның тәүге эше ата-баба
Тырмасына басып караудан башлана.

* * *

Буыннардан күчеп килә акыл көче,
Белем белән тулылана бер өлеше.
Затның мәшһүр, данлы-даһи булуында, -
Каршылыклар белән тулы заман эше.

* * *

Таш өстеннән йөгереп аккан инешнең
Читләрендә ак күбекләр бөтерелә.
Ут өстендә торган сөт тә ташып чыга,
Мәйданнарда халык сөте күтәрелә.

* * *

Лә иләһә иллал-лаһу дигән сүзнең
Тамырлары җир белән күк үзәгендә.
Итагатьле, гыйбадәтле мөселманның
Иман нуры балкып тора йөзләрендә.

* * *

Мәхшәр көнне каберләрдән кубарылып,
Адәм заты хисап тотар илсез калып.
Ахирәттә без нинди хәлдә булырбыз?
Нинди рәвеш, нинди төс-кыяфәт алып?

* * *

Милләтемнең күңел капусы ачылыр,
Офыкларга нурлар бөркеп таңы атар!
Әй, татарым! Ата-бабаң кыйтгаларда
Дәүләт тоткан данлы чорын кире кайтар.

* * *

Сәрхүш шагыйрь, сәрхүш галим, сәрхүш хәзрәт...
Милли хурлык, милли оят, милли хәсрәт.
Халкыбызны аздыручы иблисләрнең
Булганыннан буллаулары хәерлерәк.

* * *

Бөек державачылык шовинизмы
Милләтләрне тамырыннан йолкып ата.
Татарның да ялтылаш тамыры җирдә, -
Ялтылашы тышта калып, корып ята.

* * *

Коръән әйтә: «Диннән киткән мөртәтләргә,
Фәхешлектә йөргәннәргә җәза тиеш».
Ләкин алар бу дөньяның арбасында,
Кулларында хәрәм маллар, алтын-көмеш.

* * *

Фәрештәләр яшәсәләр җир йөзендә,
Тойгы, хис тә, мәхәббәт тә буллмас иде.
Фәрештәләр ничек црчи – без белмибез,
Тик балалар мәхәббәттән тумас иде.

* * *

Яши торгач, ачысын да, төчесен дә...
Кешене дә язмыш колы итеп кцрдем.
Гомеремне ялгыш-хаталарга төрдем, -
Гафу итмәс нәрсәләрнең югын белдем.

* * *

Ләцхел-мәхфцздә язылган тәкъдиреңне
Хак Тәгалә Кадер Кичендә цзгәртер.
Мең айдан да хәерле булган бу кичне
Хак мөселман ураза тоткан хәлендә,
Намаз укып, догалар кылып цткәрер.

* * *

Хак Тәгалә кешене кызыл балчыктан
Бар итә дә... Аңа мәңгелек җан өрә.
Дөньялыкта изге гамәллəр кылсынга
Гөр кешегә җан белән рәсцл дә керә.

* * *

Иман нуры, Коръән нуры – Аллаһ нуры,
Мәңге балкып торыр алар җир-күкләрдә.
Килер бер көн: дөнья малы җилгә очар,
Тик изгелек калыр рухи күңелләрдә.

* * *

Коръән әйтә: «Хак Тәгалә кешеләрне
Ислам дине өчен генә барлык кылды.
Монафыйклар, мөшриклəр һәм кяферләр...
Барысы да әүвәл чакта мөэмин булды».

* * *

Аллаһының кодрәтенә тиңнәр юктыр, –
Үзе хактыр, көче хактыр, эше хактыр.
Диңгезләрнең суларын кушып язсаң да
Изге сүзе мәңге бетмәс, Ул – Илаһтыр.

* * *

Коръән белән гамәл кылган мөэминнәргә,
Аллаһының нигъмәтләре булыр бүләк.
Җәннәтләргә керү өчен итагатьле,
Гыйбадәтле күңел кылган гамәл кирәк.

* * *

Хак Тәгалә адәмнәрне төрле диндә,
Төрле төстә итте җиргә, күккә карап.
Ислам динле һәм иманлы мөселманны
Үз рәхәте, шәфкатенә алды урап.

* * *

Әл-Коръәннең «Төтен» сүрәсендә Аллаһ:
«Җир – күкләргә утлы төтен иңәр», – дия.
Тәкәбберлек чире йоккан кешелеккә,
Хак Тәгалә һәлакәтле сабак бирә.

* * *

Адәм затын акыл иясе дисәк тә,
Гыйлем аңа чеметемләп ирешелгән.
Тәкәббер һәм денсез-динсез залимнәрдән
Җир-күкләрнең сер сандыгы яшерелгән.

* * *

Хаин татар! Син ханлыкка уктан аттың,
Ата-бабаң тамырына балта чаптың.
Идел-йортны, динеңне, телеңне саттың,
Дошманнарның оясына кереп яттың.

* * *

Күңелендә шайтан йөрткән җаһил бәндә,
Азгынлыкта йөрер хәрәм гамәл кылып.
Явызлыгы үз башына җитәр аның,
Эт көнендә иңрәп ятар ялгыз калып.

* * *

Яшәр өчен кирәк булган һәр нәрсәне,
Җир-анабыз ала Илаһи күкләрдән.
Хак мөселман ике дөнья хикмәтләрен, -
Акыл көчен аладыр изге Коръәннән.

* * *

Һәр милләтнең үз юлы бар, кыйбласы бар,
Гореф-гадәт, йолалары: бар да мулдан.
Тик шәригать, Ислам дине кыйбласы хак,
Мөселманнар! Адашмагыз туры юлдан!

* * *

Бер кешенең җирдә яшәү дәверендә,
Миллиардлаган кеше килә бу дөньяга.
Тик иманлы, игелекле гамәл кылган, –
Күренмәгәнне күрүче зат азая.

* * *

Галәмнәрдә сызылып йолдыз атыла,
Кисәкләре башка җисемнәргә төшә.
Бер нәрсә дә юктан бар, бардан юк буллмый, -
Бер халәттән икенче халәткә күчә.

* * *

Маңгай күзе түгел, күңел күзе күрә,
Күңел аша үтсә генә акыл керә.
Никадәр зур, бик акыллы булса да баш, -
Әмерне бит серле-күзле күңел бирә.

* * *

Берәү әйтә: «Дини әкиятләр тыңлаган
Кешелекнең бала чагы инде үтте».
Ләкин акыл, гыйлем һәм тәрбия биреп,
Шул берәүне иланһи дин кеше итте.

* * *

Аллаһыга ышанмаган бәндәләргә
Барлыгын һәм берлеген Ул исбат итте.
Үтә нәни нано кичәкчекләренең
Кодрәтеннән кешелекнең исе китте.

* * *

Төрки кавемнәрне бергә берләштереп,
Әверелдек без татар милләте булып.
Татар телле, Ислам динле дәүләт булып,
Яшәрбез без хөр ил-җирдә мәңге калып.

* * *

Кешелекнең явызлыгын әйтеп кенә,
Язып кына бетерә торган түгелдер.
Дөньяларның яшәешен юк итүдә
Ул Җаһил дә, Газраил дә... Ул – әҗәлдер.

* * *

Ата-ана баласына рәвеш бирә,
Кеше булыр шул рәвешкә акыл керә.
Иманына тугры булган хак мөселман,
Аллаһының рәхмәтендә көнен күрә.

* * *

Азчылыкны күпчелеккә буйсындырып,
Дәһри дәүләт хокуклардан мәхрүм итте.
Аллаһының хак юлыннан адаштырып,
Миллионнарны җәһәннәмгә алып китте.

* * *

Бу дөньяда һәркемнең бар туган җире,
Шул туфракта һәр халыкның үз тормышы.
Үз бәхетен, мәхәббәтен табар һәркем,
Балкып торса күңеленең ай-кояшы.

* * *

Кеше дигән җан иясе акыллымы?
Бу дөньяның эргәсендә ул калырмы?
Аллә инде дәһшәтле кораллар ясап,
Үз-үзенә җәллад булып кул салырмы?

* * *

Кеше дигән акыллы зат ышанадыр, -
Им-томнарга, хорафәткә, пот-сурәткә.
Аллаһыга шәрик кылып йөргән бәндә
Үзен-үзе тәкъдир итә һәлакәткә.

* * *

Кемнәр килеп, кемнәр китми бу дөньядан,
Яхшысын да, яманын да җыя-җыя.
Кеше талап җыелган мал варислары
Мирас бүлә, нәсел канын коя-коя.

* * *

Җитмештән соң кеше дигән җан иясе,
Әҗәл көтә, торып картлык җирлегендә.
Гыйбадәтле, итагатьле изге җаннар -
Мәңге яшәр ике дөнья берлегендә.

* * *

Ил-дәүләтләр тоткан мәшһүр халык идең,
Кайда синең горурлыгың, милли йөзең?
Ата-баба телен онытқан оланнар
Манкортлашты ятның ялчысы булганнар.

* * *

«Булдырабыз!» дип мактандык. Булдырмадык.
Булдырылган азатлыктан колак кактык.
Халыкара хокук иле булган идек, -
Хокуксызлык заманына кире кайттык.

* * *

Иртә-кичен Аллаһыга ул табынды,
«Мал-мөлкәт бир, байлык бир», – диеп ялынды.
Баеп китте. Аллаһның кирәге бетте,
Үрделәр. Байлыгы башына җитте.

* * *

«Хиз-бут тахрир, һәм фанатик вahһабчылар
Кирәк түгел безгә», дия чаллмалы баш.
Дин акчасын урлап йорт-коттеджлар салды,
Динне кәсеп итеп ашый калҗалы аш.

* * *

Капка артларына посып, шыңшый-шыңшый,
Койрыгы бот арасындагылар өрә.
Өтек адәм, нәфесле тәкәббер бәндә, -
Аллаһыга теш ыржайта, тел тидерә.

* * *

Бик борынгы заманнардан халыкара,
Аллаһ бармы, юкмы? дигән бәхәс бара.
Бар дигән дә, юк дигән дә – бу тормышта,
Гәр мизгелдә Аллаһка мохтаҗ бичара.

* * *

Әверелеп яшәешнең корбанына,
Гәркем гомер ахырына кабалана.
Ата-баба хатасыннан гыйбрәтсезләр, -
Тырма тешенә басканнан җәфалана.

* * *

Дөнья һәрчак үзгәрештә, хәрәкәттә,
Бернәрсә дә була аллмый бер рәвештә,
Алмашынып тора тормыш табигатьтә,
Яшәеш тә дәвам итә тик көрәштә.

* * *

Космонавтлар Галәмнәрдә очып йөри,
Бу гамәлдән ни буласын һичкем белми.
Күкнең Аллаһ тыйган катламына керү -
Гәлакәтле буллмас микән? Әй, адәми.

* * *

Гәлакәткә дучар булган инсаннарны
Икеләтә кызганамын – татар булса.
Кызганулы хисләрем кире кайтадыр
Хәмер эчеп үз башына җиткән булса.

* * *

Кем иленә, кем диненә, кем иренә...
Хатынына берәүләр хыянәт итә.
Сәбәпләрнең иң зуры да – сәбәп тугел!
Хыянәтче һәр азгынны җәза көтә.

* * *

Изге зат та, хәшәрәт тә җир куйнында,
Исән-имин йөргәннәрнең ни уенда?
Киткәннәрнең кире кайтканнары юкка, -
Җан иясе яшәештә үз җаенда.

* * *

Табигатьтә бернәрсә дә котсыз тугел,
Мәхәббәтле бу дөньяның һәрьягы да.
Чәчәк тажын сырып алган умартага
Бәрәкәтле хәтта шайтан таягы да.

* * *

«Бер кыр казы язны китермии шул, диләр,
Бер тарыдан ботка да пешереп буллмый.
Бер хатын-кыз тутыра алган йорт эчен
Кырык ир дә тутырып бетерә аллмый».

* * *

«Татарларга дүрт класс белем житә» дип,
Берәү, гүя, таш гасырдан аваз салды.
Шуны гына көткән козгын-шовинистлар
Халкыбызның тел-нигъмәтен йолкып алды.

* * *

Һәр мөселман биш вакыт намазын укыр,
Калебенә Коръән-Кәрим нурын алыр.
Җәннәтенә керер изге бәндәләре
Аллаһының рәхмәтендә булып калыр.

* * *

Монафикълар Аллаһ динен кәсеп итте,
Һәм намуслы, әдәп-әхлаклы зат бетте.
Денсезлектә, тәкәбберлек, мал җыюда...
Фиргавеннәрне дә алар узып китте.

* * *

Караңгыда каралар да, аклар да юк,
Тик ут сыман янып торган күзләр генә.
Ахирәттә ярлылар да, байлар да юк, -
Тик гөнаһлы һәм гөнаһсыз йөзләр генә.

* * *

Коръән әйтә: «Лә иләһә илләллаһ, – ди, -
Бәрәкәтле җимеш биргән яхшы агач».
Шул агачка денсез халык ташлар ата,
Лә иләһә илләллаһлары буллмагач.

* * *

Адәм заты хәрәм ашап, хәмер эчсә,
Көнкүреше хайван рәвешенә күчә.
Ата-ана, улы-кызы... Кем булса да,
Тагаракта дуңгыз кебек ашый-эчә.

* * *

«Изге хатын-кыз табар» дип, әйтә халык, -
Борын заманнар мирасы – бу затлылык.
Ләкин хәзер изге хатыннарга кытлык,
Кызларның да җан-тәннәре – товар сатлык.

* * *

Башкаларның милли гадәтен кабатлый
Үз башында уй-фикере булмаганнар.
Юл буенда аунап яткан савытлар да
Чүп-чар салу өчен диеп куелганнар.

* * *

Әүвәлендә эшче булган бериш артист,
Зарланадыр: артист булу авыр, диеп.
Тик берсе дә эшче булып кире китми, -
Эте-бете йөри уйнап, җырлап-биеп.

* * *

Җир кешесе – фәрештә дә, җен дә түгел,
Гөнаһ кылып яшәүчедер бу тормышта.
Изгеләрдән-изге булган әүлия дә -
Гомер буе нәфесенә кол булмышта.

* * *

Берәүләрнең калебенең миллилеге, -
Баласының исемендә чагыладыр.
Чит-ятларның михрабында табынудан
Татарымның тамырлары чабыладыр.

* * *

Ике икең дүрт була кебек сүзләрне
Әйткән чакларым булган өчен үкенәм.
Киләчәкнең акыл, хикмәт иясеннән
Башым иеп, гафу итүен үтенәм.

* * *

Сүзләренең хаклыгына раслык итеп:
«Иманым камил» диюләр ипле хәйлә.
Адәмнәрнең иманының ниндилеген,
Бер Илаһи Хак Тәгалә генә белә.

* * *

Орлыкларны келәттән ул ташыр булды,
Өнен дә казыды итеп, катлы-катлы.
Тик орлыклар агуланганнар иде шул,
Хәрам ризык бугазыннан тотып алды.

* * *

Алар күплэп шырпы, шәмнәр сатып алды,
Мәхшәр көнне исән-имин каллмак булды...
Сәүдәгәрләр майяларга рәхмәт әйтеп,
Ачтан үлгән әрвахларга дога кылды.

* * *

Карт кешенең күңел кыры ала-кола,
Шаярып әйткән сүздән дә хәтер-кала.
Туганнарның хатасы да йөрәгеңә
Үз ялгышың, үз хатаң кебек кадала.

* * *

Озын-озак гомер кичеп аңладым, шәт –
Хәят яме – акыл белән яшәештә.
Рух-киңеле ай-кояшлы булганнар тик
Чын бәхеткә ия затлар бу тормышта.

* * *

Адәм заты – көчсез, зәгыйфь җан иясе,
Галәмдәге серлелек аны куркыта.
Барлы җәннәт, барлы тәмуг... Теге дөнья?..
Билгесезлек адәмне зат итеп тота.

* * *

Балта-пычкы тотар тиешле кулларда -
Буген – мылтык, пистолеттыр, автоматтыр.
Алар кеше үтерүне кәсеп итте, -
Мал-мөлкәте хәләл булган байлар юктыр.

* * *

Җитәкчеләр тәхеткә менеп утыра,
Гәрберсе дә үзенчәләп тәртип кора.
Кысыр реформалар һәнүз үрчеп тора,
Бил каешын халык көн дә кысып тора.

* * *

Татарымның капка асты көчекләре
Киллмешәк урам этенә койрык болгый.
Йомгак кебек алдында тәгәрәшкәннәр,
Шыңшый-шыңшый аның табан астын ялый.

* * *

Изгелеккә хыянәтле гамәл кылу –
Иң кабахәт кешедән дә түбән булу.
Аш биргәнгә таш атучы хәшәрәтне –
Дөрес гамәл булыр микән гафу кылу?

* * *

Серле-сихри гүзәлләрне күргән һәркем
Тылсымланган кебек булып әсәрләнә.
Хак-Тәгалә ямьгә төргән – ул сөйкемле –
Мәхәббәтнең тажы булып исәпләнә.

* * *

Хак-хикмәтле телебезгә гашыйк булдым,
Энҗе-мәрҗән сүзләреннән фикер җыйдым.
Яшьлегемдә Памир тауларына мендем,
Зат сүзләрдән «Памир» дигән һәйкәл койдым.

* * *

Керәшеннәр туган тел ди татар телен,
Үз гадәтләренчә суза татар җырын.
Ни кызганыч – җуйган алар ислам рухын,
Гәм тәрегә алышканнар иман нурын.

* * *

Ләббәкәйле толерантлык җилгә очты,
Бүректәге бүреләр урманга качты.
Берьяклы булган ясалма «дуслык»лар да,
Вәлиулла җаны белән күккә очты.

* * *

Илбасарлар бары цле индеецны –
Иң-иң яхшы индеецлар диеп йөртә.
Киләчәктә телсез калыр татарны да
Әнә шундый ачы язмыш хәле көтә.

* * *

Буран дулый, тышта давыл котырына,
Бөтереп кар бөртекләрен җиргә сылый.
Киерелеп баскан шайтан таягында,
Февраль җиле цги бала сыман елый.

* * *

Битләреңдә шәфәкъ алсулыгы,
Елмаюың – кояш балкышы.
Сөрмә тарткан зәңгәр күзләреңдә
Могҗизалы күкләр чаглышы.

* * *

Хәрәкәттә тормыш бәрәкәте,
Бәрәкәтнең көче – хәрәкәт.
Җисемнәрне тарту көче тота,
Яшәешне тота – мәхәббәт.

* * *

Хак Тәгалә акыл, фикер биргән,
Яшәц биргән адәм ишегә.
Коръән әйтә: «Фәкать цлем генә
Мәңге яшәц бирә кешегә».

* * *

Әнкәйләргә, җанаш-җанкайларга
Ир-егетләр мәңге бурычлы.
Яшәү биргән, бергә гомер үргән
Затка тумлик изге бурычны.

* * *

Туган көннән үлгән көнгә кадәр
Гомер бетмәс кебек тоела.
Еллар үтә, гомер көзе җитә,
Соңгы яфрак җиргә коела.

* * *

Чәнечкеле шайтан таягының
Сабагында назлы гөл үсмәс.
Итагатьле татар кызының да
Намусына кара тап төшмәс.

* * *

Бетәбезме, әллә калабызмы?
Вакыт җитте җавап тотарга.
Яшәү өчен барган бу көрәштә
Гаярь булу кирәк татарга!

* * *

Мәхәббәтнең тәмен татымадым,
Мин аның тик читен тешләдем.
Мәсхәрәгә калган сөюемнең
Гарьлек газабында яшәдем.

* * *

Төрле юллар белән сыный Аллаһ, -
Фәрештәләр – Аңа булышчы:
Алар азгын, явыз бәндәләргә
Дөньялыкта җәза кылучы.

* * *

Сабырлык ул – гөнаһ гамәлләрдән
Үз-үзеңне тыеп торудыр.
Җир-Күкләрнең галәмәтен күреп,
Хәйран калу, гыйбрәт алудыр.

* * *

Татар башын татар ашаганы
Тарихларда инде сер түгел.
Татар! Әгәр исән калыйм дисәң...
Милләтпәрвәр татар була бел!

* * *

Ай-һай, кайнар булды быелгы җәй!
Яшәешнең өзде бәгырен.
Эсселектән эреп китәр чакта,
Салкынның да белдек кадерен.

* * *

«Татар барда – хәтәр бар», – дип, безгә
Яла ягып әйтә бер явыз.
Үз-үзеңә хәтәр булма, татар!
Татарлыкта – яшәү хакыбыз.

* * *

Моңсыз җыр ул – урам себеркесе.
Буразналап тормый күңелне.
Моңлы җыр ул – мунча себеркесе –
Сихәт биреп назлый тәнеңне.

* * *

Илле яшь ул – август ае әле,
Яшәешнең балкып торган мәле.
Гомернең дә чәчәк аткан чагы, –
Җимешләре алда әле, алда әле...

* * *

Советларның хәтта бер тиенен
Җирдән алды кеше иелеп, –
Халыкларны бергә берләштергән
Урак-чүкеч анда бар, диеп.

* * *

Юлярлар һәм юллар Русиянең
Кайһәр суккан милли сырхавы.
Намуссыз һәм гамьсез тиңәләрнең
Гаепсезгә гаеп сылавы.

* * *

Әдипләрнең мәшһүр китаплары
Чүпләкләрдә ята ауналып.
Әхлаксызлык канун булган илнең
Җаны-тәне беткән каралып.

* * *

Иң мөкатдәс милли уйларымны
Китапларым итеп бастырам.
Хөрлек яулап алу әманәтен
Килер буыннарга тапшырам.

* * *

Тау елгасы ташлар арасыннан
Шау-гөр килеп ага туфәнгә.
Кушыла ул, иңләп-буйлап аккан,
Киң, мәһабәт Дәрья дигәнгә.

* * *

Уразада ашау-эчү... хәтта
Яраамыйдыр дару кабу да.
Татарны да берләштерү өчен
Кирәк рухи-милли кагыйдә.

* * *

Үлә-бетә урыс үрчетәбез, -
Кашка тәкә тиңе итәбез.
Күрше хакы – Алла хакы, диеп,
Аяк сузар хәлгә җитәбез.
Үлә-бетә урыс үрчетәбез...

* * *

Авызында пыскый тәмәкесе,
Кулларында хәмер шешәсе.
Яраамшәрә йөрү, имеш, «кәттә» –
Заманча кыз була, янәсе.

* * *

«Йортны тоткан, йортны бөлдергән дә
Хатын-кыз» дип, әйтә халкыбыз.
Кояшлы яз, шыксыз көзләр сыман
Була белгәне дә – хатын кыз.

* * *

Бизәнсә дә асылташлар белән
Яман гадәтләре үзгәрмәс.
Агу тулы кылыч телен кадар,
Берәүне дә чакмый үткәрмәс.

* * *

Барлык телләрне дә Аллаһ белә,
Өстен күрми тик бер телне дә.
Гәркемгә дә үй-хис, фикерләрне
Ирештерә туган телендә.

* * *

Күкләр күкрәп, яшен яшьнәп үтте,
Яңгыр булып яуды бәрәкәт.
Бар табигать тәкъва мөселман күк -
Үөселләнеп кылды гыйбадәт.

* * *

И йөрәгем, нинди кодрәтле син,
Инфарктны да җиңдең көрәштә.
Чирле килеш инде кырык дүрт ел
Син тибәсең һаман, син эштә, –
Рәхмәт сиңа, рәхмәт, әлбәттә.

* * *

Шигырь – сүзнең энҗе һәм мәрҗәне,
Үй-фикернең акыл сөзмәсе.
Булмасын ул – аерткан сөт кебек,
Сыекланган сүзләр тезмәсе.

* * *

Ана сөте белән дә кермәсә, -
Тана сөте белән кермидер.
Ана сөте белән кергән яман
Кешелеккә тынгы бирмидер.

* * *

Елан сыман ятып шуышыр ул,
Диңгезләрнең йөзәр суында.
Көпчәк сыман тәгәрәгән мәлдә
Чагып китәр, торсаң юлында.

* * *

Дошманның бар зуры, кечкенәсе, –
Иң явызы – каның койганы.
Үз каныңнан туган балаңның да
Була сиңа яман кылганы.

* * *

Тик Аллаһы мәңгелек бердәнбер,
Мәхәббәт тә, диләр, мәңгелек.
Икенең дә бер үк сыйфатлары –
Икесе дә алар бер кебек.

* * *

Иптәшем дип атый хатын ирен,
Иптәшем ди ир дә хатынын.
Иптәшем дип әйтер микән берәү –
Никахлашып бергә торганын.

* * *

Җанварлар да табигатьчә яши,
Тату тора хайван ишеләр.
Әверелсәк нәфес колларына
Кем булырбыз соң без, кешеләр?

* * *

«Реформа» дигән латин сүзен,
Әй, яратты безнең түрәләр:
Үзгәрешләр миллион сумга төшә, -
Шул акчага рәхәт күрәләр...

* * *

Язмыш атым ничә мәртәбә
Тибеп-тибеп узды тәртәгә.
Миңа сабырлыклар бирә белгән
Фәрештәләремә – мәрхәбә!

* * *

Бер уйласаң, галәм – төпсез бушлык,
Йолдызлары берни сөйләми.
Җиде катлы күктә – мең могҗиза,
Бушлыкны ул барыбер өнәми!

* * *

Юк, билгесез солдат, димәгез лә,
Арта бара һаман кадере.
Чит җирләрдә, чит туфракта тыгел,
Җир шарында – аның кабере.

* * *

Ул – сүзләрдән таҗ-такыя ргән,
Чын бөекләр белән ярышкан.
Гәм үзе дә гали асыл зат ул:
Шигырь шаһы – Нури Арслан.

* * *

Татарга зыянлы татар
Тәреле хатын ала.
Гомер буе марҗасына
Олтырак булып кала.

* * *

Бу дөньяда һәркем яши
Нәсел калдыру өчен.
Астагы ботаклар корый, -
Өсләргә биреп көчен.

* * *

Кояшсыз тереклек булмый,
Ризыксыз яшәп булмый.
Гәм мәхәббәтсез тормыш та
Сукыр бер тиен тормый.

* * *

Ярлы булу гаеп түгел,
Карак булуы гаеп.
Угрыны җеннәр каршылар,
Тәмугта колач җәеп.

* * *

Утның көчен казан белә,
Диннең көчен адәм белә.
Иланы тиңсез көч-кодрәт
Аллаһның үзеннән килә.

* * *

Хакыйкатьне белим дисәң,
Коръән-Кәримне өйрән.
Яшәешнең кануннарын
Аллаһ Коръәндә биргән.

* * *

Кемгә тәртә арасына,
Кемгә кул арасына.
Кемгә рәхәт, кемгә михнәт, –
Без бәндә баласына.

* * *

Сокланып карыйбыз Күкнең
Кояшына, аена.
Мең кояш, мең ай тиң түгел
Кеше елмаюына.

* * *

Агач төпләрен кар каплый,
Алар салкында туңмый.
Тамыры нык татарның да
Иманлы рухы сынмый.

* * *

Теге дөнья бармы, юкмы -
Берәү дә аны белми.
Андагы хәлләрне әйткән,
Хат-хәбәрләр дә килми.

* * *

Вакытның – чиге юк аның,
Вакытта юктыр ара.
Туу, үлү мәле генә
Тик секундлардан тора.

* * *

Күк күкрәп яңгыр яумаса,
Хараптыр иген эше.
Буш сүз сөйләү дә файдасыз, -
Гамәл кылмаса кеше.

* * *

Бер диңгезнең суы татлы,
Бер диңгезнеке тозлы.
Изге мөселман кавемен
Кәфер кавеме бозды.

* * *

Әтәч шикелле кукраеп,
Йөри бер шагыйрь заты.
Аллаһның кашка тәкәсе –
Тагылма кушаматы.

* * *

Тинтәк булу чибәр кызга,
Кай тирәгә килешә.
Тинтәкләр дә тинтәклектән
Теләгенә ирешә.

* * *

Хәзер компьютер заманы, -
Юктыр башны ватасы.
Төймәсенә баса белсәң,
Бот күтәреп ятасы!

* * *

Хикмәт сүзе бик зиннәтле,
Ул сүз бик тә кыйммәтле.
Бу сыйфатка ия кеше
Булыр күркәм, хөрмәтле.

* * *

Диннең милләте юк, диләр,
Көчләү дә юк хак дингә.
Тик милләтсез юктыр дин дә,
Милләтсез түгел кем дә.

* * *

Чукрак кеше сүз ишетми,
Әйтәлмый аны телсез.
Тик аларның гамәлләре
Дини булуда тиңсез.

* * *

Төрле мәзһәбкә бүленде
Исламлы адәм заты.
Тик алар бер дин затлары,
Түгелләр ярты-йорты.

* * *

Бидгатьчеләр бик тә тели
Ислам динен бозарга:
Яңгыр явар болытларны
Алыштырмак кысырга.

* * *

Уйлы кеше базар ачар,
Гавамга бәйрәм ясар.
Хәләл мизаннар яныннан
Хәрам гамәлләр качар.

* * *

Үзен хөрмәт иткән затлар
Эткә ияреп йөрмәс.
Этенә дә, бетенә дә
Койрык та болгый белмәс.

* * *

Изге-рухи гамәлләр
Ғуыннар аша үтә.
Кеше – гомере беткәч тә
Яшәвен дәвам итә.

* * *

Чык тамчыларына чумып,
Чәчәкләр керфек кага.
Чирләрдә коенган гөлләр
Кояшка таба бага.

* * *

Кырларында иген шавы,
Ғолыннары – чәчәкле.
Җиргә гашыйк халкы белән
Авыллар киләчәкле.

* * *

Яхшы гадәт, яман гадәт
Ғорын заманнан килә.
Затлылык дигән сыйфатлар
Аллаһыдан бирелә.

* * *

Йөзендә кояш балкытып,
Ғар иткән аны Аллаһ.
Үзе сыйлы, куены җылы -
Әйтерсең иркәм оҗмах.

* * *

Кояш юксыз – дөнья нурсыз,
Яшәеш юк гыйшыксыз.
Тормыш кояшы – хатын-кыз,
Хатын-кызсыз – җир шыксыз.

* * *

«Мин шагыйрьләр шаһы», – дия,
Эченә хәмер керсә.
Җиһангиры булыр иде, -
Хәмерсез яши белсә.

* * *

Сүзләре сихри-тылсымлы,
Акылга бай, хискә бай.
Могҗиза, хикмәт иясе
Мәшһүр Пушкин вә Тукай.

* * *

Хисе барның – акылы юк,
Акыллының хисе юк.
Хис – акыллы адәмнең дә
Иртәсе бар – киче юк.

* * *

Тәрәккыять, алгарыштан
Сүнә әхлак яктысы.
Ярты халык эшсезлектә,
Сәрхушлектә яртысы.

* * *

Кеше талап бай булганнар, -
Рухилыкта ярлылар.
Кара мәрмәр һәйкәл булып,
Зиратларда калырлар.

* * *

Башлык булу өчен буйның
Кирәкми озынлыгы.
Баш бармакның буе кыска, -
Тик өстә урындыгы.

* * *

Егылып уңдым хатыннан -
Сабый баладай холкы.
Аркылыны буйга саллмас,
Белгәне: ашау-йокы.

* * *

Татар канлы, урыс телле
Ярым-йорты оныгым,
Нәселебез – хак мөселман,
Асылыңа кайт, улым!

* * *

Диндә милләт юк, дисәк тә,
Һәр милләтнең үз дине.
Аллаһның Коръән-Кәриме, -
Тереклекнең тезгене.

* * *

Гаепсезгә гаеп такма,
Дәлилсез яла якма.
«Әлиф»не белмәгән килеш
Фәтвалык кылып ятма.

* * *

«Хатыныңны үпсә казый, -
Кем яклар сине, абзый?»
Дип әйтә мескен халык,
Дөньяда бармы хаклык?

* * *

Татар! Кем дип аталсаң да,
Милләткә ямау булма.
Татар халкы иң сыйфатлы
Алтын җепләрдән сырма.

* * *

Һәр халыкның бар дуслары, -
Бар һәртөрле дошманы.
Җир йөзендә коелмасын,
Дин кардәшләрнең каны.

* * *

И хокуксыз, газиз халкым,
Үз өеңдә өйдәш син.
Үз илеңә, үз җиреңә
Хуҗа булып эндәш син!

* * *

Татар татарлыгын итә, -
Ул үзара талаша.
Үз телен белмәгән манкорт
Дошман белән яраша.

* * *

Гомере буе татарга
Бу халык этлек эшли.
Котырган эт тә ашаткан
Хуҗасын, диләр, тешли.

* * *

Салкын сөт эчтем – чирләтте,
Ә кайнары – терелтте.
Үзенең ике сыйфатка
Хас икәнен белгертте.

* * *

Төсе-бите, кыяфәте,
Әйтерсең коеп куйган.
Коеп куйган җанлы курчак,
Күңел кояшын җуйган.

* * *

Гомерләрне кыска, диләр,
Уза да китә, диләр.
Акыл белән яшәүчегә
Шунсы да җитә, диләр.

* * *

Туй ашлары суынмаган...
Син инде аерылган.
Очарга әзер яшьлекнең
Канаты каерылган.

* * *

Берәү ашый яшәр өчен,
Берәү тик ашар өчен.
Гәркем үзенчә яшәсен,
Тик түгел ватар өчен!

* * *

Берәүгә кирәк өч нәрсә:
Хәмер, калҗа, сөяркә.
Типтергәннәргә картлыкта
Тәтемәстер сөяк тә.

* * *

Ата-баба данын саткан,
Тәре таккан мөртәт бар.
Дине – көфер, үзе – кяфер
Ике чабата – бер пар.

* * *

Әрле-бирле талкый җилләр
Ялгыз калган каенны.
Каенга эл күңелеңне, –
Җилләр алсын кайгыңны.

* * *

Аяк-куллары – исән-сау,
Башында акылы бар.
Ләкин тормышка яраксыз, –
Күңеленең кыры тар.

* * *

Бүгенге шәфкать туташы, –
Сырхау кеше борчасы.
Чиреңнән дә авырттырып,
Акча талый барчасы.

* * *

Багучы дигәнгә барма,
Башыңа кайгы алма.
Ришвәтче табибларның да
Кулына икән калма.

* * *

Тел – милләтебезнең җаны,
Җан – милләт исәнлеге.
Үз ана телен саклауда -
Татарның бердәмлеге.

* * *

Йөзеңдә юкса ай-кояш,
Йолдызлар да юк, иркәм.
Балкып торган нурлы йөзең –
Күк йөзе сыман күркәм!

* * *

Диләр: «Дәүләтен торгызды,
Яһүдтән алыйк үрнәк».
Үз дәүләтең булсын дисәң -
«Яһүд»легең бик кирәк.

* * *

Кыйбласын югалткан татар
Үз илендә адашты.
Милли рухын, горурлыгын
Мескенлеккә алмашты.

* * *

Тормыш каршылыктан тора –
Җан тартмаса – кан тарта.
Кан тартканны – җан өнәми,
Җан сөйгәнне – кан сөймми.

* * *

«Эшче булу – хурлык, – дия -
Мәктәп бетергән яшь кыз.
– Акчалы фәхишә булам,
Акчасыз кеше – сансыз».

* * *

Чәчәк алыпсатар кемсә
Коттедж кора.
Затлы каләм ияләре
Йортсыз тора.

* * *

Кире беткән дә тыгел кыҗ,
Мәрхәмәтле дә кебек.
Тик холкы үз канунында,
Буйсыныр димә берҗ.

* * *

Ул – хәйләкәр, ул – мәкерле,
Ул – безнең «Олы» курше.
Милли йөзебезне сөрткән
Явыз бәндәнең – берсе.

* * *

«Утлы камчы» ялкыннары
Көйдереп ала безне.
Аллаһының каһәренә
Тап иттек үзебезне.

* * *

Арыш, бодай бөртекләре
Сихри алтын төсендә.
Әлмә гәрәбә бөртекләр
Үсә туфрак өстендә.

* * *

Туган көнен бәйрәм итә
Татарымның азганы.
Хәрам ашап, хәрам эчеп
Кыйбласыннан язганы.

* * *

«Аша да эч, типтереп кал», –
Дип әйтә яңа байлар.
Халыкларны ач калдырып,
Ил-җирне талаганнар.

* * *

Орлыклар уңыш бирсенгә –
Су сибеп тору кирәк.
Догаң саваплы булсынга –
Изге эш-гамәл кирәк.

* * *

Иң акыллы, иң күркәм тел –
Үзен тыя белгән тел.
Тел әйткән хикмәтле сүзнең
Игелеген күрә бел.



ЭЧТӘЛЕК

Татар өчен җан аткан әдип... 5

I бүлек

Болгар җыенында 14
Милли холык 17
Без – кылычлы милләт 18
Каравыл! 19
Уйлашыйк әле! 19
Вакыт! 20
Үкенечле үтенеч 21
Метаморфоза 22
Үзең хуҗа бул! 24
Татар халәте?.. 25
Татарлык билгесе 26
Кан акты 28
Уен бара... 29
Толерантлык турында 30
Риваять 31
Милли корт 32
Кем гаепле? 32
Җаным сыкрануы 34
Өмет баглау 35
Өмет 36
И, мокатдәс туган телем! 37
Җитәр вакыт... 38
Исеңдә тот! 38
Нигә шулай? 39
Татар аты 40
Иреккә сусау 41
Безнең татар 42
Булма гафил! 45
Табигыйлек 45
Орлыксыз башак 46
Кардәшкә эндәшү 47
Уяна! 48
Соңгы чара 49
Көрәш өлгесе 50
Тураеп бас! 51
Уйланыйк әле, кардәшләр! 52
Мин – татармын! 53
Ерактан килгән аваз 55
Җан авазы 56

Бер кыйтга....64
Албасты....65
Давыл хәбәрчесе....66
Җавап....67
Тартыш бара...68
Татар язмышы....69
Татарник....71
Кем һәм нинди?....71
Муенчакларны атып!....73
Мин әйтәмен....75
Ләкин!..75
Бергә булыйк, бердәм булыйк!....76
Учак....77
Сорауларга җаваплар....78
Бигайбә....80
Тәвәккәллек....80
Тансыклаган төш....81
Сагыш....82
Аяныч....84
Йөрәккәем....85
Йөрәк җыры....86
Иҗат газабы....86
Хисап тоту....88
Кемгә нинди бәхет?....89
Халәтемнең шундый чагы....90
Кайтаваз....90
Уразада булган чагың....91
Барлыгым....92
Дәрья кичтем....93
Соңгы теләк....94
Мин – табигать баласы....95
Галәмәт....96
Алданма!....96
Борчылу....98
Гомеркәем!....100
Картлыгым-шатлыгым....101
Мин бәхетле....101
Баш иямен....103
Минем язмыш....104
Пошыну мәлендә....105
Авылдашларга нәсыйхәтем....106
Сөйлим ихластан....107
Гомер....108
Язмышымда – тояк эзләре....109

Урман иле ... 122
Сихәт алам ... 126
Татар алиһәсе ... 127
Мәхәббәт әлифбасы ... 129
Мәхәббәт турында ... 130
Татар хатыны ... 131
Сәрхушлекне яңгыр юмакчы... ... 132
Кызганыч хәл ... 134
Җәза ... 135
Мәнсезлек ... 135
Аналар күрке ... 136
Тулгак бәясе ... 137
Терәк бул! ... 138
Тәкатьсезлек бәласе ... 139
Гадәткә керсә ... 139
Тәүбәгә килү ... 140
Капма каршылык ... 141
Заманның яман сурәтләре ... 141
Җир алмасы ... 142
Чорнап ала язмыш ... 143
«Аккош күле» урманында ... 144
Икмәк каргышы ... 144
Бичара!.. ... 146
Илле яшь ул... ... 147
Дуска ... 147
Яшибез ... 149
Очты мәгърип ягына ... 149
Елан елына аяк басканда ... 150
Ахырзаман ... 151
Дисәк тә... ... 152
Табып булмый ... 154
Фәлсәфи яңгыр ... 154
Вәт замана! ... 155
Икейөзле бәндәгә ... 156
Яши шундый ... 157
Сайлау-сайлану ... 158
Тере курчак ... 159
Кем ул? ... 160
Бәгъзе каләм иясенә ... 161
Гыйбрәтле җәза ... 161
Фетнәче? ... 162
Шулай булыр! ... 163
Бәхет әлифбасы ... 164
Дөньяви сагыш ... 166

Югалту 167
Саклап тора җәза 168
Бәрәкәтле хәрәкәт 169
Манзара 170
Көзге манзара 171
Чабата турында 172
Җыерчык 173
Ак болытлар 174
Бер киңәш 175
Мандатлы кул 175
Эх-ма! 177
Байлык белән сынау 178
Кем син? 179
Ә син беләсеңме? 180
Әй, син кеше! 183
Тотка 184
Уйландыра 185
Замана мактанчыгы 187
Эт һәм песи мәрәкәсе 188
Ярый әле... 189
Менә шулай 190
Этлек 191
Безнең мәгыйшәт 192
Тәкълид 193
Татарга эндәшү 194
Әйтер сүзем 195
Мәңгелек сорау 196
Нәфес турында 197
Хисләрем дисбесе 198
Татар язы килер... 200
Урыс «демократия»се 201
Язмыш тамгасы 211
Чарасызлык 212
Һәлакәт 213
Ялган һәм чынбарлык 214
Кем? 215
Чиге бармы? 216
Сабан туе галәмәтләре 217
Килер бер көн! 218
Буталган мәгыйшәт 219
Соң булса да 220
Соңгы сүз 221
Эчтәлексез тормыш 222
Нәүмиз иттең 223

Тормышымның син йолдызы идең 224
Яңарыш 224
Әнием – Хәбибҗамал 226
Чагылыш 227
Күкләр галәмәте 229
Ак болыт инде 229
Ялгышлыклар, хаталар... 230
Тормыш дәвам итсен! 232

II бүлек

Өч һәдия 238
Галәмнәрнең бердәнбере 239
Аллаһының илаһияте 240
Хисап бирәбез 242
Мөнәҗәт 243
Ирешүдә Аллаһ рәхмәтенә 244
Аллаһыга сыгыныйк 245
Ике язмыш, ике юл 246
Бердәнбер 247
Фарыз булсын! 248
Сөбхәналла 248
Бер нәсихәт 250
Җәза 251
Сур мөгезе әле... 253
Тарихтан бер сәхифә 253
Могҗизалы терелү 255
Пәйгамбәрне яд итү 260
О син, кеше! 261
Элгәреләр һәм бүгенгеләр 263
Чигүле дөнья 264
Күк җәзасы 265
Бер кебек 266
Никах 267
Камиллек 268
Иншаллаһ 268
Бердән-бер юл 269
Әгәр... 270
Мәңгелек көрәш 271
Канун булсын! 272
Барысы да Аллаһ кодрәтендә 272
Адәм 274
Әйләнештә... 276
Хисап 277
Күрше хакы – Аллаһ хакы, диеп 278

Денсезлек 280
Әйләнеш 281
Кәһәрле кавем 282
Бертуганнар 282
Иблискә ияреп 284
Адашу 285
Әҗәлгә бер сүз 286
Кар сулары 288
Яшәү катламнары 289
Лаекмы син?.. 290
Дәһри адәм 291
Бер киңәш 292
Аллаһының бүләге 293
Комагай 295
Саранлык бәласе 297
Урталай 298
Сабырлык турында 299
Уйлан, Кеше! 300
Соңгы чик 301
Онытмыйк! 304
Аллаһү әкбәр 305

III бүлек

Лә иләһә илләл-лаһ * 308
И кардәшләр! 309
Бердәм булыйк! 310
Әй, татар җанлы туганнар! 311
Милли холык 312
Татар моңы 312
Әй, җир-әнкәм... 314
Бәрәңге җыры 315
Аналар мәхәббәте 316
Туган йорт, туган нигез 316
Әти бәгърем 317
Әнкәй бәгърем 318
Авылдашларга нәсыйхәтем 319
Сезгә дәшәм 320
Аты елгасы буенда 322
Субаш-Атым 323
Яшә, Арчам! 324
Илле яшь ул... 325
Илаһи җыр 326
Хәят нуры 327
Сөю турында 328

Мәхәббәт манзарасы 329
Мәхәббәт аҗаганы 330
Син – мәхәббәт бит үзең 331
Мәхәббәт нуры 332
Мәхәббәт галәмәте 333
Ана булу 334
Үзәкләремне өзә 335
Татар кызы! 336
Ихлас күңелдән 337
Котлау сүзе 338
Кыр чәчкәләре – гүзәлләр 339
Әй, Чулпан 340

IV бүлек

Ана 342
Моң 353
Ахирәткә* хат 363

V бүлек

Дини мотивлар 406

РӘИС САФИН

ҖАН АВАЗЫ

Компьютерда верстка лаучы А. М. Гапсаламов
Рәссамнар: Рушан, Илгиз Шәмсетдиновлар

Сдано в набор 10.08.2017 г. Подписано к печати 28.09.2017.
Формат 60x84 $^{1/16}$. Бумага офсетная.
Гарнитура «Таймс». Печать ризографическая.
Усл. печ. 118 л. Тираж 500 экз. Заказ № 133.

420111, Казань, Дзержинского, 9/1. Тел. 8 917-264-8483.
Отпечатано в редакционно-издательском центре «Школа».
E-mail: ric-school@yandex.ru